ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

Минһаҗетдин Җәбәли

# ТӘВАРИХЫ БОЛГАРИЙӘ ВӘ ТАТАРИЙӘ

«МИЛЛИ КИТАП»

ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

Минһаҗетдин Җәбәли

# ТӘВАРИХЫ БОЛГАРИЙӘ ВӘ ТАТАРИЙӘ

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2023

**УДК 94(3=512.1)+28–9(470.40/43–31)**
**ББК 63.3(0=63)+86.38–3(2Рос.Тат)**
**Җ 77**

*Төзүчесе, басмага әзерләүче*
*һәм мәкаләләр авторы –*
*археограф, текстолог*
Раиф Мәрданов

**Җ 77** Җәбәли Минһаҗетдин. Тәварихы Болгарийә вә татарийә / төз. Р.Ф.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2023. – 234 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 31 нче китап).

Бу китапта Минһаҗетдин Сәйфулла улы Җәбәлинең болгар-татар тарихына багышлап 1878 елда язган хезмәте тәкъдим ителә. Автор кулъязмасы моңарчы галимнәр тарафыннан өйрәнелмәгән иде.

Аның төп әһәмияте – Минһаҗетдин Җәбәлинең беренчеләрдән шундый хезмәт язарга алынган булуында. Чөнки ул вакытта әле халкыбызның үткәне турында татар авторларының бер китабы да басылып чыкмаган.

Җәбәлинең исеме үз чордашлары Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Хөсәен Әмирханов һәм Каюм Насыйри белән янәшә торырга лаек.

ISBN 978-5-88473-098-4

УДК 94(3=512.1)+28–9(470.40/43–31)
ББК 63.3(0=63)+86.38–3(2Рос.Тат)

© Мәрданов Р.Ф., 2023
© «Милли китап» нәшрияты, 2023

# «БОРЫНГЫ ТАРИХЛАРДАН ҖЫЕП ЯЗДЫМ...»

Халкыбызның тарихы искиткеч бай. Гарәп язулы иске татар кульязмалары арасында Болгар һәм Казан кебек борынгы калалар, Чыңгыз хан, Аксак Тимер, Сөембикә һәм башка тарихи шәхесләр турындагы ярым уйдырма риваятьләр, нәсел шәҗәрәләре, мөселман дәүләтләренең үткәндәге маҗараларына багышланган кыйссаларның кульязма күчермәләре еш очравы – татарларның гасырлар дәвамында үз тарихы белән кызыксынганын ачык күрсәтә. XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башында болгар-татар тарихы темасына яртылаш дөреслек һәм яртылаш уйдырмалар нигезендә Таҗетдин Ялчыгол иҗат иткән «Тарихнамәи Болгар», шулай ук аңа нисбәт ителә торган (ләкин авторлыгы бәхәсле) «Тәварихы Болгария»[1] әсәрләренең халык арасында гаять популяр булганлыгы да тарихка ихтыяҗның дәрәҗәсен билгеләргә ярдәм итә.

Мәгълүм булганча, мәдрәсә белемле татарлар XIX гасырда халкыбызның тарихын фәнни нигездә өйрәнүгә омтылганнар. Казан университеты галиме Ибраһим Хәлфин (1778–1829), Хөсәен Әмирханов (1816–1893), Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889), Петербург университетында лектор булган Хөсәен Фәезханов (1823–1866), Каюм Насыйри (1925–1902) – нәкъ менә шундый милли тарихчыларыбыз.

Әлеге санаулы галимнәр янәшәсенә тагын бер татар укымышлысы – тарихи хезмәт язуга җөрьәт иткән, әмма әсәре дөнья күрмичә калган Минһаҗетдин мулла Сәйфулла улы әл-Җәбәли (1838–1893) исеме дә өстәлергә лаек.

[1] Монысының авторы дип китапта Хисаметдин Шәрәфетдин улы Мөслими күрсәтелгән, бу исем Шәрәфетдин Хисаметдин улы дип тә теркәлгән.

«Татар археографиясе» сериясенең бу басмасында Минһаҗетдин мулланың болгар-татар тарихына багышланган җыентыгындагы язмалары – автор әсәренең кыскачарак һәм тулырак каралама вариантлары тәкъдим ителә.

Археографик сериянең элеккеге бер басмасында Хөсәен Фәезхановның «Кыскача татар тарихы» дип исемләнгән хезмәте дөнья күргән иде[2]. Сериянең башка китабында исә Ибраһим Хәлфиннең Казан тарихына багышлап язган әсәре турында мәгълүмат бирелде һәм хәзергәчә сакланып калган кереш өлеше нәшер ителде[3].

## Тарихи җыентык кулъязмасы

Минһаҗетдин Җәбәли тарафыннан язылган, фәнни әһәмияткә ия җыентык элек археограф галимә, педагог Зәйнәп Максудова (1897–1980) карамагында булган. Ул аны кайдан кулына төшергәндер – билгеле түгел. Максудова бу җыентыкны 1962 елда Казан дәүләт университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенә тапшырган. Кулъязма хәзерге вакытта китапханәнең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә «2113т» шифры белән саклана.

Кулъязма текстының кайбер өлешләрен Максудова үзенә күчереп калдырган. Мәсәлән, Татарстан Республикасының Милли музеендагы Зәйнәп Максудова фондында (№18369 фонд) саклана торган «Казан бәете» фрагменты күчермәсен «Татар археографиясе» сериясендә дөнья күргән тарихи бәетләр җыентыгыбызга керткән идек. Максудова әлеге күчермәне

[2] [Фәезханов Хөсәен]. Кыскача татар тарихы / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2011. – 68 б. Х.Фәезхановның борынгы болгар ташъязмаларына багышланган, Казан һәм Касыйм ханлыклары турындагы фәнни хезмәтләренең кулъязмалары 1998 елда табылып (алар хәзер Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә саклана), башка бер күләмле җыентыкта беренче мәртәбә нәшер ителгән иде (*Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык / төз.-авт. Р.Мәрданов. – Казан: «Җыен» нәшр., 2006. – 704 б.*).

[3] «Чыңгызнамә»: тарихи дастаннар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2019. – Б. 27–30.

«Минһаҗетдин Сәйфулла угылының кулъязма мәҗмугасеннән берничә мисраг» дип атаган[4]. Ә текст ахырында «Минһаҗетдин Сәйфетдин[5] угылының «Мөнтәхәб тәварихы Болгарийә» исемле кулъязма мәҗмугасеннән. Бу кулъязма мәҗмугане Казан дарелфөнүне хизанәсенә тапшырдым. Зәйнәп» дигән искәрмә бирелгән. («Казан дарелфөнүне хизанәсе» дигәндә Казан университетының Фәнни китапханәсе күздә тотылган).

Кулъязма җыентык университет китапханәсенә саклануга тапшырылгач, аның белән галимнәр кызыксынганлыгы мәгълүм (мәсәлән, тарихчы Рәшид Кадыйров һ.б.). Әмма, җыентыкның әсәр караламасы хәлендә булганлыгы, тексты тулы түгеллеге һәм кәгазьләре буталганлыгы сәбәпледер – аны тикшереп, нәшер итәргә омтылучылар һәм мәкалә язучылар безгә билгеле түгел. Һәрхәлдә, татар тарихи чыганакларын өйрәнгән галим Миркасыйм Госманов китабында, халкыбызның төбәкчелек тарихын фәнни нигездә тикшергән Рафаэль Шәйхиев хезмәтендә, Идел-Урал буйларында яшәгән татар һәм башкортларның Болгарга мөнәсәбәтләрен, аерым алганда, «Тәварихы Болгарийә» исемендәге әсәрләрне тәфсилләп өйрәнгән Аллен Франк һәм Михаэль Кемпер китапларында, XVII–XIX гасырларның әдәби-тарихи ядкярләре тупланган (өчесе «Тәварихы Болгария» исемле) җыентыкта, Яшел Үзән төбәге тарихына багышланган җыентыкта[6], шулай ук татар тарихының җиде томлыгында Минһаҗетдин Сәйфулла улының исеме язылмаган һәм тарихи әсәре турында берни дә әйтелмәгән. Димәк, аның хезмәте фән дөньясында һаман да билгесез иде.

[4] «Гәүһәр Болгарга килдем...»: тарихи бәетләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2013. – Б. 96, 113.

[5] Бу исем З.Максудова күчермәләрендә ике төрле: Сәйфулла һәм Сәйфетдин рәвешләрендә язылган. Шуны да искәртик, З.Максудова кулында һәм карамагында булган йөзләрчә кулъязма ядкярләр арасында Минһаҗетдин мулла исеме белән бәйле бүтән истәлек булганлыгы ачыкланмады.

[6] Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв.: «Сборник летописей», «Дафтар-и Чингиз-наме», «Таварих-и Булгария», татарские шаджара. – Казань: изд-во ун-та, 1972. – 223 с.; Шайхиев Р. Татарская

Бары тик әдәбият галиме, татар фольклоры белгече, галим Марсель Бакиров Зәйнәп Максудованың шәхси архивыннан алып, «Казан бәете» фрагменты текстын бастырган[7], аннан соң бу бәетнең шул ук сәхифәләре башка китапларда да чыкты. Аларда, башлангыч чыганак күрсәтелгән очракта да, З.Максудова исеме генә аталган.

Бу кулъязма җыентык турында кыскача мәгълүмат һәм Зәйнәп Максудованың фикере галим Әлфрид Бостанов китабында басылды[8]. Ул З.Максудованың «Үземдәге кулъязма китаплар, сәхифәләр каталогы»нда 201 нче исемдә теркәлгән. Мәгълүматы түбәндәгечә.

«201 (2113Т). Минһаҗеддин бине Сәйфеддин әл-Болгари. «Тәварихе Хакания вә Болгария». Зәй өязе Бәчук авылы мөгаллиме һәм имамы. XIX йөз. Бу китапның төп кулъязмасы Казан дәүләт дарелфөнүннең Шәрык язмалары хәзинәсенә бирдем. Тарих. Төрки телдә. 1878 миладидә тәэлиф ителгән. 75 кәгазь. Шуннан күчереп, үз кулым белән язылган нөсхә үземдә саклана. Татар-болгар хакында кызыклы хәбәрләр бар».

Моңа карата Ә.Бостанов тарафыннан әсәр кулъязмасының хәзерге вакытта Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәдә «2113т» шифры белән саклануы, кәгазенең форматы

---

народно-краеведческая литература XIX–XX вв. – Казань: изд-во ун-та, 1990. – 118 с.; Франк Аллен Дж. Исламская историография и «булгарская» идентичность татар и башкир в России / пер. с англ. И.Хайбутдиновой. – Казань: РИУ, 2008. – 266 с.; Кемпер М. Суфии и ученые в Татарстане и Башкортостане. Исламский дискурс под русским господством / пер. с нем. И.Гилязова. – Казань: РИУ, 2008. – 675 с.; Мирастан биш сәхифә: XVII–XIX гасырлар әдәби-тарихи ядкярләре. – Казан: Татар. китап нәшр., 2011. – 331 б.; Зеленодольский регион: проблемы истории и культуры. Восток-Запад: диалог культур Евразии / под ред. А.А.Бурханова. Вып. 3. – Казань: Gumanitarya (Изд-во ТГГИ), 2003. – 395 с. (серия «Проблемы истории и археологии»).

[7] Яхин А., Бакиров М. Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе: мәзәкләр, бәетләр. – Казан. ун-т нәшр., 1979. – Б. 125.

[8] Бустанов А. Библиотека Зайнап Максудовой = Зәйнәп Максудова китапханәсе. – М., 2019. – С. 177.

21x35 см. тәшкил итүе һәм «бу китапны университетка Максудова 1962 елда тапшырган. Кара каралар, кустодлар юк»[9] дигән искәрмәсе өстәлгән.

Галимә Зәйнәп Максудованың әлеге мәгълүматында Минһаҗетдиннең әтисе Сәйфетдин дип ялгыш язылган. Алда искәртеп үткәнебезчә, Милли музейның Максудова фондындагы исемлекләрдә һәм бүтән бер күчермәсендә Сәйфулла дип дөрес теркәгән урыннары да бар. Шулай ук Минһаҗетдингә «әл-Болгари» дигән нисбә З.Максудова тарафыннан өстәлгән булуын искәртик, чөнки кульязмада автор үзен «әл-Җәбәли» дип язса да, «Болгари» дип күрсәтмәгән. Әсәрнең исеме «Тәварихы Хакания вә Болгария» рәвешендә бирелүдә зур булмаган төгәлсезлекне искәртик – автор үз хезмәтен төрле вариантларда исемләгән һәм аларның берсе – З.Максудова язганга якыны – «Тәварихел-Болгарийә вәл-хаканийә»[10]. Алдарак Максудова тарафыннан бу әсәрнең «Мөнтәхәб Тәварихы Болгарийә» дип билгеләнгәнен күреп үткән идек, автор язмаларында нәкъ андый атамасы юк, ә «Мөнтәхәбет-татар» дигәне һәм «Мөнтәхәб фи әхвали...» дип башланган озын варианты булган.

Кульязма җыентыкның күләмен «75 кәгазьдә» дип белдерүгә дә аңлатма таләп ителә. Бу очракта ике тарафлы кәгазьләр түгел, ә гомуми битләр саны язылган һәм ул дөреслектә 76 битне тәшкил итә.

Зәйнәп Максудова аңлатмасындагы гарәп хәрефләреннән күчереп язылган «Зәй өязе Бәчук авылы» дигән гыйбарәдәге «Бәчук»ның – Бәчек икәнлеге аңлашыла. Ә Зәй өязе дигәне хата. Дөресе – Зөя (Свияга) өязе. Зәй өязе дигән административ берәмлек тарихта гомумән булмаган. Хәзерге Татарстанда Зәй шәһәре бар һәм ул бөтенләй башка тарафта – Чулман елгасының аргы ягында. Шунлыктан, Иделнең уң тарафында-

---

[9] Шунда ук.

[10] «*Хакан*» – төрки каһанлыкларның иң югары хакиме-идарәчесенең титулы. Соңрак башка төрки халыкларның (хәзәр, уйгур һ.б.) хакимнәре дә «хакан» дип аталган.

гы (хәзерге Яшел Үзән районындагы) Бәчек авылы XIX гасырда шактый еракталгы Зәйгә һичничек бәйле булмаган[11].

Максудованың бу кулъязманы «күчереп, үз кулым белән язылган нөсхә үземдә саклана» дигән искәрмәсенә карата өстәп шуны әйтергә кирәк, чынлап та, әлеге җыентыкның төрле битләрендә аның карандаш белән теркәлгән «язылган» һәм «язылды» рәвешендәге искәрмәләре бар.

Бостанов китабында Гали ишан Түнтәри исеменә, гарәп телендә язылган иҗазәтнамәнең тексты, Минһаҗетдин мулла әсәренең башлангыч өлеше гарәп хәрефләре белән күчереп басылган[12] (хәзерге татар әдәби теленә күчермәләре һәм русчага тәрҗемәләре юк).


***

Минһаҗетдин мулланың бу кулъязмасын элегрәк тә күргәнем бар иде. 2018 елда «Татар археографиясе» сериясендә «Чыңгызнамә» җыентыгын басмага хәзерләгәндә кызыксынып тагын карадым. 2022 елның октябрендә университет китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегенә кергәч, коллегабыз Энҗе Сабирова шушы җыентыкның исемен төгәлрәк билгеләү мәсьәләсендә мөрәҗәгать итте. Кулъязманы игътибар белән карап чыккач, аны археографик сериядә бастыру фикеренә килдек. Бу ниятебезне университет китапханәсенең һәм Милли китапханәнең белгечләре хуплап, фатихаларын бирделәр.

---

[11] «Зөя өязе» урынына «Зәй өязе» дип теркәлгән тупас хата З.Максудованың ялгышы булмыйча, күрәсең, китапны басмага хәзерләүченең каләменә нисбәтледер. Чөнки ул китапта татар авылларының исем-атамалары З.Максудова язмаларыннан бик бозып укылган һәм шул рәвештә нәшер ителгәнен (мәсәлән, 64 биттә Тау ягындагы Акъегет авылының исеме танымаслык дәрәҗәдә үзгәртелеп – «Әкыйгәнт» рәвешендә басылганын) элегрәк искәрткән идек (*Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2021. – Б. 16*). «Зөя» атамасын «Зәй» дип бутау элек тә күзәтелә иде (*Гайнетдин Ахмеров. Избранные труды / сост. Р.Г.Хайрутдинов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1998. – С. 5*).

[12] Бустанов А. Библиотека Зайнап Максудовой... – Б. 177–180.



*Кулъязманың 32а кәгазе*

Минһаҗетдин Җәбәли кулъязма җыентыгының битләре-кәгазьләре тегелгән төбеннән сүтелгән һәм таркалган. Барлыгы 38 кәгазьдән торган җыентыкның 18 кәгазе ике урында (12–19 нчы һәм 27–36 нчы кәгазьләре) элек берләштереп, дәфтәрләп тегелгән рәвештә сакланган, 4–5 нче кәгазьләре куш бит, ә калган 18 кәгазе төбеннән аерылган хәлдә. Кулъязманың иясе тарафыннан бит саннары сугылмаган һәм текстның икенче биттәге дәвамын белдерү өчен махсус «хафиз» (кустод) ысулы да кулланылмаган, ә Зәйнәп Максудова билгеләгән пагинация шушы таркау битләргә рәттән куелган. Автор текстының мәгънәсенә нигезләнеп, таркау битләрнең дөрес тәртибен күзаллауга ирештек. (Кулъязма җыентык пагинациясенең дөрес дип табылган рәвешкә туры килү саннары китап ахырында – кулъязманың тасвирламасына багышланган махсус мәкаләдә күрсәтелде).

Безнең аңлавыбызча, Минһаҗетдин Җәбәли кулъязмасында бер үк хезмәтнең каралама рәвешендәге өч (өченчесе кыскача) тексты сакланган. XIX гасырда яшәгән башка татар галимнәренең дә бер үк хезмәтләрен бер төптәге кәгазьләрдә төрлечәрәк вариантларда язган булулары татар археографиясендә очрый. Мәсәлән, Хөсәен Фәезхановның «Рисалә» дип аталган күләмле хезмәтенең өч варианты бер кулъязма җыентыкта бергә тупланган[13]. Каюм Насыйриның Зөя өязе авыллары тарихына багышланган материаллары шулай ук бер үк төптәге кулъязма җыентыкта – һәр авыл турында икешәр-өчәр вариант рәвешендә[14]. Димәк, ул чорда каләм ияләре тарафыннан бер үк кулъязма әсәрнең яисә хезмәтнең берничә вариантын (дөресрәге – беренчесен төзәтеп һәм камилләштереп) язу тәҗрибәсе гамәлдә кулланылган.

Минһаҗетдин Җәбәли кулъязмасын «җыентык» дип атавыбызның берничә сәбәбе бар. Ул автор хезмәтеннән һәм төрле китаплардан күчерелгән өземтәләрдән гыйбарәт.

---

[13] Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык..., 2006. – Б. 279–281.

[14] Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә «601т» шифры белән саклана торган кулъязма.

Автор тексты исә гомуми күләмнең яртысыннан кимрәк өлешен тәшкил итә һәм, өстәвенә, ул берничә варианттан тора. Кулъязманың кәгазьләре (димәк, текстлары да) үзара буталган хәлдә. Гомумән, бу кулъязма җыентык турында, ул – күләмле һәм әһәмиятле тарихи хезмәтнең эш дәвамында тулыландырылып килгән, өстәлгән һәм төзәтелгән, ләкин ахырынача төгәлләнеп җитмәгән нөсхәсе, дип әйтү дөрес булыр.

## Авторы

Тарихи әсәр язган Минһаҗетдин Сәйфулла улы – үзе белдергәнгә караганда, Тау ягындагы – хәзерге Татарстан Республикасы Яшел Үзән районының – Мамадыш авылына нисбәтле укымышлы нәсел вәкиле. Ул нәселенең чыгышын һәм төп буыннарын «Тау ягындагы Гөбенә суы буенда Мамадыш иленнән Минһаҗетдин бине Сәйфулла бине Мөхәммәтшәриф бине Гаделшаһ бине Габдрахман әл-Маматыши әл-Җәбәли» дип язган. «Җәбәли» дигән нисбәсе гарәп телендәге «җәбәл» – тау дигән сүздән алынган һәм Идел елгасының уң тарафы – Тау ягы кешесе икәнлеген белдергән. Нәселләрендә «бабайлар унике кеше имам булып үткәннәр» дип искәрткән. Үзе дә шул ук төбәктәге Бәчек авылында имам булып торган. Аның Бәчек зиратындагы кабер ташына «мулла Минһаҗетдин мулла Сәйфулла улы» дип язылганга караганда, әтисе дә имам булганлыгы аңлашыла. Чынлыкта да, архив мәгълүматларыннан күренгәнчә, Сәйфулла шул ук Бәчектә имам хезмәтен башкарган. Мәгърифәтче галим Каюм Насыйри бер мәкаләсендә үз әтисенең 1857 елда Бәчек авылы мулласы Сәйфулла хәзрәт белән әңгәмәсен искә алган[15], һәм ул – нәкъ менә шушы Минһаҗетдиннең әтисе Сәйфулла мулла булган. Димәк, төп нәсел тамырлары Мамадыш авылына

[15] Насыйри К. Археология материаллары (Зөя өязе авыллары буенча) // Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре һәм йөз еллык бәйрәм материаллары: мәҗмуга / Гали Рәхим карамагында. – Казан: Татарстан дәүләт нәшр., 1926. – Б. 47; Каюм Насыйри: әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык / төз. Р.Исламов. – Казан: «Җыен», 2017. – Б. 264.

бәйләнгән Минһаҗетдингә хәтле аның әтисе үк Бәчек авылында имам вазифасын үтәгән.

Архив документларыннан ачыклануынча, Бәчек авылының указлы мулласы, 1802 елда туган Сәйфулла Мөхәммәтшәриф улы 1869 елның 2 апрелендә 75 яшендә вафат булган.

Улы Минһаҗетдин әтисе исән вакытта ук шул авылда мулла вазифасын үти башлаган. Мәсәлән, 1865 елгы метрика документында алар икесе: «Зөя өязендә Бәчек илендә ил имамы мулла Сәйфулла мулла Мөхәммәтшәриф угылы» һәм «имам-хатыйб вә мөдәррис Минһаҗетдин бине Сәйфулла» дип, бергә имза куйганнар.

Тау ягындагы Гөбенә елгасы тирәсендә Мамадыш исемле авылларның элек бишәү булганлыгы Каюм Насыйри язганнардан мәгълүм[16]. Хәзерге вакытта билгелеләреннән Мамадыш-Әкил дигәнен Мамадыш дип кенә йөрткәннәр. Архив документларыннан ачыкланганча, Минһаҗетдин хәзрәтнең нәселе менә шул Мамадыш-Әкил авылыннан булган. Зөя өязендәге Мамадыш-Әкил авылының 1850 елгы халык исәбен теркәү (ревизия) документында Шәмсетдин Шәрипов гаиләсе белән бергә аның бертуган энесе Сәйфулланың гаилә әгъзалары да теркәлгән. Анда Сәйфулланың 12 яшьлек Минһаҗетдин исемле улы 1838 елның 19 июнь көнендә туган булуы язылган[17]. 1834 елгы исәп алу документында бертуган Шәмсетдин һәм Сәйфулла әтиләре Шәрип Гаделшин (1753–1817) гаиләсендә теркәлгәннәр[18].

Минһаҗетдин мулла белдергән шәҗәрә буыннарында әтисе Сәйфулла ягыннан бабалары Мөхәммәтшәриф, Гаделшаһ һәм Габдрахман исемнәре архив чыганаклары белән раслана. Минһаҗетдин Җәбәли үз бабаларыннан

[16] Каюм Насыйри: әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык..., 2017. – Б. 247–248.

[17] Татарстан Республикасы Дәүләт архивы. – 3 ф., 2 тасв., 219 саклану берәмлеге, 876об.–877 кәгазьләр.

[18] Шунда ук. – 3 ф., 2 тасв., 97 саклану берәмлеге, 93об.–95 кәгазьләр.

12 кешене мулла булганнар дип язганын игътибарга алганда, димәк, аның әлеге өч буындагы бабалары да рухани вазифаларын башкарганнар.

Сәйфулланың бертуган абыйсы Шәмсетдиннең (1799 елда туган) һәм әтиләренең имам булганлыклары Каюм Насыйриның Мамадыш-Әкил авылы тарихы турында язганнарыннан да күренә: «Иске заманда Мамадыш авылында кемнәр имам булып торгандыр, мәгълүм булганы юк. Ләкин элгәре бер заманда Кадер мулла дигән кеше имам булган. Аннан соң Мөхәммәтшәриф мулла булган. Аннан соң Шәмсетдин мулла, хәзердә сәламәт, туксаннарда бардыр, диләр»[19].

Шәмсетдин мулланың улы Шәрәфетдин (1826–1901) шулай ук Мамадыш-Әкил авылында озак еллар имамлык иткән. Минһаҗетдин хәзрәтнең үз улы да мулла булганын исәпкә алганда, бу нәселдәге имамнар саны 12-дән шактыйга артып китүе аңлашыла.

Минһаҗетдин Сәйфулла улы Түнтәр авылында (хәзерге Татарстанның Балтач районында) данлыклы Гали ишан мәдрәсәсендә укыганлыгын һәм остазыннан Тау ягындагы Бәчек авылында имамлык итәргә рөхсәт-фатиха алганлыгын язган.

Хезмәтнең керешендә (26б кәгазьдә) Минһаҗетдин хәзрәт «фәкыйрьлегемез өчен мәдрәсәдә күп заман» тора алмавын искәрткән һәм «хак сөйләгән адәмне капкаларыннан сөрәләр» дип, үзенең хакыйкать тарафдары, туры сүзле булганын да искәрткән.

Мөхәммәтгали ишан Сәйфулла улы Түнтәри (1788–1874) – гомумән, татар тарихында танылган, укымышлы зат. Ул Бохарада, Һиндстанда белем алып, Түнтәрдә 50 елга якын имам булып хезмәт иткән, мәдрәсәсендә күп шәкертләр тәрбияләгән, аеруча белемле һәм сәләтлеләренә фатихасын биргән. Гали ишанның нәфис язулы, мәһабәт кабер ташы

[19] Каюм Насыйри: әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык..., 2017. – Б. 249.

Түнтәр авылы зиратында хәзергәчә сакланган[20]. Бу мәшһүр шәхес турында галимнәрнең һәм төбәк тарихчыларының хезмәтләрендә күп язылган[21].

Минһаҗетдин мулла Гали ишанның кияве Шәмсетдин Рәхмәтулла улыннан[22] да (1830–1876) белем алганлыгын белдергән. Туган төбәге тарихын өйрәнүче фидакяр шәхес, Түнтәр авылында яшәүче Рәфхәт Зарипов үзенең китапларында Түнтәр авылының күренекле мәгърифәтчеләре турында күп мәгълүмат туплап чыгарды[23].

Минһаҗетдин Сәйфулла улының, дини карашларына тәэсире белән бергә, тарихны мөкиббән китеп өйрәнүенә, ифрат дәрәҗәдә кызыксынучанлыгына остазы Гали ишанның йогынтысы булгандыр. 1846 нчы елларда Гали ишанның Вятка губернасындагы (Малмыж өязендә) берничә удмурт авылы халкын ислам диненә күндерү вакыйгасы[24] шәкерте Минһаҗетдингә дә тәэсир итмичә калмагандыр. Идел буе төбәгендә яшәгән чуваш, мукшы, удмурт һәм башка халыкларның элек ислам динендә булганлыкларын Минһаҗетдин мулланың үз хезмәтендә рас-

---

[20] Һадиев И., Мәрданов Р. Балтач төбәгенең ташъязма истәлекләре. – Яр Чаллы: «Ислам нуры» дини-эшмәкәрлек үзәге, 2021. – Б. 108.

[21] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде / төз. Ә.Хәйруллин. – Казан: Татар. китап нәшр., 1989. – Б. 338–339; Балтач энциклопедиясе / төз. Г.Мөхәммәтшин. – Казан: Идел-Пресс, 2006. – Б. 283; Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. – Казан: «Рухият» нәшр., 2010. – Б. 16–42; Балтач энциклопедиясе. II китап / төз. Г.Мөхәммәтшин. – Казан, 2010. – Б. 408–409; Фәхреддин Р. Мәшһүр адәмнәр: «Шура» журналы сәхифәләреннән. – Казан: «Рухият» нәшр., 2012. – Б. 36–47; Мөхәммәтшин Г. Балтач мәчетләре: үткәне һәм бүгенгесе. – Казан, 2018. – Б. 284–286.

[22] Иҗтиһадлы, киң мәгълүматлы бу зат турында Ш.Мәрҗани һәм Р.Фәхретдин шулай ук зур хөрмәт белән язганнар. Әмма аның туган авылы гына икесендә ике төрле күрсәтелгән (Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар..., 1989. – Б. 343; Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар..., 2010. – Б. 87–89).

[23] Мәсәлән, Зарипов Р. Тирән тамырлы Түнтәрем. – Казан, 2008. – 830 б.; Зарипов Р. Түнтәр авылының мәчет-мәдрәсәләре тарихы. – Казан: ун-т нәшр., 2018. – 336 б.

[24] Фәхреддин Р. Мәшһүр адәмнәр..., 2012. – Б. 45.

ларга һәм аларны ничек тә якларга омтылып язуы, ихтимал, шуңа да бәйледер.

Тарихчы Ризаэтдин Фәхретдин Гали ишанның иң булдыклы 14 шәкерте арасында «Минһаҗетдин бине Сәйфулла әл-Җәбәли» исемен күрсәтүе[25] дә очраклы гына түгел.

Остазын бик хөрмәт иткән һәм олылаган Минһаҗетдин хәзрәтнең Гали ишанга Нәкышбәндия суфи галимнәре тарафыннан бирелгән иҗазәтнамә (ишанлыкка рөхсәт документы) текстын тарихи хезмәтенә күчергәнлеген һәм Гали ишанга багышлап язылган мәдхияне урнаштыру нияте булганын да искәртергә кирәк.

Тарихи хезмәт авторы үз исемен, әсәренең атамасы белән бергә, кулъязмасының ике урынында белдергән: 26б кәгазьдә «Мин – Минһаҗетдин бине Сәйфулла бине Мөхәммәтшәриф бине Гаделшаһ бине Габдрахман әл-Маматыши әл-Җәбәли Тау ягында Гөбенә суы буенда булып, ... Бәчек авылында имам булып, берникадәр вакыт балалар укытып, бу китапчыкны яздым. Бу китапка «Мөнтәхәбет-татар» (Татар тарихыннан сайланма) дип исем бирдем». Җыентыкның 38б кәгазендә әсәрен күптөрле чыганаклардан мәгълүмат җыеп-туплап язганлыгын болай дип теркәгән: «Мин – Минһаҗетдин Сәйфулла угылы Бәчектә имам (төп ватаннан күчүчеләрдән булып Мамадыш авылыннан бабайлар унике кеше имам булып үткәннәр), бер китапчык төзедем, үз нәселләребез һәм кардәшләребезне аңлатып һәм ачыклап бирү нияте белән, бу китапка «Болгар һәм татар җирендәге төрле көрдләр һәм төркиләрнең хәлләреннән сайланма» дип исем биреп ... җыеп яздым». Автор кулъязмасының берничә урынында әсәрнең язылган (язып төгәлләнгән) елы – 1878 дип күрсәтелгән. Ул үзенең теркәгән сүзләрен-фикерләрен аралашкан даирәсенә сөйләп, карашларын уртаклашкан булуын, әңгәмәдәшләре хуплаганын да искәрткән: «сәламәт вакытыбызда халык белән сөйләшеп йөрелгән сүзләр ки, әмма сүземезне һәр дус-иш бик тә аңлап, канәгать булалар иде». Бу исә Минһаҗетдин мулланың

[25] Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар..., 2010. – Б. 18.

кызыксынуы һәм уйланулары, фикерләп нәтиҗәләр ясавы берничә еллык кына шөгыле булмаганын раслый.

Мулла Минһаҗетдин Сәйфулла улы Җәбәлинең, Бәчек авылының имамы булган хәлендә, мондый дәрәҗәдәге, аеруча җитди һәм киң мәгълүмат, тирән белем таләп ителгән хезмәтне язарга алынуы, һичшиксез, зур әһәмияткә ия.

Археограф һәм текстолог буларак, без үз тарафыбыздан, халкыбыз тарихына багышлап язылган хезмәтне матбугатта бастырырга алындык. Ә аның авторы – фидакяр җанлы татар укымышлысы Минһаҗетдин Җәбәлинең фикерләрен һәм тарихи карашларын тәфсилләп өйрәнү, тиешле фәнни бәяләмә бирү – әлбәттә, тарихчы галимнәр вазифасы.

Бу шәхеснең тормыш юлы һәм гыйльми мирасы киләчәктә галимнәр (тарихчылар, тел белгечләре) һәм төбәк тарихын өйрәнүчеләр тарафыннан җентекләп тикшерүгә лаек. Үзе дә мәдрәсәдә белем алган һәм укыту эше белән шөгыльләнгән кеше буларак, татарларда уку тәртибе турында ул язып калдырган мәгълүмат мәгариф һәм педагогика тарихыбыз өчен – шулай ук кыйммәтле ядкяр. Гомумән, халкыбызның тарихи карашларын, XIX гасырда татарларда тарих фәненең үсешен өйрәнү дәвамында Минһаҗетдин Җәбәли хезмәте, гәрчә китап рәвешендә басылмыйча калган булса да, һичшиксез, тикшерелергә һәм гыйльми бәясен алырга тиеш.

Бәчек авылына, Яшел Үзән төбәгенә һәм республикабызның Тау ягына бәйле замандашларыбыз үткәндәге тарихта Минһаҗетдин Җәбәли исемле якташлары булганлыгы белән горурланырга хаклы дип саныйбыз.

Үзе имамлык иткән Бәчек авылының зиратында Минһаҗетдин Сәйфулла улының кабер ташы сакланган дип әйтеп үткән идек. Анда мулла Минһаҗетдин мулла Сәйфулла улының 1893 елның 7 нче декабрендә, 54 яшендә вафат булганлыгы, 30 ел имам булып торганлыгы язылган. Ташъязмадагы мәгълүматка караганда, Минһаҗетдин Сәйфулла улы 1863 (яисә 1864) елдан алып Бәчек авылында имам вазифасын башкарган. Хәзрәтнең кабере янәшәсендә шундый ук шәкелдәге



*Минһаҗетдин Сәйфулла улының кабер ташы*

ташъязмада аның җәмәгате Ләйләҗамал Габделгалим мәзин кызының исеме уелган. Ләйләҗамал абыстай 1892 елның 22 апрелендә (ягъни, иреннән 1,5 ел алданрак) дөнья куйган. (Бу кабер ташында Габделгалим мәзиннең әтисе Нигъмәтулла мулла икәнлеге дә күрсәтелгән). Әлеге ядкярләрнең мәгълүматларын 2013 елның көзендә И.Һадиев белән бергә теркәп алган идек. Бу кабер ташларының фоторәсемнәре һәм тулы текстлары

Яшел Үзән районының ташъязма истәлекләренә багышланган китапта басылып чыкты[26].

Минһаҗетдин хәзрәтнең кабер ташында яше аермачык 54 дип уелган, ә вафаты теркәлгән метрика язмасындагы 56 дигән яше – һиҗри ел исәбе белән бирелгән (ягъни, һич тә хата түгел).

Тарихчы мулла Минһаҗетдин Җәбәли вафат булганнан соң аның улы Мөхәммәтпарса Бәчек авылында имамлык иткән. Ул исә 1871 елда туган, Казанда Габделгалләм хәзрәт Салихов (Күл буе) мәдрәсәсендә укыган, 1894 елның ноябрендә имам-хатыйп һәм мөгаллим вазифасына рәсми указ алып, совет чорына хәтле мулла булып торган. Бәчек авылында яшәүчеләр әйтүенчә, ул 1930 нчы елларда кулак итеп хөкемгә тартылган.

## Хезмәтнең исеме

Минһаҗетдин Җәбәли үз хезмәтенә нинди исем кую турында җитди уйланган. Кулъязмасының төрле битләрендәге (22а, 26б, 28а, 38б кәгазьләрдә) исем вариантлары, бөтенесен исәпләгәндә, барлыгы 9 төрле. Аларның өчесе кыскача, ә башкалары мөселман авторларының әсәрләре традициясен саклап, рифмалашкан рәвештә һәм гарәп телендә генә диярлек.

Вариантлар түбәндәгечә:

1) «Мөнтәхәбет-татар» (Татар тарихыннан сайланма; кулъязмада – 26б кәгазьдә);

2) «Болгар вә Казанда улан мөтәнәүвигъ татарлар хакан таифәсендән улуб, җөмләсе этракел-мөхтәлифәләрдүр вә замане сәгадәтдә дине ислам берлә мөшәррәф улдыкларун игълам идән мәдлүл ләүхел-мәзар фи арзыйль-хәзәр мин әл-болгар. Хакыйкател-Болгар әл-хакан әт-татар вә хакыйкатет-татар мин әл-этракь фи рәсмил-әхҗар рисалә[се]дүр» (Болгар һәм Казанда булган төрле татарлар хакан таифәсеннән булып, барчасы төрле төркиләр һәм пәйгамбәр заманында ислам дине

[26] Гайнетдинов А. Яшел Үзән районы эпиграфик истәлекләре. – Казан: ТР ФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих ин-ты, 2019. – Б. 27–28. Бу китапта Ләйләҗамал исеме, гарәп язуының кайбер орфографик үзенчәлекләрен белеп җиткермәгәнлектән, «Ләйлиҗамал» рәвешендә бозыбрак бирелгән.

белән хөрмәтләнгәнлекләрен белдергән, дәлилләгән, хәзәр җирендәге болгарларның зират ташлары);

3) «Мәдлүл ләүхел-мәзар әл-мәтрүк фи корбәти карьятил-хәзәр (вәл-хәзәр) мин арзыйль-Болгар вә хакыйкател-Болгар әл-хакан вәт-татар вә хакыйкатет-татар мин әтракь би-рәсмил-әхҗар әл-мәктүб би-рәсмил-Бәгъдад вәл-Госманийә вә көллүһүм мәктүб фи тарихи мийәтит-тисгыйә вәс-сәманийә» (Болгар җирендәге хәзәр авыллары янындагы ташландык зиратларның кабер ташлары дәлиле белән ныгытылган һәм Болгарның төркиләрдән булган хакан һәм татарларның Бәгъдад һәм госманлы язулары төрләрендәге (һәммәсе дә 900 һәм 800 һиҗри[27] еллардагы) ташъязмалары турында хакыйкать; 2 һәм 3 нче пунктлардагы вариантлар кульязмада – 28а кәгазьдә);

4) «Мөнтәхәб фи әхвали әкрядел-мөхтәлифә вә әтракел-мөхтәлифә фи арзыйль-болгар вәт-татар» («Болгар һәм татар җирендәге төрле көрдләр һәм төркиләрнең хәлләреннән сайланма»; кульязмада – 38б кәгазьдә). Бу исем варианты башта «Мөнтәхәб фи әхвалит-татар вә Болгар» (Татар һәм Болгар хәлләреннән сайланма) дип язылып, авторы тарафыннан сызылган;


5) «Тәварихел-Болгарийә вәл-хаканийә» (Болгарлар һәм хаканлылар тарихы);

6) «Болгар вә хакан татарларының замане сәгадәтдә ислам дине берлә мөшәррәф булдыкларун игълам идән мәдлүл ләүхел-кадим рисаләседүр» (Болгар һәм хакан татарларының пәйгамбәр заманында ислам дине белән хөрмәтләнгәнлекләрен белдергән, дәлилле, борынгы ташлар китабы);

7) «Болгар вә Казанда хакан татарларының замане сәгадәтдә ислам дине берлә мөшәррәф булдыкларун игълам идән мәдлүл ләүхел-кадим фи арзыйль-Болгар әл-кадим рисаләседүр» (Болгар һәм Казанда хакан татарларының пәйгамбәр заманында ислам дине белән хөрмәтләнгәнлекләрен белдергән, дәлилле, борынгы Болгар җирендәге борынгы ташлар китабы);

---

[27] *900, 800 һиҗри еллар* – миладе белән 1400, 1500 нче елларга туры килә.




*Китап исеменең вариантлары язылган 22а кәгазе*

8) «Болгар вә Казанда улан татарлар мөтәнәүвигъ вә җөмләсе әтракь вә хакан улуб, барчасы замане сәгадәтдә дине ислам берлә мөшәррәф улдыкларун игълам әйләгән мәдлүл ләүхел-мәзар фи арзыйль-хәзәр (ләфзыль-мәзар фи хәзәр вәл-Болгар) хакыйкатән әл-хакан вәт-татар рисаләседүр» (Болгар һәм Казанда булган татарлар күп төрле һәм бөтенесе дә төрки һәм хакан булып, барчасы пәйгамбәр заманында ислам дине белән хөрмәтләнгәнлекләрен белдергән, дәлилле, Хәзәр җирендәге зират ташлары (хәзәр һәм болгар сүзләре белән язылган) хакыйкатьтә хакан һәм татар китабы; 5–8 пунктлардагы вариантлар кульязманың 22а кәгазендә теркәлгән);

9) «Тәварихы Болгарийә вә татарийә» (Болгар һәм татар тарихы; кульязмада – 22б кәгазьдә).

Монда китерелгән бөтен төр атама вариантларының 1–3 саннары белән билгеләнгәннәре әсәр текстының I вариантында, 4 нчесе – II вариантта һәм 5–9 саннардагылары III вариантта теркәлгәннәр. (Алар бөтенесе дә текстның үзләре язылган урыннарында да бирелделәр).

Исем вариантларының өчесендә «Болгар вә Казан», сигезендә «болгар» һәм «татар» атамалары, алтысында «хакан», дүртесендә «төрки» һәм «ислам», өчесендә «хәзәр» сүзләре бар. Вариантларда иң күбе (13 мәртәбә) «Болгар» һәм «болгар» атамалары язылган.

Җәбәли әсәре исемнәренең озын вариантларыннан бишесендә борынгы кабер ташларының дәлиллек итүе күрсәтелгән. 3 нче пункттагы вариантта аларның бөтенесе дә һиҗри IX–X гасырларга (800 һәм 900 нче елларга), ягъни милади белән XV–XVI йөзләргә нисбәтле булганлыгы ачык әйтелгән. Хәтта кабер ташларының Бәгъдад һәм госманлы язулары үрнәгендә булганлыгы искәртелгән. Бу очракта автор гарәп язуының нәфис төрләреннән «нәсех» һәм «сөлес» дип аталганнарын күздә тоткан.

Беренче мәртәбә нәшер ителә торган бу басма өчен авторның «Тәварихы Болгарийә вә татарийә» дигән исем вариантын кулай дип табылды.

## Автор кулланган чыганаклар

Минһаҗетдин Сәйфулла улы әсәрен язганда күптөрле чыганаклар белән эш иткәнлеген белдергән. Ул иске зиратлардагы кабер ташларын тикшерүен, борынгы тел-сөйләмгә нигезләнүен, тарихи китапларны һәм белешмә хезмәтләрне кулланып, фикерләп, нәтиҗәләр чыгарып язганын әйткән. Ягъни, ул болай дигән: «Борынгы тарихтан иске зиратларда булган ташлар белдерүе буенча, иске сүзләр һәм тел буенча, татарларның сөйләшкәндә кулланган гыйбарәләр һәм сүзләреннән фикерләп, тарих китапларыннан һәм сүзлекләрдән, кайбер төрекчә тәрҗемәләрдән алып, төшенеп һәм фикерләп, җыеп яздым».

Җыентыкта, чынлап та, иске кабер ташларыннан, тел-сөйләм мисалларыннан, географик атамалардан, дини һәм фәнни китаплардан күчерелгән мәгълүматлар тупланган. Анда гарәп һәм төрек, татар телләрендәге ике дистәдән артык әсәр исемнәре бар. Алар: «Чыңгызнамә» («Дәфтәри Чыңгызнамә») исемле тарихи дастаннар җыентыгы, Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгарийә» китабы, фарсы тарихчысы һәм дин галиме Мөхәммәд Табарриның (839–923) «Тарихер-рөсул вәлмөлк» («Тарихе Табарри» дип тә йөртелгән) әсәре, Шәмседдин Хәлликанның (1211–1282) «Тарихе Ибне Хәлликан», Мөхәммәд Тәбризинең «Тибъян нафигъ» хезмәте, фарсы дин галиме Казый Бәйдави[28] әсәрләре, Рабгузиның 1310 (1311) елда иҗат ителгән «Кыйсасел-әнбия», госманлы тарихчысы Мостафа Гали әфәнденең (1541–1600) «Көнһел-әхбар»[29], госманлы

---

[28] *Казый Бәйдави* – фарсы дин галиме, казый. Коръән тәфсирчесе Наширеддин әл-Бәйдавиның (1319 елда вафат) «Тәфсире Казый» («Тәфсире Кадый Бәйдави») хезмәте телгә алынган. Бәйдави фикъһ, тарих, гарәп теле грамматикасы, тәфсир һ.б. буенча хезмәтләр язган. Тарихи хезмәтләреннән фарсы телендә язылган «Китабе низамет-тәварих» дип исемләнгәне дә булган, ул Иранның этник һәм милли тарихына багышлап язылган беренче китап булып исәпләнә.

[29] Госманлы төрек тарихчысы һәм шагыйре Гали әфәнденең (Гәлибулылы Мостафа Гали, 1541–1600) барлыгы 13 тарихи хезмәте билгеле. Шулардан иң мөһим, төп хезмәте – дөнья тарихына багышланган 4 томлык «Көнһел-әхбар» («Вакыйгаларның асылы») 1591 елда башланып 6–8 ел дәвамында язылган.

галиме Мөхәммәд Чокрыкчызадәнең (1623 елда вафат) «Алты бармак», төрек галиме Ибраһим Хаккыйның (1703–1780) «Мәгърифәтнамә», «Укъянус камусы», «Нисабел-интисар», «Миръател-кяинат» китаплары, шулай ук «Тәзкирәтел-хөкем табакател-өмәм», «Тәнбиһел-гафилин», «Гаҗаибел-мәхлукат», «Тарикател-гаҗаиб», «Нәтаиҗел-фөнүн», «Әхмәдия», «Шәрхе әрбәгыйн» һ.б. әсәрләр.

Болардан иң күп мәгълүмат «Миръател-кяинат», «Тибъян нафигъ», «Алты бармак», «Көнһел-әхбар», «Нисабел-интисар» китапларыннан алынган. Чыганаклардан күчерелгән өзекләрдә гарәп тарихчылары һәм галимнәреннән Әбү Исхак Истәхри, Ибне Әсир, Ибне Хәлликан, Ибне Шихнә[30] хезмәтләре дә файдаланылган булуы күренә. Мәсәлән, Ибне Әсирнең Болгар, Биләр, Саксин, Сарай һ.б. борынгы калалар турындагы мәгълүматлары бирелгән.

Автор кулланган «Нисабел-интисар» исемле, гарәп телендәге китаптан күчерелгән өземтәләр Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» хезмәтендә язылганнарга бик якын. Мәрҗани «Рисаләтел-интисаб» дигән китаптагы мәгълүматларга ишарә иткән. (Ул китапның авторы XVI гасыр галиме Гали Дәдә икән). Җәбәли кулланган китап шул ук әсәр булмаса да, элекке автор-

---

[30] *Әбү Исхак әл-Истәхри* (850–957) – гарәп географы, сәяхәтче. Якынча 951 елда «Китабе мәсаликел-мәмалик» хезмәтен язган. Ул гарәпләргә билгеле булган 20 икълимгә (өлкәгә) бүленгән. Бу әсәрнең гарәп телендә язылганы кыскачарак, ә фарсы телендәге вариантлары тулырак булуы мәгълүм. *Ибне Әсир* – тарихчы, дин галиме, биограф Гыйзеддин Әбелхәсән Гали ибне Мөхәммәд әл-Җәзәри (1160–1233, Ибне әл-Әсир буларак танылган). Дөнья яратылганнан алып 1230 елга кадәрге дәверне колачлаган «Әл-камил фит-тарих» исемле, гомуми тарихка багышланган хезмәтендә болгарлар, кыпчаклар, татарлар һ.б. күп халыклар телгә алынган. *Ибне Хәлликан* – Шәмсетдин Әбел-Габбас Әхмәд ибне Мөхәммәд (1211–1282) – мәшһүр гарәп тарихчысы, биограф һәм юрист. Аның тарафыннан 1254–1274 елларда язылган «Вафаител-әгъян вә әнбаү әбнаиз-заман» («Мәшһүр затларның некрологлары һәм замандашлары турында») китабы иң мәшһүр мөселман биографик энциклопедиясе булып санала. *Ибне Шихнә* – сүрияле хәнәфи галиме һәм мәмлүкләр дәвере тарихчысы Әбел-Вәлид Ибне әш-Шихнә (1348–1412).

лар да үзләреннән әүвәлгерәк чыганаклардан күчереп, бер төрле үк хәбәрләр кабатланган булуы гаҗәп түгел. Андый мисаллар М.Җәбәли кулланган башка китап өземтәләрендә дә бар.

Минһаҗетдин мулла кулланган китапларның хәзерге тарихи хезмәтләрдә исемнәре дә телгә алынмый торган кайберләре замандаш галимнәребезне кызыксындырырга мөмкин. Гомумән, мөселман цивилизациясенең X–XIV гасырлардагы югары күтәрелешкә ирешкән чорында гарәп галимнәренең, сәяхәтчеләренең хезмәтләре күптөрле халыклар (хәзәр, болгар, славян һ.б.) турында бик кыйммәтле һәм ышанычлы мәгълүматлар калдырганлыгы фәндә күптән танылган[31].

Тирән белемле Минһаҗетдин Җәбәли, дин әһеле буларак, дөнья яратылышын һәм тарихи үсешне, шул исәптән, төрки-татарлар тарихының борынгы дәверен төрки-татар һәм мөселман галимнәренең дини һәм фәнни әсәрләренә нигезләнеп тасвирлаган. Ул, гадәттә, чыганакларның исемнәрен, аерым очракларда ничәнче биттә икәнен күрсәткән. Иске китаплардагы кайбер мәсьәләләргә карата үз аңлатмаларын һәм искәрмәләрен дә өстәп язган.

Автор халык авыз иҗатына (бәетләргә, риваятьләргә) мөрәҗәгать иткән. Мәсәлән, «Болгар бәете» һәм «Казан бәете». Шулай ук ул алыпларга, авыл тарихларына һәм борынгы ташъязмаларга бәйле риваятьләрне кыскача теркәгән. Борынгы төрки телдәге һәм үз чордашларының әдәби әсәрләренә дә әһәмият биргән – «Бакырган китабы»ндагы шигъри әсәрне, рус-төрек сугышына бәйле шигырь текстын язып куйган. Фәхретдин хәзрәт Норлатыйның Гали ишан Түнтәригә багышлаган мәдхиясен телгә алган.

Минһаҗетдин мулла үзенә мәгълүм бөтен нәрсәне дә язып бетермәгәнлеге күренә. Мәсәлән, ул борынгы кала-

---

[31] Тарихчы Гайнетдин Әхмәрев бу хакта 1906 елгы бер мәкаләсендә үк бик ачык итеп язган (*Әхмәрев Г. Ватан вә милләт тарихы хакында // Казан мөхбире. – 1906. – 12 апр.; Шул ук // Гайнетдин Әхмәрев: тарихи-документаль җыентык / төз.: Р.Мәрданов, Р.Миңнуллин, Э.Сәлахова. – Казан: «Хәтер» нәшр., 2000. – Б. 189*).

шәһәрләрнең күп булганын әйтеп, һәммәсенең дә «исемнәрен язмадык» дип, искәртеп кенә үткән. Шулай ук, кулланган барлык чыганакларын да белдермәгән. Әйтик, Болгарга сәхабәләр килеп, ислам дине кабул итүне язганда нинди әсәргә таянганын күрсәтеп тормаган. Шулай ук, кайбер очракларда «җугърафийун» дип кенә телгә алып, географ һәм сәяхәтчеләргә ишарә иткән, ләкин тәгаен кемнәрнең хезмәтләре күздә тотылганын теркәмәгән.

Әсәр текстының берничә урынында, «рус тарих китапларында әйтелгән» дип, гомуми искәрткән. Чувашларның этногенезын һәм диннәрен өйрәнүгә руслар тарафыннан зур әһәмият бирелә дигән. Минһаҗетдин хәзрәтнең рус галимнәре һәм матбугаты язмаларыннан хәбәрдарлыгы аңлашыла. Ә Ерак Көнчыгыштагы – Амур буйларындагы – борынгы татарлар турында бәян иткәндә «Гатсук гәзитенең 1876 елгы 23 нче номеры»н төгәл итеп телгә алганлыгы – аның рус телендәге матбугаттан файдаланганын раслый. «Гатсук гәзите» дигәндә 1875–1890 елларда Мәскәүдә археолог һәм язучы А.А.Гатцук нәшер иткән «Газета А.Гатцука» күздә тотылган.

Гомумән, хезмәтнең авторы Минһаҗетдин мулла, мөмкин кадәре төрле чыганакларга мөрәҗәгать итеп, үзенең хасил булган фикерен башкаларга да җиткерергә тырышкан.

Аның аерым китаплардан күчергән өземтәләре шактый күләмле – берничәшәр кәгазьдә дәвам иткән. Минһаҗетдин Җәбәли төрле чыганаклардагы фикерләрне һәм өземтәләрнең кайберләрен үз хезмәтенә дәлилләр рәвешендә бирергә ниятләгәндер. Һәрхәлдә, аның үз тексты эчендә кулланылганнары да бар, «җыеп яздым» дигән сүзләренә дә игътибар итәргә кирәк. Шулай ук, күчермәләренең эчтәлекләре буенча фикер йөрткәндә, алардагы фактларны һәм дәлилләрне, нигездә, кабул иткән. Әмма һәммәсенә дә турыдан-туры иярмәгән, үзе килешмәгән урыннарга карата мөнәсәбәтен белдергән.

Бу китап ахырындагы, кулъязма тасвирламасына багышланган мәкаләдә Минһаҗетдин Җәбәлинең нинди китаплар-

дан нәрсәләр күчергән булуы турында тулырак мәгълүмат һәм кайбер өземтәләре дә бирелде.

Әйтеп үткәнебезчә, хезмәтнең авторы иске кабер ташларының мәгълүматларына аеруча зур әһәмият биргән. Гомумән, Минһаҗетдин Җәбәли тарихи хезмәт язуның методологиясен яхшы күзаллап, аны гамәлдә кулланган.

### Әсәрдә нәрсәләр тасвирланган

Минһаҗетдин Җәбәлинең кулъязма җыентыгы безнең көннәргә кәгазьләре таркалган һәм үзара буталган, күпмедер өлеше җуелган рәвештә килеп җиткәнлеген тагын бер искәртик.

Кәгазьләрнең урыннарын текст эчтәлегенә һәм мәгънәсенә күрә урнаштырып, башлангычтагы дөрес һәм эзлекле тәртибен торгызырга тырыштык. Нәтиҗәдә, җыентыкның яртысына якын өлеше авторның үз иҗаты, ә яртысыннан күбрәге төрле китаплардан күчермәләрне һәм өземтәләрне тәшкил итүе ачыкланды.

Авторның үз хезмәте өч варианттан тора. Соңгысының кыскача башлам өлеше генә сакланган.

Җыентыктагы текст өлешләрен вариант дип атавыбыз, әлбәттә, бик шартлы гына. Чөнки беренче вариант текстының эчтәлек тәртибе тотрыксыз, урыны-урыны белән ул аерым мәсьәләләрне теркәп кую, темага кагылышлы чыганакларның конспект кебек күчермәләре рәвешендә һәм үзара бәйләнешләре дә ачык кына күренми. Әлеге текстта кайбер нәрсәләр кыскача, схематик рәвештә генә телгә алынган. Мәсәлән, анда С.Бакыргани шигыренең дүрт юлы гына теркәлгән булса, II вариантта ул тулы (барлыгы 15 дүртьюллыктан тора). Шулай ук, беренче вариантта «Казан бәете»нең ике юлы гына, ә икенче вариантта күбрәк язылган. Боларга охшаш – кыскалык һәм тулылык мисаллары тагын да бар.

Күпчелек мәсьәләләр ике текстта өлешчә кабатланса да, беренче вариантта гына теркәлгән, әмма икенчесендә булмаганнарын да күрергә мөмкин. Мәсәлән, I вариант-

та Минһаҗетдин хәзрәт үзенең нәсел буыннарын тулырак (Минһаҗетдин – Сәйфулла – Мөхәммәтшәриф – Гаделшаһ – Габдрахман) язган, ә II вариантта ул үзенең һәм әтисенең исемнәрен күрсәтү белән чикләнгән. «Бу урынга Болгар бәете язылачак» дигән автор искәрмәсе дә II вариантта юк. Татарларның Бохара, Сәмәрканд, гомумән, Урта Азия мәдрәсәләрендә белем алып, үз туган җирләрендә мәгърифәт тарату белән шөгыльләнүләре турындагы җөмләләр I вариантта гына бар. Татар халкындагы уку-укыту тәртибен тасвирлаган өлешенең урыннары төрлечә: I вариантта ул текст башында булса, II вариантта иң ахырда. Әйткәнебезчә, текстның эчтәлек эзлеклелеге (I вариантта) тотрыксыз. II вариантта берникадәр тәртипкә китерелгән, ә III вариантта алдагы икесенең кыскартылган сөземтәсе кебек һәм анда ташъязмалар турында күбрәк язылган. (Бу текст тулы түгел).

Искәртеп узганыбызча, Минһаҗетдин Җәбәли җыентыгында автор хезмәтенең каралама текст өлешләре бер-берсен тулыландыра һәм аларның берсе дә иң ахыргы – акка күчерелгән нөсхә түгел. Моның шулай икәнлеген безнең тарафтан шартлы рәвештә II вариант дип билгеләнгәнендә Гали ишан Түнтәригә багышланган мәдхия тексты бирелергә тиешлеге турындагы искәрмә күрсәтеп тора. Ягъни, искәртелеп, ишарә генә ителгән, ә шигъри тексты юк.

Автор язганнарны гомумиләштереп әйткәндә, борынгы төрки-татарларның төп ватаннары, килеп чыгулары, яшәгән һәм биләгән урыннары, аларның ислам динен кабул итүләре тарихына зур әһәмият бирелгән. Хәзәрләр, Болгар дәүләтенең чикләре һәм аның халкы, Болгарда һәм Казан ханлыгындагы төрле халыклар, аларның тел-сөйләм үзенчәлекләре кебек, күптөрле мәсьәләләр тасвирланган. Автор төрле халык вәкилләренең бер-берсен ничек дип атауларын, бигрәк тә Идел буе татарларын күрше халыклар һәм Урта Азиялеләр кем дип йөртүләрен тәфсилләп язган. Минһаҗетдин хәзрәт Идел буенда яшәгән чувашларның һәм фин-угор халыкларының татарларга якын нәселдәш-тармаклар икәнлеген һәм барысының да

әүвәл мөселман булып, Казан ханлыгы басып-яулап алынганнан соң гына мәҗүсилеккә төшкәннәрен язган. Фикерләрен раслау өчен әлеге халыкларның кием-салым, тел-сөйләм һ.б. күрсәткечләрен дәлил итеп китергән. Шулай ук чуваш авылларының зиратларында мөселман каберләренә гарәп хәрефләрендә язып куелган борынгы ташлар сакланган булуына игътибар юнәлткән.

Дөнья һәм төрки-татар тарихын Минһаҗетдин Җәбәли, күптөрле чыганакларга нигезләнеп, мөселман тарихы белән бергә үргән. Ул иң әүвәлге Адәм пәйгамбәрне, шулай ук Нух, Салих һәм Мөхәммәт пәйгамбәрләрне, Гомәр хәлифәне, сәхабәләрне телгә алган, аларга бәйле кайбер хәлләрне хикәяләгән, гъад кавеме, яэҗүҗ-мәэҗүҗләр, Искәндәр Зөлкарнәйн (Руми) вакыйгаларын бәян иткән.

Борынгы Татарстан («Татарстане кадим») җиренең башлангычта төньяк Кытайда булып, аннан Амур елгасының Татар бугазына койган җиреннән, Магул, Чин-Мачин, Кашгар, Тибет, Һиндстан, Туран, Әфганстанга һ.б. таралганын-җәелгәнен язган. Төрки-татарларның Көрдестанга, Мисырга, Йәмәнгә, Европаның көньяк-көнчыгыш тарафына, рус җиренә кадәрге киңлекләрне биләгәнен әйткән. Хәтта татарларның бер өлеше Татар диңгезен кичеп, Япониягә, инглизләр идарәсендәге Төньяк Америка мәмләкәтенә дә барып җиткәнен язган. Шул рәвешчә, М.Җәбәли хезмәтендә төрле ил-дәүләтләрдәге шәһәр-калалар һәм дистәләрчә елга исемнәре дә теркәлгән.

«Борынгы Татарстан» турында тәфсилләп язганда Минһаҗетдин мулла, үзе дә дин әһеле буларак, суфичылыкның мәшһүр затларыннан Сөләйман Бакырганиның тантаналы рухлы «Шәйхем Әхмәд Ясәви» шигырь-хикмәтен күчереп урнаштырган.

Әсәрнең авторы Болгар дәүләтендә һәм Казан ханлыгында төрле төрки халыклар – татар, чирмеш, чуваш, мукшы һәм арлар – бергә яшәгәннәр дип кабатлаган. Башкорт, мишәр, төмән, кыргызлар, Төркестан да бер заман Болгар хөкүмәтендә торган, Болгар җире киң мәмләкәт булып, Кавказ тауларыннан алып, Боз

диңгезенә һәм Себергә кадәр җәелеп, Хәзәр вилаяте дип аталган, аның халкын төрле төркиләр тәшкил иткән, дип язган. Болгар иленең элеккедән баш калалары Сарай, Сәмәндәр, Хәзәр, Казан һ.б. шәһәрләр булган, хәзерге заманда Болгар җирендә бихисап шәһәр-кала урыннары билгеле дип, һәммәсенең дә исемнәрен язып тормавын искәрткән. Шулай да, Тау ягындагы берничә борынгы кала урыны турында мәгълүмат теркәп калдырган.

Минһаҗетдин хәзрәт кешелек дөньясының тарихы күптәннән дәвам итүен әйтеп, остазының сүзләрен искә алган: «Бу дөньяның әүвәлен белгән кеше юк. Түнтәрнең ишан хәзрәттән ишеткән идек – бу дөньяда адәм исемендә күп адәм булып үткән, бу дөнья ничә миллион еллар дәвер иткән дип исбатланган, әмма барлыкка килгән заманы һәм тарихы юк».

Хезмәтнең авторы борынгы алып кешеләр турында язганда, аларның Болгар җирендә дә булганын, хәзер дә сөякләре табылуын (мәсәлән, Күгеш һәм Әлмән авыллары янында) әйтеп, «Болгар вилаятендә Адәм пәйгамбәр заманында ук кешеләр торган. Болгар – бик иске шәһәр» дип белдергән. Шулай ук болай язган: «Болгар нам шәһәре кадим Салих пәйгамбәр өммәте булуб, соңра хәзрәти рәсүлгә иман килтүрүб, бер заман Искәндәр Руми тәхте тәсаррыфында булуб, нәчә йыллар мөэмин булуб әүкате гөзар итмешләрдүр». Тарихи каланың гомерен ул хәтта болай дип белдергән: «Болгар өч мең елга якын заманнан бирле бар шәһәр». «Миръател-кяинат» китабыннан күчерелгән өлешендә Нух пәйгамбәр токымыннан Яфәснең улы Гуз (Угыз) Болгарга килеп биналар төзүе турында язылган.

Тарихи чыганаклардагы «сакъләб» (сәкалибә) дип аталган халыкның кемнәр булганлыгы турында фикер йөртеп, Минһаҗетдин Сәйфулла улы «Рәддел-мохтар» китабында Болгар шәһәрен сәкалибә төзегәнлегә мәсьәләсенә карата «Без – татарлар, Болгар шәрифне татарлар төзегәнен бик хуш беләбез» дип ачыклык керткән.

Сүз уңаеннан, Минһаҗетдин хәзрәт татарларда диннең зәгыйфьләнүен, Казан, Уфа һ.б. тарафлардагы мөселманнар белән чагыштырып, үз якташлары – Тау ягы татарларында

дингә мөнәсәбәт тиешенчә үк түгеллеген искәртеп тә үткән. Бу мәсьәләдә ул, күрәсең, үзе искиткеч укымышлы һәм тәҗрибәле имам буларак, аеруча таләпчәнлек күрсәткәндер.

Минһаҗетдин Җәбәли Болгар һәм Казан ханлыкларында яшәгән халык барысы да төркиләр булып, аларны «хәзәр» (хәзәзийан) исеме белән атаганнар дип язган. Болгар мәмләкәтенә төрле кавемнәр дә кушылып, алар төп халык арасында үзләшкәннәр дигән. Мәсәлән, Искәндәр Руми белән бергә килгән европалылар, Гомәр хәлифә заманында ислам диненә дәгъвәт иткән гарәпләр, аннан соң шул ук максат белән килгән гарәпләр һәм төрекләр, Әфридун заманында (X гасырда) Болгар иленә аяк баскан фарсылар, берничә гасыр соңрак пәйда булган монголлар һ.б. Ул чуваш, чирмеш, ар, мукшылар барысы да төркиләр дип белдергән, гъад кавеме дип тә язган. Көрдләр – алар башкордлар, алар – гъад кавеме дигән сүзләре дә бар.

Ул Болгар дәүләтендә яшәүчеләрнең ислам динен кабул итү вакыйгасына зур әһәмият биргән. Борынгы язма чыганакларга нигезләнеп, Болгар дәүләтенең хак Аллаһы Тәгаләгә иман китерүенең өч дулкын рәвешендә булганын (Салих пәйгамбәр вакытында, Искәндәр Зөлкарнәйн тарафыннан һәм һиҗри 9 елда сәхабәләрнең Идел буена килүенә бәйләп) фаразлаган һәм дәлилләргә омтылган. «Алты бармак» китабында тасвирланган, Мөхәммәт пәйгамбәргә бәйле вакыйганы искә алып, «Җабәлкаһ» дигән борынгы кала Болгар шәһәре булган, Кавказ аша үтеп кергән гарәп гаскәренең хәзәрләр белән (Турханга каршы) сугышы Тау ягында узган дип тәңгәлләштергән. Моңа дәлил итеп Бәчек авылы янында гарәп гаскәренең чатырлар корып торган «Тугыз түбә» дип аталган, Төрләмәс авылының «Турхан басуы» дип йөртелгән борынгы урыннарын искә алган.

Идел буе Болгар дәүләтендә яшәгән халыклардан чувашлар, чирмешләр, мордвалар, удмуртларның да әүвәл мөселман булганлыгын, Казан ханлыгы җимерелгәннән соң гына аларның мәҗүсилеккә дүнгәнен тасвирлаган.

Автор чувашларның үткәне һәм аларның диннәре, теле, горефләре турында шактый язган. Аларның борынгы заманнан ук мөселман булып, XVI гасыр уртасыннан – Казан ханлыгын руслар яулап алган чордан, ислам динен тота алмыйча һәм чукындырылмаган хәлдә, тәмам мәҗүсилеккә төшеп бетүләрен бәян иткән.

Минһаҗетдин мулла чуваш авыллары янындагы элекке, ташландык зиратларда ислам динен тоткан вакытларындагы, Коръән сүзләре уелган ташъязма истәлекләрне үз карашына төп дәлил итеп китергән. «Чувашлар зиратларын күреп бик елаучылары бар. Кайбер түбән кеше аларны чын христиан дип белә. Аларда христианлык та, мөселманлык та һәм яһүдлек тә юк. Мәҗүсилектән башка мәгънәләре юк. Гъад заманындагы халәтләренә кире кайтып, мәҗүси булып калганнар. Ләкин алар исламга бик сәләтле. Хан заманында чуваш һәм чирмешләр, мукшылар һәм удмуртлар – һәркайсы мөселман булганнар. Аларның мәҗүсилекләре дүрт йөз ел вакытында».

Автор үз чорында – XIX гасырда православие миссионерлары тарафыннан тәкрарланган – чувашларның татарларга һәм мөселманлыкка бернинди бәйләнеше булмаган, алар бөтенләй башка халык дип белдерүләре белән килешмәгән. Ул болай язган: «Руслар белмиләр – чуваш халкы хан заманында татарлар кебек мөселман булганнарын, руслар әйтәләр: «Хәзер генә фәлән татар авылы чувашдан татар булган», – дип әйтәләр. Тагын да соңрак әйтерләр – «Барча татар чувашдан», – дип. Инде без – мөселман татарлар әйтәбез: чувашлар бөтенесе татардан дип һәм бөтенесе төрки (хәзәр, хәзәз, фәгъфуре Чин, вә хакан) халкы, Болгарның төп халкы! Электән мөселман булганнар, мең ел мөселман булып торганнарын искә алынган ташлар әйтә. Һәм тагын да фигыльләре һәм киемнәре әйтә. Күптән түгел аларны рус көчләп христианлаштырмакчы булып, мәҗүси ясап киткәннәр. Хәзер русның исенә төшкән христиан кылу нияте, чувашларның исенә төшкән ислам нияте. Чувашлар әйтәләр: «Безнең бабайлар барчасы хан булганнар, – дип, – һәм мөселман булганнар», – дип».

Китерелгән өземтәдән күренгәнчә, хезмәтнең авторы «татар–төрки–хәзәр–хәзәз–хакан–Чин халкы»ның асылда бер үк булганын таныган. Ул синоним сыйфатында язган мондый тезмәләрдәге халыкларның бөтенесе дә төрки дигәнне күздә тоткан һәм бер үк мәгънәне белдергән сүзнең төрле чыганакларда төрлечә аталганына ишарә иткән. Кайбер очракларда автор ул мәсьәләне «География белгечләре һәм тарихчылар Болгар халкына «хәзәзийан» дип әйткәннәр» рәвешендә искәрткән.

Минһаҗетдин Җәбәли Идел буе халыкларының берлеге турында күп язган. Ул, Болгар-Казан дәүләтләрендә яшәгән халыкларның телләре дә элек бер булган дип, дәлилләрен китергән. Мәсәлән, «Хан заманында – Болгар һәм Казан хөкүмәте заманында татарлар һәрбер төре белән Рум җирендәге һәм Кырым, Кавказ халкы кебек сөйләшкәннәр. Чөнки Болгар халкы барысы төрле көрдләр һәм төркиләр ки, кием-салымда һәм сөйләмдә, йорт-җир әйберләрендә асыл төркилекләре күренә. Хәзерге вакытта Казан татарларының иске һәм борынгы телләрендә чуваш, чирмеш, мукшы, ар халкы сөйләшәләр. Борын заманда, хан заманында һәркайсы чуваш киеме һәм теле кебек булганнар». Димәк, аның фикеренчә, ул әйткән күрше-тирә халыкларның сөйләм теле Казан татарларының элеккеге теле булган.

Автор шулай ук Казан артындагы һәм Тау ягындагы борынгы авылларның исемнәрен мисалга китереп, этимологияләренә игътибар биргән. Аерым алганда, «ширмә» сүзенең нәрсәне белдергәнен һәм бу компонент кергән авыл атамаларын аңлаткан. Аның хезмәтендә гомумән 70-тән артык авыл исеме телгә алынган. Аерым төбәкләрдәге[32] татарларның сөйләм теле дә бер генә төрле түгеллеген искәрткән: «Әгәр дә асыл төрки китапларын күрмичә торып, наданлыкта калсалар, йөз елда тәмам телләре башкага әверелеп, татарлыктан чыгып,

[32] Татарларның тел-сөйләм мәсьәләсен язганда авторның бу хезмәтеннән бер гасыр элегрәк гамәлдән чыккан административ берәмлекләрне (Алат, Гәлеч, Арча, Җөри һәм Нугай юлларын) санап үтүе дә кызыклы.

башка кавем булып беленерләр иде, бу заманда чуваш халкы хакыйкый төркиләрдән була торып та, башка кавем һәм башка халык булып күренгәне кебек. Чынлыкта, алар хан заманында мөселман булганнар». Авторның шулай ук үз чорындагы мөселман татарларга карата «диндә бик чыдамлы булмасалар, бара-бара һәммәсе мәҗүси кебек булырлар» дигән фикере дә шуңа аваздаш. Мондый сүзләре белән Минһаҗетдин хәзрәт китапның, телнең һәм диннең үз чорында милли-мәдәни җәһәттән берләштерүче төп чара икәнлеген белдергән.

Минһаҗетдин Җәбәли тел мәсьәләләренә аеруча әһәмият биргән, ул үз заманы өчен яхшы белемгә ия лингвист һәм ономастика белгече буларак та күзаллана. Җәбәли үз тәҗрибәсенә нигезләнеп, телнең тарихи үсешен һәм үзгәрешләргә дучар булуын аңлатырга тырышкан. Төрле телләрне чагыштырган, татар телендәге алынма сүзләргә, архаизмнарга, җирле сөйләшләргә хас мәсьәләләргә, этимологиягә тукталган. Фикерләрен раслау өчен мисаллар һәм дәлилләр китергән. Ул төрле телләрдәге аерым гыйбарәләрне чагыштырган, төрек теле белән уртаклык мисалларына тукталган. Чуваш теленең госманлы төрек теленә охшашлыгын искәрткән. Гади халык сөйләмендәге һәм архаиклашкан сүзләрне, сүзтезмәләрне искә алган, татар телендәге кайбер алынма сүзләрнең нинди телдән кергәнлеген (мәсәлән, фарсы, монгол, гарәп һ.б.) аңлаткан. Төрле халыкларда әүвәлге кием-салым төрләренең ничек аталганын санап үткән. Үзенең фикер-карашларын дәлилләү өчен ул ономастикага мөрәҗәгать итеп, географик атамаларга, авыл һәм кеше исемнәренә игътибар юнәлткән.

Минһаҗетдин Сәйфулла улы язган хезмәтнең теле үз чорына – XIX гасыр өчен – хас булган фәнни китаби өслүбтә. Тексты урыны белән катлаулы – гарәп сүзләре аеруча күп кулланылган, берникадәр госманлы төрекчәрәк (бусына үзе кулланган төрек телендәге китаплар тәэсире дә булгандыр), кайчакта исә гади татар телендә бәян ителгән. Үзенең дә төрле телләрне (татар, чуваш, гарәп, фарсы, госманлы төрек, рус һәм, ихтимал, башкаларны да) белгәнлеге, язма теленең

фикерне белдерү-аңлату, дәлилләү һәм раслау хасиятләренә ия булганлыгы аңлашыла. Автор төрле төбәкләрдә яшәгән башкорт халкының сөйләмнәрендәге аермаларны да искәртеп үткән. Хезмәтенең текстында синоним сүзләрне янәшә тезеп китүе шулай ук аның тел байлыгын күрсәтә. Мәсәлән, җөмләләр эчендә бер үк сүзнең төрле синонимнарын: авыл – карья – гөй, шәһәр – биляд – кальга, нәүбәт – чират – кизү, таг – даг – тау, сагъ – сәламәт – таза; ел – сәнә рәвешләрендә язган.

Минһаҗетдин хәзрәтнең кайбер русча гыйбарәләрне гарәп хәрефләре белән кулланганы күренә. Мәсәлән, «Татарыски пырлиуф» (татарский пролив), «язычнуй биры» (мәҗүси диндә), бу соңгысында русча «вера» дип тә өстәгән. Шулай ук ул кулъязманың берничә урынында үз исемен русча язып куйган.

Хезмәт авторының Аксак Тимер турындагы фикерләре татарлар арасында укылган элеккерәк әсәрләрдән аермалы. Ул, мәсәлән, «Чыңгызнамә»дәге елъязмаларның иң беренче хәбәре булып килгән «тарих йите йөз елда ирде, Аксак Тимер шәһри Болгарны алды...» дип башланганча язмаган[33]. Шул ук «Чыңгызнамә» китабындагы Аксак Тимер дастанында бу шәхеснең ислам динен көчәйтүче итеп тасвирлануына да, Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария» әсәрендәге шундый ук рухтагы уңай персонаж итеп хикәяләнүенә дә Минһаҗетдин мулла иярмәгән. Аның Аксак Тимергә мөнәсәбәте бик тискәре: «һиҗри сигезенче (милади XIV) гасырда фетнәсе булып, Аксак Тимер үзбәк шәһәрләрен җимергән, юк иткән. Шул заманда беткән мөселманнарның хисабын Аллаһы Тәгалә үзе генә белә. Болгарның ничә мең шәһәрләрен һәм авылларын һәлак итеп киткән», дигән һәм аны «бинур Тимер», ягъни «нурсыз, имансыз» дип тә атаган.

Әсәрдә Казан шәһәре турында мәгълүматы бик аз гына:

---

[33] Бу әсәрнең 1822 елгы беренче басмасын хәзерләгән Ибраһим Хәлфин дә кулъязма күчермәләрдәге «тарих йите йөздә» дигәнгә үзеннән өстәп «сикез йөздә» дип искәрткән булган.

анын яулап алынуы турында кыскача әйтеп үткән, «Казан бәете» өзеген теркәгән, Казан шәһәрендә ханлык чорыннан калган манара хәзер дә бар дип, Сөембикә манарасын искә алган.

Хезмәтнең авторы үз чордашларыннан кайбер надан кешеләрнең «мин – татар!» дип мактануы мәсьәләсенә дә тукталган. Ул «татар» атамасының Русиядә «мөселман» дигән мәгънәгә тәңгәлләштерелүе турында язган. Ләкин мондый карашның ялгыш икәнлеген, мөселман дигән төшенчәнең мәгънәсе киң булуын аңлаткан. «Кирәксә француз халкыннан булсын, кирәксә гарәп милләтеннән булсын, кирәк рус таифәсеннән булсын һәм кирәксә чуваш булсын – безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд мостафа һәммә җиһан әһеленә гомуми пәйгамбәр»[34] – дип язган.

Минһаҗетдин Җәбәли үзе гомер кичергән Тау ягындагы Бәчек һәм кайбер башка авылларның нигезләнү тарихлары турында да фикерләр теркәп калдырган. Үзе имам булып торган Бәчек авылы зиратындагы борынгы ташъязма истәлеккә бәйләп, ул авылның нигезләнүе турында да кыскача мәгълүмат теркәгән. Әлмән, Кармыш, Бәчек – өчесе дә ханның биләреннән булганнар, һәм шул ук исемнәрдәге авылларны нигезләгәннәр дип язып калдырган. Бәчекне нигезләгән Бичек би, Күз би, Мулла бабай, Дүскә бабай башта «Иске йорт»та – тау башындагы имәнлек урманында урнашканнар дип язган. Бәчек авылы атамасын ул, авылны нигезләгән кеше Болгар ханының

[34] Авторның бу фикере Ш.Мәрҗанинең «Татар булмасаң, гарәп, таҗик, нугай түгел, кытай, рус, француз һәм немец та түгел, инде кем булырсың?» (*Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар..., 1989. – Б. 44*) дигәненә охшаш. Җәбәли, үз нәүбәтендә «мөселман» төшенчәсенең мәгънәсе киң булуын белдергән, ә Мәрҗани халыкның «татар» дигән атамасын аңлаткан. Ике авторның да башка милләтләрне мисал итеп, полемика ысулында дәлилләү рәвеше, күрәсең, халык атамасының дөрес билгеләнеше ул чордагы татар укымышлылары арасында көнүзәк мәсьәләләрдән берсе булып, бәхәс-әңгәмәләрдә кулланылгандыр. Чордашлары Х.Фәезханов та «татар» һәм «мөселман» атамаларының дөрес кулланылмавына борчылуын белдергән ([*Фәезханов Хөсәен*]. *Кыскача татар тарихы..., 2011. – Б. 15)*.

якын күргән биләреннән берсе булып, ханның «Бичегем» дип әйтүеннән килеп чыккан, дип аңлаткан. Шул ук авылның зиратындагы кабер ташына Бәчүкә исеме уелган дип тә язган һәм аны «безнең Бәчек бинең ташы» дип атаган.

Бу авылның тарихы турында Каюм Насыйри язганнар бераз башкачарак. Ул болай дигән: «Бәчек авылы дәхи күптәнге авылдыр. Иң әүвәл бу Бәчек авылына Болгар яки Биләр шәһәре тарафыннан өч кеше килеп утырганнар. Алар: Бәчек баба, Әнчек баба, Янчек баба – агай-эне улганнар. Олугысы Бәчек диерләр икән»[35].

Җәбәли, гомумән, бөтен дөнья географиясе һәм тарихы турында да язган. Мәсәлән, «География галимнәре сүзенчә, дөнья туп кебек йомры һәм биш кыйтгага (материкка) бүләләр: Азия, Африка, Америка, Европа һәм көньяк Һиндстан – Австралия һәм башка утраулар күп». Аның кулъязма җыентыгында җир йөзендәге материклар, алардагы ил-дәүләтләр турында кыскача тарихи, географик, дини, сәяси һәм статистик мәгълүматлар да теркәлгән.

Минһаҗетдин Җәбәли тарихи хезмәтенең хәзергәчә килеп ирешкән каралама тексты эчтәлегенең төп өлеше – кыскача күздән кичергәндә, югарыда тасвирланганнардан гыйбарәт. Автор язган тарихи вакытның әүвәлге чиге – иң борынгы заманнардан алып, ахыргы чиге – XIX гасырның 1870 нче еллары белән төгәлләнгән. Ул шушы киң вакыт арасындагы бөтен заманнарны да тасвирламаган, әлбәттә, күбрәк игътибары борынгы дәвергә юнәлтелгән. Хикәяләгән мәсьәләләре кызыклы һәм мавыктыргыч.

Тарих кебек аеруча катлаулы темага хезмәт язган авторларга хас булганча, М.Җәбәлинең дә каршылыклы фикерләре бар. Мәсәлән, төрле чыганакларга ияреп текстның бер урынында Болгар шәһәрен Искәндәр Руми төзегән дип язса, икенче урында аны татарлар төзегән,

[35] Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре..., 1926. – Б. 47; Каюм Насыйри: әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык..., 2017. – Б. 264.

ди. Шулай ук, хезмәтнең авторы Мөхәммәт пәйгамбәрнең мигъраждан кайтканда Җабәлкаһ каласы халкын иманга китергәнлеген «Алты бармак» китабына нигезләнеп хикәяләгән һәм шул каланы Болгар шәһәре дип фаразлаган. Аларның гъад кавеменнән булганын һәм Салих пәйгамбәр вакытында иманга килгән булулары турындагы сүзләр дә «Алты бармак»тан алынган. Әмма шунысы бар – «Алты бармак»ның авторы өчен дә чыганак булып хезмәт иткән борынгы дәвер китапларында (мәсәлән, Табарри әсәрендә) мөселман гарәпләр өчен көнбатыш белән көнчыгыш (мәгъриб һәм мәшрикъ) хәзерге географик киңлек масштабында күзалланмаган, ә Гарәбстан ярымутравының ике тарафындагы төбәкләре (Азиянең чагыштырмача якынрак өлеше һәм төньяк Африканың Мисырдан көнбатыштагы тарафы) күздә тотылган. Шуны да әйтергә кирәк, башка авторларда Болгарны Җәбалкаһка тиңләштерү юк. Алай да, ул шәһәрнең зөбәрҗәттән төзелгәнлеге турындагы борынгы китапларда язылган мәгълүматка күрә, шәһри Болгар бәетләренең берсендәге «Гәүһәр Болгарга килдем, якут Болгарга килдем...»[36] дигән сүзләре уйландырырлык.

Автор текстында башка төрле географик хилафлыклар да бар. Мәсәлән, Кавказдагы «алан» атамасын Балтыйк буендагы шундый ук исем белән тәңгәлләштергәне күренә. Шулай ук, Хәзәр дәүләтенең Каспий һәм Кавказга якын тирәләрендәге тарихи вакыйгаларны Болгар җирлегенә (аерым алганда, Тау ягындагы Бәчек, Төрләмә авыллары тирәсенә) «күчергән».

Хезмәте исеменең вариантларында Мөхәммәт пәйгамбәр заманында ук ислам динен кабул итүләрен раслый торган борынгы кабер ташлары турындагы автор сүзләре шул ук – үзе фаразлаган Җабәлкаһ вакыйгасына бәйле. Ләкин текстында телгә алынган кабер ташлары XV–XVI гасырларга гына карый, алардан борынгыраклары әйтелмәгән. Минһаҗетдин

[36] «Гәүһәр Болгарга килдем...»: тарихи бәетләр..., 2013. – Б. 62.

Җәбәлинең Тау ягындагы мөселманнарның бик борынгы чорда (хәтта Мөхәммәт пәйгамбәрнең үз дәгъвәте белән) изге дингә кергәнлекләрен язуының асыл максаты – бу әсәр иҗат ителгән чордагы империянең ачыктан-ачык христианлаштыру сәясәте шартларында нәфрәтнамә сыйфатында булганлыгы белән аңлатыла.

***

Татар халкының һәм Тау ягы төбәгенең тарихи үткәне белән кызыксынуда, аны өйрәнүдә М.Җәбәли хезмәтенең якташы һәм чордашы Каюм Насыйри язганнар белән уртаклыклары бар. Шул уңайдан К.Насыйриның фәнни мирасына бәйле бер мәсьәләгә тукталабыз. Мәгълүм булганча, Тау ягы авыллары тарихы буенча Каюм Насыйри бай мәгълүмат туплап калдырган. Аның «Зөя өязе авыллары» исеме белән беренче мәртәбә 1926 елда басылып чыккан хезмәтенең автор кулъязмасы хәзергәчә сакланган. Насыйри әлеге мәгълүматларын дистә еллар дәвамында туплаган. Алар бөтенесе галимнең бер кулъязма җыентыгында булып, һәр авыл турында кабатлап һәм өстәп язылган. Мәсәлән, Бәчек турында баштагы кечкенә генә язма арттырыла барып, бу авыл Насыйри кулъязмасында өч мәртәбә теркәлгән. Башка авыллар да, нигездә, икешәр-өчәр тапкыр язылган. Әлеге текстларда бер-берсен тулыландыра торган мәгълүматлар да күренә.

Аның кулъязмасында Зөя өязендәге татар авыллары тарихына кереш сүзе дә булганын күрәбез. Әмма ул 1926 елгы басмада бирелмәгән һәм, К.Насыйриның аннан соңгы җыентыкларына да шул – беренче басма нигез итеп алынган булуы сәбәпле, мәкалә авторның кереш сүзеннән башка гына һәм 1551 елда Зөя каласының төзелүе турындагы язма белән башланган рәвештә чыгып килде. Гәрчә, безнең карашыбызча, автор кулъязмасындагы мәгълүмат бик мөһим. Шул сәбәпле, Каюм Насыйриның «Зөя өязе авыллары тарихы»на язган кереш сүзен монда өлешчә күчереп бастырабыз.

«Мөкаддимә – сүз башы.

Моңарчы мең дә сигез йөз илле бишенче елдан бирле һәрбер ишеткән вә сөйләшкән иске вә кадимге риваятьләрне җыя килгән идем. Имди быел моны тәмам кыйлырга бигрәк сәбәп: Зөя өязендәге мөселман авыллары хосусында «Казанский ведомость»ларның бәгъзе номерларында мөселманнарның риваятенә күрә хилаф күренәдер – ничек язсалар да, үзләренең сулышына күрә (ике тарафның берсен ригая кыйлыб)[37] язалар. Мәсәлән, Норлат авылында Касыйм вә һәм Әбүгаликъ дигән кемсәнәләр мөселманнар арасында ничә бабалардан бирле «газизләр» дип ишетелә килгән, әмма мәзкүр ыстатьяләрдә күренәдер – гүя алар юл кисүче угрылар булган, имеш. Ни язсалар да, язалар, игътираз кыйлган кеше юк. Һәммәсе дә төпле сүз түгел. Халык авызындагы сүзне табарга бик читен. Ул язган кеше берәүдән-берәүдән сорашкан булгандыр. Йә бер-бер көтүчедән йә булмаса бер мутаукадан... Тәмам белгәнен әйтеп бетермиләр. Урыс халкы ни сорашса да, шомланалар. Урыс халкы мөселманнарны куркытып бетергән. Әллә ни шомлык белән сораша торгандыр дип, урыс халкыннан куркалар. Сорашканда бездән һәм тартыналар»[38].

Каюм Насыйри шулай дип, үзенең мәгълүматларны читенлек белән, 1855 нче елдан бирле сорашып-белешеп туплаганын белдергән. Ул бу эшенә әтисенең бик зур ярдәме тигәнлеген, аның таныш муллаларыннан һәм әүвәлге заман кшеләреннән тәфсилләп сорашканнарын язган. Керешендә Насыйри болай дип тә өстәгән: «...риваятьләрне җыюдан максуд ошбудыр: Зөя өязе яки Тау ягы хакында бер тәварих язмак – Тау ягы дигәч тә тиз үк күңелгә төшә Иделнең ары ягы – Зөя өязе. Зөя өязендәге мөселман авыллары күбесе Аксак Тимер Болгарны һәлак кыйлган Болгардан (вә һәм Бүләр яки Биләр шәһәреннән) күчеп килгән халыклардыр...». Галим Зөя өязендәге авыллар тарихына гомуми күзәтүләр ясаган, дәлилләр китергән.

[37] Җәя эчендәге сүзләр кулъязмада карандаш белән сызылган.

[38] Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә «601т» шифры белән саклана торган кулъязма, 2а–3б кәгазь.

Монда язылганнардан К.Насыйриның авыл тарихларын ничек өйрәнгән булуын, җыйган мәгълүматларын бер тәртипкә китерү өчен нәрсә сәбәп булганын һәм рус авторларына тәнкыйди карашын да күрергә мөмкин.

Каюм Насыйри кебек киңкырлы эшчәнлек алып барган һәм бай мирас калдырган сирәк шәхеснең әсәрләрен киләчәктә өйрәнүчеләр аның үз кулъязмалары – беренчел чыганаклар белән нигезлерәк эш итсәләр, галимнең басылып чыккан хезмәтләрен тулыландырырлык мәгълүматлар тагын да табылачак әле. Мәсәлән, аның шул ук кулъязма җыентыгында каберташ язмаларының күчермәләре (Мулла Иле авылы һ.б.) бар, Шигали авылы турында басылган текстта Нәҗметдин мулла белән йөргәнлеге әйтелгән булса да, кулъязмасында аның Таҗетдин дип төзәтелгәнен күрергә мөмкин һ.б.

## Эчтәлегенә кайбер искәрмәләр

Мулла Минһаҗетдин Җәбәли моннан 145 ел элек язган тарихи әсәрдә тасвирланган күп нәрсәләр хәзерге көннең фәнни казанышлары күзлегеннән караганда күптәннән расланган яисә кире кагылган.

Тикшерелә торган чыганакның автор язган каралама текстлар икәнлеге һәм аларның да тулы хәлендә сакланмаганлыгы истә тотылырга тиеш.

Хәзерге заманның академик фәне белән азмы-күпме таныш укучыга Минһаҗетдин Җәбәли язган мәгълүматлар урыны-урыны белән урта гасырлардагыча мифлаштырылган әкиятсыман кебек тоелырга мөмкин. Бу хезмәтнең файдалы һәм уңай яклары булган кебек үк, әлбәттә, җитешсезлекләре дә бар. Кимчелекләренә һәм ялгыш фикерләренә карап, Минһаҗетдин мулланың язганнарын гомуми кире кагудан сакланырга кирәк.

Мондый очракта әүвәлгеләрнең фидакяр хезмәтләренә аеруча хөрмәт белән караган галим һәм фикер иясе, татар тарихы буенча күп хезмәтләр авторы Ризаэтдин Фәхретдиннең үз чорында күп тәнкыйтькә һәм шактый сүгелүгә дучар булган Хи-

саметдин Мөслими дигән авторның «Тәварихы Болгарийә» әсәре уңаеннан әйткән сүзләрен искә төшерү урынлы булыр. Ул язучы, әдәбият галиме һәм археограф, борынгы кабер ташларын өйрәнгән Гали Рәхимгә 1927 елда язган хатында болай дигән: «Тәварихы Болгарийә» бер кеше тарафыннан язылган булса булыр, әмма төрле урыннардан вә бигрәк тә иске китаплар читләреннән җыелып, чүпләнеп алынгандыр дип гөман кылам. Анда бер дә дөрес булмаган сүзләр булса, бик дөрестләр дә булырга мөмкин. Шуның өчен китапны бөтенләй эштән чыгарып ташламыйсы иде»[39]. Р.Фәхретдин шул карашын кабаттан тәфсилләбрәк аңлатып та язган: «Тәварихы Болгарийә» китабында нигезсез сүзләр вә ялган хәбәрләр, ясалма вакыйгаларның хикәятләре хисапсыз күп. Әмма, шуның белән бергә, моны язучының белгән нәрсәсе дә хисапсыз дәрәҗәдә диярлек күп. Халыклар моның ялганлавына гаҗәпләнгәннәре вә хәйран калганнары хәлдә, мин үзем матбугат халык арасында таралмаган бер заманда аның бу мәртәбәдә күп нәрсә ишетүе вә белүе хакында хәйранмын...»[40] дигән. Галим бу әсәрне җентекләп өйрәнергә һәм ялганын хактан аерып карарга кирәклеген искәрткән. Тикшергән чакта аеруча игътибарга алынырга тиешле мәсьәләләрне пунктлап язган.

Элекке тәҗрибәле галимнәрнең кульязма мираска аеруча сакчыл мөнәсәбәт булырга тиешлеге турындагы фикерләрен М.Җәбәли хезмәтенә карата да истә тоту зарур. Минһаҗетдин мулланың хезмәте, беренче нәүбәттә, язылган заманыннан һәм иҗтимагый шартларыннан аермыйча өйрәнелергә тиеш. Ягъни, аны язуга нәрсә этәргеч биргән? Ул аны кемгә адреслаган? Әсәрне язган чорда татар авторларының үз тарихларына багышланган әсәрләре күп булганмы? Авторлары кемнәр һәм Минһаҗетдин мулла ул әсәрләрне белгәнме? Аның «Тәварих...»ы үз заманының

[39] Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз. Р.Мәрданов, И.Һадиев. – Казан: «Җыен» нәшр., 2008. – Б. 339.
[40] Фәхреддинев Р. Болгар вә Казан төрекләре / төз. Ә.Хәйруллин. – Казан: Татар. китап нәшр., 1993. – Б. 59.

менә шундый күп мәсьәләләре даирәсендә тикшерелергә һәм фәнебез тарихында лаек урынын алырга тиеш.

Минһаҗетдин хәзрәт бу хезмәтен язган вакытта татар тарихы буенча үз телебездә фәнни хезмәтләр әле басылып чыкмаган булган. Чөнки Хөсәен Әмирхановның «Тәварихы Болгарийә» әсәре 1883 елда нәшер ителгән, Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар» китабы беренче тапкыр 1885 елда дөнья күргән. Ә гасырдашларыннан Ибраһим Хәлфиннең Казан тарихы турындагы хезмәте 1827 елда басмага әзерләнгән булса да, дөньяга чыкмыйча калган һәм аның турында мәгълүмат XX һәм XXI гасырда гына билгеле булды[41]. Галим Хөсәен Фәезхановның татар тарихы буенча 1859–1860 нчы елларда язган әсәрләре үз вакытында басылмаган, аларның текстлары күптән түгел – 2006 һәм 2011 елларда гына матбугатта чыкты.

Димәк, мәсьәләнең торышын үз чорыннан аермыйча карaганда, Минһаҗетдин Җәбәли әлеге хезмәтен язу белән мәшгуль булган вакытта башка татар авторларының милли тарихка багышланган һәм нигез булырлык китаплары бөтенләй чыкмаган. Ягъни, Минһаҗетдин мулла шундый әсәрне үзлегеннән язарга алынган шәхесләрнең беренчеләреннән булганлыгы ягыннан зур игътибарга лаек. Үзе туплаган чыганаклар базасы нигезендә һәм мөмкинлекләренә күрә, аның гаять катлаулы

---

[41] Фәнни яктан бик мөһим булган бу мәгълүмат А.Фәтхинең тасвирламасында 55 ел элек үк 1968 елда чыкканын (*Кулъязмалар тасвирламасы. XII чыгарылыш: Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары. Өченче бүлек / төз. А.Фәтхи. – Казан: ун-т нәшр., 1968. – Б. 27*) искә төшерик. Рус телендә 2013 елда дөнья күргән җиде томлы татар тарихы китапларының бары тик берсендә – VI томында Казан университетында XIX гасыр башында эшләгән галим И.Хәлфин турында махсус мәкалә (*История татар с древнейших времён. В семи томах. Т. VI: формирование татарской нации: XIX–начало XX вв. – Казань: Ин-т ист. им. Ш.Марджани АН РТ, 2013. – С. 745–746, 788*) булса да, анда Хәлфиннең тарихи әсәре турында берни әйтелмәгән. Югыйсә, татар тарихын Ш.Мәрҗанигә хәтле үк чын фәнни нигездә өйрәнә башлаган, университетта эшләгән татар галименең хезмәте турында тулырак язылса, тарихи яктан дөрес булыр иде. И.Хәлфиннең Казан тарихына багышланган хезмәтенең кереш өлеше беренче тапкыр «Чыңгызнамә» китабында басылып чыкты (*Чыңгызнамә»: тарихи дастаннар..., 2019. – Б. 27–29*).

һәм җаваплы эшкә керешкәнлеге күренә. Бу авыл мулласының бай китапханәләре белән данлыклы Сәмәркандта һәм Бохарада, Төркиядә яисә башка урында укымаганлыгын да истә тотарга кирәк. Ул кулланган тарихи һәм фәнни китаплар (күбесе кулъязма хәлендә булганлыгы аңлашыла), димәк, үзебезнең татар җирлегендә булган. Аларның бер өлеше татарлар арасына алып кайтылган Төркия басмалары икәнлеге аңлашыла.

Ихтимал, Минһаҗетдин хәзрәт остазы Гали ишан Түнтәринең бай китапханәсеннән файдалангандыр, бәлки якташы һәм чордашы Каюм Насыйри белән әңгәмәләр коргандыр, тарихчы муллалар Хөсәен Әмирханов һәм Шиһабетдин Мәрҗани белән дә күрешкәндер, шулай ук башка күп танышлары белән китап алмашып торгандыр дип фаразларга мөмкин. Кулъязма җыентыгының 25б кәгазендәге «Мәрҗани, китап. Әбү Исхак әл-Истәхри» дигән кыска гына язмасы шундый аралашуга бер дәлил түгел микән дигән уй да килә.

Җәбәли әсәренең язылган датасы буларак күрсәтелгән 1878 ел – каралама да сакланган ахыргы вариантының кәгазьгә теркәлгән елы дип кабул ителергә тиеш. Чөнки мондый зур һәм җаваплы хезмәт берничә елда гына языла алмаган. 1877–1878 еллардагы рус-төрек сугышына бәйле рәвештә империя эчендәге мөселманнарга дәүләт мөнәсәбәтенең кискенләшүе дине өчен янган-көйгән фидакяр авыл мулласының бу хезмәтен төгәлләү ниятенә этәргеч биргәндер. Минһаҗетдин мулла Сәйфулла улы татарларның гына түгел, ә Идел-Урал буйларында электән яшәп килгән башка халыкларның әүвәл ислам динен тоткан булуларын расларга омтылып, мөселманнарның бу җирлектә – үз ватаннарында элек-электән бердәм гомер иткәнлекләрен бәян итеп, халыкның рухын сакларга тырышкандыр.

Билгеле булганча, рус-төрек сугышы елларында миссионерлык көчәйгән, православие диненнән мөселманлыкка чыккан татарларны һәм аларны «котыртучыларны» эзәрлекләү арткан, меңләгән мөселманнар (алар арасында йөзләрчә руханилар) төрмә-сөргеннәргә озатылган. Русларның төрекләрне җиңүе Россиядәге татарларны чукындырачаклар дигән сүзләр

таралуга сәбәпче булган. Шул җирлектә Идел-Урал төбәгендә мөселман-татарлар яшәгән губерналарда хөкүмәткә каршы хәрәкәтләр булган[42]. Аларга чуваш һәм марилар да кушылган. Баш күтәрүләр бастырылган, күп кенә крестьяннар җәзага тартылган. Татар халкының ул еллардагы рухи халәтенең торышы һәм кичергән газаплары «Төрек сугышы бәете»ндә ачык тасвирланган[43]. Сугыш алдыннан гына Россия Халык мәгарифе министрлыгының 1870 елгы карары буенча татар мәктәп-мәдрәсәләренә мәҗбүри рус телен укытуны кертү омтылышы да империядә яшәгән мөселманнарны зур куркуга салган булган. Идел-Урал буйларындагы халыкларның христианлыктан тайпылышларын күзәтү аеруча көчәйтелгән, мөселманлык кабул итүләре катгый тыелган.

Менә шундый вакыйгалар заманында Минһаҗетдин мулланың, беренче нәүбәттә, мөселманлыкны яклап һәм кайгыртып, өстәвенә чувашлар, чирмешләр, мукшылар, удмуртлар элек мөселман булганнар, Казан ханлыгы яулап алынгач мәҗүсилеккә төшкәннәр дип язган хезмәте, гомумән, империя сәясәтенә кискен каршы килгән. Шунлыктан, М.Җәбәли үз әсәрен китапчык-рисалә итеп бастыру өчен патша цензурасына тапшырган булса да, аның дөньяга чыгуына рөхсәт бирелмәве һәм нәшер ителмичә калуы гаҗәп түгел. Чынлыкта, Минһаҗетдин Сәйфулла улы тарихи һәм дини җыентыгын аерым китап-рисалә итеп бастыру өчен акка күчергәнмеюкмы икәнлеге билгесез.

Борынгы Болгар дәүләтенең тарихи-географик җәһәттән киң чикләргә ия булганын язуыннан, шулай ук башка тасвирларыннан күренгәнчә, авторның Алтын Урда һәм чыңгызлылар төзеп, идарә иткән зур территорияләрне күзаллаган булуы аңлашыла. Мәсәлән, Болгар дәүләтенең «хөкүмәте Кавказ тарафларыннан алып, Русиянең Нижний

---

[42] Алишев С. Каһарман бабайлар. – Казан: Татар. китап нәшр., 1976. – Б. 151–152; История татар с древнейших времён. В семи томах. Т. VI..., 2013. – С. 493–494, 570–574.
[43] Мирас. – 1991. – №1. – Б. 52–59.

каласына кадәр булып, бәлки Русия һәм Мәскәү бер заман татарларның идарәсе астында булганлыгы Русия халкының тарих китапларында язылган» дигән сүзләре. Ул XIX гасырда мөселман-татар укымышлылары арасында Идел-Урал төбәгенә карата кулланылган «Болгар йорты» дигән атаманы да теркәгән. Кульязманың 20а кәгазендә татарларда уку тәртибе турында бәян итеп, ахырында шул сүзләрне язып куйган. «Болгар йорты» дигән билгеләмә, чынлыкта, әүвәл Казан ханлыгы биләгән киң территориянең «Болгар вилаяте» дип аталган булуыннан килгән.

Минһаҗетдин Җәбәли текстында күп мәртәбә кулланылган «әтраке мөхтәлифә, әкряде мөхтәлифә» (күп төрле төркиләр, күп төрле көрд кавемнәре) гыйбарәләре гарәп телендәге борынгы тарихи китаплардан алынган. Мәсәлән, 1135 елда Болгарга килгән Әбү Хәмид әл-Әндәлеси Болгар тирәсендә күптөрле төрки таифәләр булганын язган, аның чордашы Әл-Идриси дә шулай дип белдергән.

Җыентык иясенең татар этнонимы турындагы фикерләре кызыклы һәм, үз чорына күрә, әһәмиятле дә. Җәбәли текстта «татар» сүзен күп кулланган, аның «мөселман» дигән мәгънәгә тәңгәл түгеллеген аңлаткан. Әсәренең полемик рухтагы җөмләләрендә «без – татарлар», «Казан татарлары», «без – мөселман татарлар» дип, берничә урында тәгаенләп кабатлаган. Ләкин ул бөтен мөселман дәүләтләрен, шул исәптән, Бәгъдадны харап итүчеләрне аерып, «Чыңгыз хан һәм улы Һуләгу, аларның бөтен гаскәрләре – монголлар иде» дип, «Миръател-кяинат» китабыннан күчереп язган.

Әсәр текстында хәзәр–болгар–татар дәвамчанлыгы һәм тәңгәллеге дә бәян ителгән. Минһаҗетдин хәзрәт вакытлар үтүгә бәйле рәвештә ил-дәүләтнең, калаларның һәм аларда яшәгән халык исеменең үзгәреп килгәненә игътибар юнәлткән. Мәсәлән, Нух пәйгамбәрдән дәвам итеп килгән шәҗәрәдәге Алынча ханның «татар» исемле улының кавеме вакытлар узу белән «Җабәлкаһ» дип аталганын искәрткән. Автор, үзенчә, Болгар (Казан) вилаятендә яшәгән халыкларның

этник составын тәгаенләгән. Җыентыкның 11а кәгазендә аларны атап язган: «Нугай һәм кимәк – татарлар. Һәм янә заман узу белән «каракалпак», «үзбәк» һәм «чыгытай» булып, тагын вакытлар үткәч «Мәмләкәте Кыпчак» вә «Биляде сакалибә вә хәзәр вә хәзәз» дигәннәр. Һәм заманнар узу белән «Болгар» дигәннәр, аннан соң «Казан» дигәннәр. Казанга буйсынган халыклар да төркиләр җөмләсеннән. Татар, мишәр, төмән[44], башкорд, кыргыз, чуваш, чирмеш, мукшы һәм ар – бөтенесе төрле төрки кавемнәр, хан заманында мөселман булганнар».

Шунысы үзенчәлекле, М.Җәбәли Болгар вилаятенең халкы дип тезеп язганда бер мәртәбә дә аерым «болгар» кавемен-кабиләсен атамаган. Аның язганнарыннан «болгар» атамасы, гомумән, бер җыелма исем икәнлеге аңлашыла. Автор, «хәзәр» һәм «болгар»ларны бер үк итеп караганлыгы сәбәпле, тарихи үткәннәрен дә бергә кушыбрак тасвирлаган. Ул кулланган китаплардан «Нисабел-интисар»да төрле төрки халыклар һәм Хәзәр иле Искәндәр төзегән диварга чиктәш дигәнгә ияреп, Хәзәр белән Болгарны тиңләштергәнлеге күренә.

Автор «татар» сүзен еш кына бик киң мәгънәдә – «төрки» атамасы урынына кулланган, хәтта Идел буендагы фин-угорларны да шул атама эченә керткән. Төрле халыкларның (Идел-Урал буендагы, Урта Азия һ.б.) татарларны ничек дип атавы турындагы күзәтүләре дә кызыклы. Ул болай язган: «Фарсы халкы да «татар» ди һәм күпчелек «үзбәк» диләр. Аеруча, Бохараи шәриф халкы – сартлар, таҗиклар, үзбәкләр – «татар» диләр. Әмма төрекмән халкы, хивалылар «татар» диләр һәм «Болгар халкы» диләр. Сарт халкы, Куканд һәм Ташкентлар «нугай», «татар» һәм «үзбәк» диләр[45]. Шулай ук төрекләр (Госманлы халкы) «та-

---

[44] Элекке чорда «төмән, төмәннәр» дип йөртелгән халык төркеме – патша дәверендәге Пенза һәм Тамбов губерналарыннан чыккан «Темников татарлары» (мишәрләр, йомышлы татарлар, морзалар).

[45] Урта Азиядәге төрле халыкларның, шулай ук фарсыларның Идел-Урал татарларын ничек атаулары мәсьәләсендәге мәгълүматны автор, ихтимал, остазы Гали ишаннан ишетеп белгәндер һәм башка чыганакларга да нигезләнгәндер.

тар» диләр». Шулай ук авторның «мишәр» атамасы турындагы фикере үзенчәлекле.

Минһаҗетдин мулланың башка язма чыганакларга нигезләнеп, Болгарда хак диннең кайсы чорларда һәм ничә мәртәбә таралыш алып, яңартылганын тасвирлаганын алда әйтеп үткән идек. Автор риваятьләрне һәм чынбарлыкны бергә үргән. Халык тарихындагы андый мөһим вакыйга турында электән төрле риваятьләр йөргән. Болгарга VII гасырда сәхабәләр килеп, ислам дине шул вакытта ихтыяри рәвештә кабул ителүе турындагы риваять шактый киң таралыш алган. Хисаметдин Мөслиминең бик популяр булган «Тәварихы Болгария» китабында, шулай ук Таҗетдин Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» әсәрендә ул турыда күп язылган (алардагы кеше исемнәре генә бераз төрлечә). Болгар шәһәрен Искәндәр Зөлкарнәйн (Руми) төзетүе[46] турындагы «Тәварихы дәваир» китабына ишарә итеп язганы да Таҗетдин Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» әсәреннән алынган булса кирәк. Тик шуны да истә тотарга кирәк, авторларның һәммәсе дә әүвәлге – башка бер язма чыганакка нигезләнгән булуы бик ихтимал.

Хезмәтнең авторы хикәяләвенчә, ислам дине Кавказ аша хәзәрләргә (болгарларга) үтеп кереп, тагын бер мәртәбә яңартылган. Бу тарихны да ул төрле чыганаклар нигезендә тәфсилләп язган.

Фәнни мәгълүматлар буенча, Идел буена ислам дине ике юл белән үтеп кергән. Беренчесе – 653 елда гарәпләрнең Кавказдагы сасанилар каласы Дәрбәнтне («Бабел-әбваб») басып алуы аша, икенчесе – Урта Азиядәге саманилар дәүләтеннән

[46] Хезмәтнең авторы Искәндәр Руминың Болгар каласын төзетүе һ.б. турында «Тибъян нафигъ» китабының тәрҗемәсенә дә нигезләнгән (13а кәгазь). Тарихчы Г.Әхмәрев Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятендәге 1895 елгы бер хисабында Искәндәр Зөлкарнәйннең Болгар каласын төзүе турында татарлар арасында йөргән риваятьләрнең дөреслеккә туры килмәгәнлеген белдергән. Чөнки мөселманнар Искәндәрне изгеләрдән исәпләп, йөзләрчә калаларның төзелүен аның исеме белән бәйлиләр дигән (*Гайнетдин Әхмәрев: тарихи-документаль җыентык..., 2000. – Б. 331*).

Урта Иделгә – болгарларга IX–X гасырларда кергән. Шуны да искәртергә кирәк, Хәзәр каһанлыгы вакытында болгарларда ислам дине таралуын тарихчылар кире какмый.

Кавказ аша үтеп керү вакыйгасы җиңел булмаган, чөнки хәзәрләр гарәпләргә каршы сугышып, төньякка үткәрмәгәннәр. 737 елда гына хәлифә Мәрван II Хәзәр каһанлыгын тар-мар иткән һәм анда кыска гына вакытка ислам динен мәҗбүри кабул иттергән. Ләкин хәзәрләр яһүд диненә авышканнар. Шуңа карамастан, Хәзәр каһанлыгында рәсми булмаса да, ислам дине таралган, мәчетләр төзелгән, христиан динен тотучылар да булган.

Шиһабетдин Мәрҗани әлеге мәсьәләләрне тәфсилләп өйрәнеп, ислам дине 922 елда рәсми рәвештә кабул ителгәнче Идел буе Болгарында бик киң таралган дип язган[47].

Ислам диненең җирләшүе мәсьәләсендә татар тарихчыларында әле XX гасыр башында да ныклы гына караш урнашып җитмәгән булуын да искә алырга кирәк. Мәсәлән, Гайнетдин Әхмәрев «Болгар халкының кай заманда мөселман булганлыгы тәгаен мәгълүм түгел» дип, Хисаметдин Мөслими китабында язылганны – сәхабәләрдән кабул ителү турындагы хәбәр барлыгын әйткән. «Бу хәбәрнең дөреслеге бик ачык мәгълүм түгел» дип искәрткән. Ул шулай ук мондый фактларны теркәгән: «Хәзрәти Гомәр заманында (һиҗрәттән 19 нчы елда) гарәпләр Дәрбәнт шәһәрен алганнар, шуннан соң Болгарда дине ислам гайре диннәрдән өстен санала башлаганы мәгълүмдер»[48]. Г.Әхмәрев, болгарлар үзләре мөселман булгач ислам динен башка халыкларга тарата башлаганнар дип, башкортларны мисалга китергән. Болгар вилаятендәге фин-угорларга да ислам диненең тәэсирен әйтеп, ләкин,

[47] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар..., 1989. – Б. 116, 123, 135. Идел буе Болгар дәүләтендә ислам диненең таралуы һәм башка күп мәсьәләләрнең торышы галим Гамирҗан Дәүләтшин хезмәтендә нигезле аңлатылган (*Дәүләтшин Г. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. – Казан: Татар. китап нәшр., 1999. – 512 б.*).

[48] Гайнетдин Әхмәрев: тарихи-документаль җыентык..., 2000. – Б. 56–57.

«телләре башка булганлыктанмы», алар тулаем мөселман була алмаганнар[49], дигән.

Ислам диненең Болгарда таралу вакыйгалары, ул мәсьәләдәге риваятьләр, гарәпләрнең Кавказ аша үтеп керүе, хәзәрләр һәм болгарлар, «сәкалибә»ләрнең кем икәнлеге һәм, гомумән, М.Җәбәли хезмәтендә тасвирланган мәсьәләләрнең бер өлеше XIX гасырда ук башка татар галимнәре (Ш.Мәрҗани, Х.Әмирханов һ.б.) тарафыннан нигезле рәвештә өйрәнелгән. Аннан соң да ул мәсьәләләр белән кызыксыну кимемәгән. Соңгырак чордагы фәнни хезмәтләрдә алар шактый киң һәм дәлилле аңлатылган.

Хезмәттә монгол яулары кыскача гына телгә алынган: «...Чыңгыз хан чыгып Болгарны, Мәскәүне басып алып, тамга салу гадәтен керткән».

Нәсел тамгаларының Алтын Урда чорында милек хокукын белдерү хасияте рәсмиләшкәненә ачык бер дәлил барлыгын искәртик – XVIII–XIX гасырлардагы язма документларда (хәтта XX гасыр башына кадәр) Россия империясенең төрле төбәкләрендә яшәгән хатын-кызлар бер үк төрле («киләп» рәвешендәге) тамга куйганнар. Мөселман-татар метрикаларындагы талак (аерылышу) турындагы язмаларда хатыннар «хатын-кызларга махсус киләп тамга салдым» дип, тамга сурәтен ясаганнар[50]. Шулай ук Идел-Урал төбәгендә яшәгән төрле халыкларда, хәтта руслар катнашкан хосусый актларда тамга кую күренеше булган.

Иске Казан шәһәренең нигезләнүе һәм яңа урынга күчүе, шулай ук руслар тарафыннан Казанның алыну вакыйгасы ту-

---

[49] Шунда ук. – Б. 57.

[50] Тарихчы Җәүдәт Миңнуллин хезмәтендә барлык хатын-кызларның бер төрле үк тамга куюы мәсьәләсе Казан ханлыгы чорында рәсмиләшкән булу ихтималы белдерелгән (*Миннуллин З. Татарские частные акты XVII – первой половины XIX в.: источниковедческая характеристика. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2020. – С. 82–83*). Ләкин, безнең уебызча, бу мәсьәлә әүвәлдәнрәк – Алтын Урда чорыннан ук килгәндер. Казан ханлыгы территориясеннән читтәге һәм хәтта ерактагы төбәкләрдә дә хатын-кызлар тамгасының шундый ук булганлыгына бүтәнчә аңлатма табылмый.

рындагы мәгълүматны Минһаҗетдин мулла «Чыңгызнамә» әсәреннән алганлыгын үзе дә күрсәткән. Казанның яуланган елы итеп «Чыңгызнамә»нең күпчелек кульязма күчермәләрендә һиҗри 961 елның 2 гакърәб (чаян ае) көне язылган, ләкин бу дата миладируы 1554 елның 23 октябренә туры килә. Дөресе – 1552 елга туры килә торганы – һиҗри 959 ел булырга тиеш[51].

Автор текстының II вариантында Иске Казан шәһәрендә татарлар йөз елдан артык яшәгәннәр диелсә, I вариантта анда 110 ел торганнар дип язылган. Бу очракта шуңа игътибар итәргә кирәк, Минһаҗетдин Җәбәли мәгълүматлар алган «Чыңгызнамә» китабының кульязмаларында Иске Казанда 104 ел яшәгәннәр диелгән[52]. Шул сәбәпле, 110 ел дигән санны Җәбәлинең кайдан алып язганлыгы аңлашылмый. «Чыңгызнамә»нең кайбер күчермәләрендә, бәлки, шундый сан язылган булгандыр дип фаразларга мөмкин.

Минһаҗетдин хәзрәт хезмәтенең бер урынында (35а кәгазьдә) «Үземезнең иске хикәйәтемезгә киләлек» дигән җөмләсе бар. Бу җөмләнең охшашы әүвәлге тарихи дастаннардан һәм иске китаплардан күчкән. Мәсәлән, «Чыңгызнамә» китабындагы Чыңгыз хан нәселе турындагы дастан «Дәфтәрнең әүвәл башындин сөйләйәлек» дип, шундагы ук Аксак Тимер турындагы дастан «Имди йәнә Аксак Тимер нәселендин сөйләйәлек» дип башланган[53].

Автор тарафыннан тел мәсьәләсенә аеруча зур игътибар бирелгәнен алдарак әйтеп үткән идек. Ул үз чоры өчен үк архаиклашкан төрле сүзләрне һәм гыйбарәләрне мисалга китергән. Ә аның заманында кулланылган, хәзерге вакытка архаиклашкан бүтән сүзләр дә барлыгын искә алыйк. Мәсәлән, М.Җәбәли үз текстында Идел елгасына карата «Кара Идел»

---

[51] «Чыңгызнамә»: тарихи дастаннар..., 2019. – Б. 87.

[52] Иске Казан шәһәрендә татарлар 104 ел яшәгәнлеге турындагы бер төрле үк сан Х.Әмирхановта, Ш.Мәрҗанидә, С.М.Шпилевскийда, Г.Әхмәревтә һ.б. авторларда кабатланган.

[53] «Чыңгызнамә»: тарихи дастаннар..., 2019. – Б. 96, 186.

дигән атама кулланган. Аның хикмәте борынгы төрки заманнан ук килгән үзенчәлеккә – «кара» дигән сүзнең төньякны һәм «ак» сүзенең көньякны белдерү төсмерләренә бәйле. Мәсәлән, Идел елгасын төньяктарак урнашканына нисбәт итеп, элек «Кара Идел» дип, аннан көньяктагырак Чулман (Кама) елгасын «Ак Идел» дип язганнар. XIX гасыр галиме Хөсәен Фәезханов та нәкъ шундый атамалар кулланган[54]. Чулман елгасы буенда урнашкан борынгы Кашан каласы Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария» китабында «Ак Идел ярында Кашан шәһәре» буларак телгә алынган. «Кара» белән «ак» сүзләренең «төньяк» һәм «көньяк» мәгънәләрендә хәзергәчә кулланыла торган очрагы – Төркиянең төньягында «Кара диңгез», ә көньягында – «Ак диңгез» дип аталуда ачык күренә.

Минһаҗетдин Җәбәли текстында «Чин» дигән атама еш кабатланган. Аны, гадәттә, «Кытай» дип тәңгәлләштерсәләр дә, борынгы чорда, бигрәк тә мөселман авторларының әсәрләрендә «Чин» дигәндә Кытай Төркестаны күздә тотылган. Ул турыда төрле галимнәр (шул исәптән шәрык белгече, тюрколог Е.Э.Бертельс та) ачык итеп язганнар[55].

Минһаҗетдин мулла теркәгән алыплар турындагы риваять татар халкында киң таралган. Ул язганнар замандашы һәм чордашы Каюм Насыйри тасвирлаганга[56] аваздаш.

Татарларда һәм башка төркиләрдә генә түгел, гомумән, җир йөзендәге күп халыкларның авыз иҗатында борынгы чордагы алып гәүдәле кешеләр турындагы риваятьләр һәм мифлар сакланган. Дөньяда киң таралыш тапкан борынгы дин китапларында, шул исәптән, Коръәндә, алып кешеләр телгә алынган. М.Җәбәли «Нисабел-интисар» китабыннан Болгардагы алып турында күчергән өзектән тыш, X гасыр-

[54] Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык..., 2006. – Б. 73.
[55] Бу мәсьәләгә элегрәк бер тукталган идек (*Кыз хикәяте / төз.-авт. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2012. – Б. 177–181)*.
[56] Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда. Беренче том. – Казан: Татар. китап нәшр., 1974. – Б. 81–83.

да Идел буе Болгар дәүләтенә сәяхәт иткән Ибне Фадлан, XII гасыр сәяхәтчесе Әбү Хәмид әл-Әндәлеси Гарнатый үз язмаларында шулай ук алып кеше турында бәян иткәннәр[57].

Коръән һәм мөселман риваятьләре буенча, җир йөзендәге беренче кеше – Адәм пәйгамбәрнең буе 60 терсәк (ягъни 18 метр чамасы) булган, Нух пәйгамбәрнең токымнарыннан Йәмәндә яшәгән борынгы «гъад кавеме» дип аталган алыплар кабиләсе Аллаһы Тәгаләнең хөкеме белән һәлак ителгән. Коръәндә язылганча, гъад кавемен иманга китерү өчен Һуд галәйһиссәлам җибәрелгән, әмма аны куганнар. Аллаһы Тәгаләнең әмере буенча гъад кавеменә һәлакәт килгән – алар бөтенләй юкка чыгып беткәннәр.

Җир йөзенең төрле кыйтгаларында (Европа, Азия, Африка һәм Америкада) гадәттән тыш эре кешеләрнең сөякләре күпләп табылган булуы да мәгълүм. Дөрес, аларның шактые кешелек дөньясы эволюцион үсешенең рәсми фәндә урын алган теориясенә каршы килгәнлектән, юкка чыгарылган, диләр. Ифрат зур гәүдәле кешеләрнең сөяк калдыклары төрле урыннарда: чүлләрдә, тауларда, диңгез төбендә, тигез җирләрдә хәзер дә табылып тора. Галимнәр аңлатуынча, электә эре булган кешеләрнең вагаюына атмосфера үзгәрешләре сәбәпче булган. Кайбер белгечләр әлмисакта, агачларның һәм үләннәрнең, шулай ук барлык җан ияләренең, җанварларның аеруча гигант рәвешләрен истә тотып, эре гәүдәле кешеләр дә, үз чорына күрә, гайре табигый булмаган, дип аңлаталар.

Җыентыктагы «Казан бәете» фрагментының моңарчы матбугатта чыккан вариантларыннан кульъязмадагы бер аермасын искәртергә кирәк. Бәет тексты башындагы ике юлыннан соң килгән өлешенең кабатлану рәвешендә бирелүе үзенчәлекле:

[57] Путешествие Ахмеда Ибн-Фадлана на реку Итиль и принятие в Булгарии ислама / древний текст пересказал Султан Шамси. – Москва: изд-во «МИФИ-СЕРВИС», 1992. – С. 40–41; История татар с древнейших времён. В семи томах. Т. II: Волжская Булгария и Великая Степь. – Казань: изд-во «РухИЛ», 2006. – С. 781, 787.

Божырга диб тозак салдым,
Божырга диб тозак салдым.
Суйыр боты өзелде,
Суйыр боты өзелде.

Менә мондый – бер юлны икешәр мәртәбә кабатлаулар борынгы дастаннарда да күзәтелә. Мәсәлән, «Түләк китабы» дастаны текстындагы рефреннар шундый[58]. Анда язганыбызны искә төшереп, тексттагы кабатлану үзенчәлеге, һичшиксез, әсәрнең поэтик аһәңен көчәйтә һәм бизи дип, «Казан бәете»ндәге фрагментына карата да әйтә алабыз. Ихтимал, бәетнең бу өлеше һәр икеюллык строфа саен кабатланып баргандыр. Чөнки бәеттәге икеюллык белән рефрен тезмәләренең үлчәмнәре дә төрлечә.

Мөселман татарларда гамәлдә булган күп гасырлык уку-укыту системасының бай тарихы шактый өйрәнелгән диярлек. Бу өлкәдәге тикшеренүләр әле дә дәвам итүен исәпкә алганда, Минһаҗетдин Җәбәли язып калдырган кыскача мәгълүмат файдалы булыр. Аның бу мәсьәләне үз чорында теркәп калдыруы әһәмиятле, кадими мәдрәсәләрдә «иҗек»не кулланылышка татарлар керткән диюе һ.б. мәгълүматлары кызыклы. Дөрес, ул язганнар арасында кайбер дәрес (мәсәлән, фәраиз) һәм дәреслек итеп кулланылган китап исемнәре («Мөхәммәдия») төшеп калган. Кайбер нәрсәләрнең язылмыйча калуының сәбәбе – төрле мәдрәсәләрдә укытылган дәресләр һәм аларда кулланылган китаплар стандарт тәңгәллеккә ия булмаганлыкка да бәйле. Җәбәлинең әлеге текст өлешен З.Максудова «Татар мәктәпләренең программасы» дип атап, үзенә аерым күчереп тә алган (Милли музейдагы материаллары арасында күргән идек).

Тарихчы һәм дин галиме Ризаэтдин Фәхретдин уку-укыту тәртипләрен тасвирлаганда Идел-Урал буе мәдрәсәләрендә кулланылган китапларның кайберләре Төркиядә, Кырымда, Дагстанда белем алган татарлар тарафыннан алып кайтылган-

[58] Түләк китабы / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2008. – Б. 12–13.

лыгы турында язган[59]. Ул атаган китап исемнәре М.Җәбәли хезмәтендә дә телгә алынган. Минһаҗетдин мулла уку һәм белем алу дәрәҗәләрен китапларны өйрәнү-үзләштерүгә бәйләп, санап үтү рәвешендә язган булса, Р.Фәхретдин аларның кайсысына ничә кыш вакыт үткәнен тәфсилле тасвирлаган[60].

Иске татар мәдрәсәләрендәге укыту тарихы совет чорында беренчеләрдән булып галим Җамалетдин Вәлиди тарафыннан өйрәнелгән[61]. Аннан соң совет идеологиясе белән бәйле рәвештә дистә еллар дәвамында, кадими татар мәдрәсәләре, нигездә, искелек һәм дини фанатизм оясы буларак бәяләнеп, объектив мәгълүмат бирүдән ерак һәм начар яктан сурәтләнеп, нигездә, сүгелә иде. Совет заманыннан соң (XX гасыр ахырыннан) мәсьәләне тирәнтен өйрәнүгә игътибар бирелә башлады. Соңгырак чордагы фәнни тикшеренүләрдән Динә Мөхәммәтҗанованың махсус хезмәте[62] зур әһәмияткә лаек.

Йомгаклап әйткәндә, Минһаҗетдин Җәбәли язган фикерләр чордашлары Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов, Х.Әмирханов, К.Насыйри кебек галимнәрнеке белән аваздаш. Шул ук вакытта, аның аерым әһәмияткә ия, мөстәкыйль карашлары да аз түгел. Үзеннән соңгы буын вәкилләреннән тарихи хезмәтләр язган Хәсәнгата Габәши һәм Гайнетдин Әхмәрев белән кайбер мәсьәләләрдә уртаклыклары да күренә.

## Чувашлар тарихына бәйле мәсьәлә

Җәбәлинең хезмәтендә төрле төрки халыклар турындагы һәм Болгар дәүләте белән Казан ханлыгы территорияләрендә яшәгән фин-угор халыклары турындагы фикерләре әһәмиятле. Ул чувашларның үткән тарихы турында шактый уйланган, чуваш халкының килеп чыгуы мәсьәләсендә үз чорының фәндәге

---

[59] Фәхреддинев Р. Болгар вә Казан төрекләре..., 1993. – Б. 238–239.

[60] Шунда ук. – Б. 240–243.

[61] Валидов Дж. Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.). – М.; Пг.: Гос. изд-во, 1923. – С. 13–32.

[62] Мухаметзянова Д. Кадимистская система образования в историческом и педагогическом контекстах. – Казань: Ин-т ист. АН РТ, 2008. – 216 с.

карашларыннан, ягъни, чувашларның борынгы хәзәрләргә, яһүд диненә мөнәсәбәтләреннән, болгар ташъязмаларындагы аерым сүзләрнең чуваш телендә сакланганыннан, болгар-чуваш теориясеннән һ.б. хәбәрдар булган.

Минһаҗетдин мулла, беренче нәүбәттә, чувашларның элек ислам динендә булганлыгын расларга омтылган. Ул ташландык чуваш зиратларындагы мөселманча язулы кабер ташларын тасвирлаган. Шигали исемле чуваш авылының борынгы зиратындагы ташъязмалар уңаеннан М.Җәбәли бу халыкның 900 елга якын (мең елга якын) мөселман булып торганын һәм 400 еллап элек мәҗүсилеккә дүнгәнен язган. Бу очракта автор аларның XVI гасыр уртасына кадәрге 900 һәм 1000 елга якын дәвердә мөселманлыкта яшәгәнлекләрен үзе тасвирлаган буенча, ягъни Хәзәр дәүләтендә һәм Болгарда яшәүчеләрнең элек-электән берничә дулкын рәвешендә мөэмин-мөселман булганлыгын күздә тоткан. (Шунысы да мөһим, Минһаҗетдин мулла язган еллар исәбе һиҗри календарьга нигезләнгән, ягъни милади 33 елга – һиҗри 1 ел кимрәк була).

Искәртү зарур ки, чуваш авылларының (Шигали, Кызылъяр, Тегеш) уртак борынгы зираты буларак, Җәбәли телгә алганнардан Кызылъяр дигәне Сәфәр һәм Нәдер исемле татарлар тарафыннан нигезләнгән һәм элек бу авылның ярты халкы татарлар булган дип чуваш галимнәре яза. XVIII гасырда көчләп чукындыру сәясәте үткәрелгәндә татарларны «чуваш» дип язу фактлары[63] булганын да онытмыйк. Димәк, Тау ягындагы чувашларның элек ислам динен тотулары мәсьәләсе катлаулы этник тарих үзенчәлекләренә ия.

Казан университеты профессоры, шәркыять галиме Христиан Мартин Френ (1782–1851) чувашларны яһүди динен тоткан борынгы хәзәрләрнең дәвамчы тармакларыннан дип белдергән. XVIII гасырда яшәгән Россия Академиясе галим-нәреннән Г.Миллер, П.Паллас һ.б. да чувашларның гореф-гадәтләрендә яһүдиләргә хас уртаклыклар булуына игътибар иткәннәр.

---

[63] Данилов В. Хужа Хәсән – әби-бабайлар нигезе = Хозесаново – земля моих предков. – Казань, 2014. – Б. 40.

Минһаҗетдин Җәбәли «борынгы заманда булган Болгар шәһәренең зиратында һәм ташларда чуваш теле белән язылган ташлар күп дип әйтәләр» дип язган. XIV гасырга караган борынгы кабер ташларындагы текстларда болгар теле үзенчәлекләре чуваш теле ярдәмендә беренче мәртәбә галим Хөсәен Фәезханов тарафыннан ачыкланып, 1863 елдагы мәкаләсендә аңлатылган[64]. Шул рәвешчә, ташъязмалардагы аңлаешсыз булып килгән сүзләрне (нигездә, саннарны һәм елларны) дөрес итеп уку ачышын Фәезханов ясаган.

Хөсәен Фәезхановның рус телендә шул мәсьәләгә багышланган һәм Петербургта басылып чыккан мәкаләсен Бәчек авылында яшәгән Минһаҗетдин мулла ул вакытта күрмәгән булса да, халык арасында сүзе таралгандыр дип фаразларга мөмкин. Бу мәсьәләнең аңа Ш.Мәрҗани яисә К.Насыйри белән аралашулары нәтиҗәсендә ирешкән булуы ихтимал.

Галим Хөсәен Фәезханов Тау ягындагы чувашларның ислам диненә мөнәсәбәтләре турында мондый фикерен язып калдырган: «...бу тирәдәге чувашлар болгар мөселманнарының тырышлыгы белән ислам динен кабул итеп һәм исемнәрен дә мөселманча куеп, аларның язуларын алсалар да, соңрак – мөселманлыкның куәте бетеп, рус кулы астына төшеп, аларда тамырлана алмаганлыктан янә чувашлыкларына кайтканнар булса кирәк, аннан соң христиан булганнардыр дип уйларга мөмкин»[65]. Чуваш теле мәсьәләсе уңаеннан Фәезханов Ш.Мәрҗанигә 1863 елда язган бер хатында болай дигән: «... ислам кабул итмәгән финнәр (хәзерге чуваш һәм чирмешләр) үз телләре белән калсалар да, аларда төркилек бик күп. Хәтта чуваш телен төрки теленнән үзгә тел диярргә дә кыен. Якын араларда чуваш теле сүзлеге китабы алдым. Аннан мәгълүм була ки, сүзләренең дүрттән өч өлеше төркичә. Ләкин асылы

[64] Фейз-ханов Х. Три надгробных Булгарских надписи (с 3-мя таблицами снимков) // Известия Императорского археологического общества. Т. 4. – СПб., 1863. – С. 395–404; Татарская археология. – 1999. – №1–2 (4–5). – С. 49–60; Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык..., 2006. – Б. 298–310.

[65] Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык...., 2006. – Б. 257.

төрки булганлыкларыннан күп авазлар үзгәргән... Әмма чирмеш телендә сүзләрнең өчтән бере кадәресе төркичә булып, калганы финчә»[66].

Борынгы эпиграфик истәлекләрдә чуваш сүзләре булуга карап, борынгы болгарларның дәвамчылары чувашлар дигән теория XIX гасырдан көчәйгән һәм XX гасыр башында фәнни раслама дәрәҗәсенә ирешә язган. Хәтта, ислам динендәге чувашлар үзләренең тарихларын онытып, имеш, татарлашып беткәннәр дигән фикерләр йөргән. Бу мәсьәләдә православ миссионерлары һәм галимнәре Н.И.Ильминский, Н.Ф.Катанов, Н.И.Ашмарин һ.б. зур тырышлык күрсәткән. Ләкин совет чорындагы галимнәр чувашларның элекке фин-угорлар (борынгы чирмешләр) булганлыгы турында язганнар һәм аларның материаль культуралары да шуны раславын белдергәннәр. Болгар дәүләте чорында чуваш теленә кереп, сакланып калган сүзләрнең XIV гасыр мөселман ташъязмаларында очравы – чувашларның турыдан-туры болгарлар дәвамчысы икәнлегенә тулаем дәлил була алмавын язганнар. Чөнки аннан соңгы – XV–XVII гасырлардагы (ягъни, чувашларны чукындыруга кадәрге чорда) мөселман кабер ташларында чуваш телендә генә очрый торган сүзләр бөтенләй юк.

Болгар һәм Казан тарихларын тәфсилләп өйрәнгән галим Гайнетдин Әхмәревнең XX гасыр башындагы карашларына игътибар итик. Ул болгарларның дәвамчылары кемнәр булуы (чувашлармы, татарлармы) турында фикер йөртеп, Казан татарлары дип дәлилләп язган[67]. Бу тарихчы, гомумән, болай дигән: «Бортасларның бу замандагы нәселләре чувашлар булса кирәк, чөнки 1551 нче елда бортас исеме бетеп, алар урынына чуваш исеме ишетелә башлаган. Аннан элек чувашларның исеме ишетелгәне юк»[68]. Бу очракта «чуваш» дигән этноним үзе рус елъязмаларында беренче мәртәбә XVI гасырның икенче яртысында гына теркәлгән булуы күздә

[66] Шунда ук. – Б. 372.
[67] Гайнетдин Әхмәрев: тарихи-документаль җыентык..., 2000. – Б. 33–34.
[68] Шунда ук. – Б. 46.

тотылган. Галим Казан татарларыннан башка бер халык та үзләрен Болгарга бәйле дип дәгъва кылмавын белдергән. Ул Болгарга, Болгар шәһәренең хәрабәләренә һәм археологик табылдыкларга чувашларның мөнәсәбәтен сорашып караган. «Алар Болгар шәһәрләрендә татарлар торган дип сөйлиләр, ур казып әйләндергән шәһәр урыннарын, болгарлардан калган археологик табылдыкларны – барын да татарныкы дип йөртәләр. Үзләрен читтән күчеп килгән халык диләр, Болгар дәүләтенең мәркәзе булган хәзерге Тәтеш, Спас, Чистай өязләрендә әүвәлдә чувашлар бөтенләй булмаган» дип язган Г.Әхмәрев[69].

Чуваш теленең төрки тел булу-булмавы турындагы электән үк килгән «табышмак» хакында галимнәр тарафыннан күп язылган. Мәсәлән, эпиграфик истәлекләрдә борынгы болгар теленә хас сүзләргә карата галим Һарун Йосыпов ул телнең сөйләм теле буларак күптәннән гамәлдән чыкканлыгын һәм XIV гасырның уртасына кадәр эпитафия теле буларак кына кулланылганын белдергән7070. Минһаҗетдин Җәбәли өйрәнгән чуваш зиратларындагы XVI–XVIII гасырларның берничә мөселман кабер ташында да борынгы болгар теленә генә хас булган яки чуваш телендәге бер генә сүз дә юк. Гомумән, болгар теле турында махсус хезмәтләрдән тулырак мәгълүмат алырга мөмкин[71].

Болгар чоры тарихы белән тирәнтен кызыксынган әдип Нурихан Фәттахның 1986 елда язган мәкаләсенә мөрәҗәгать итсәк, чуваш теленә бәйле мәсьәләнең төп хикмәтләре аңлашыла төшәр. Ул түбәндәгечә язган.

«...Чуаш теле һәм чуашларның килеп чыгышы турында йөз елдан артык бәхәс бара. Соңгы вакытта бу бәхәс яңадан көчәйде. Бәхәс, чуаш теленнән бигрәк, болгар теле һәм Болгар

---

[69] Шунда ук. – Б. 35.

[70] Юсупов Г. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.–Л.: «Наука», 1960. – С. 91–92.

[71] Мәсәлән: История татар с древнейших времён. В семи томах. Т. II ..., 2006. – С. 621–628.

мирасы тирәсендә бара. Татар галимнәренең күпчелеге: чуашлар төркиләшкән фин-угорлар дигән карашны яклый. Чуаш галимнәре исә: чуашлар бик борынгы төркиләр һәм алар Идел буе болгарларының турыдан-туры варислары дигән карашны алга сөрә...

Монголлар кебек үк, чуашлар да төркиләргә (бу очракта татарларга) «генетик» туган түгел, чуаш теле чыгышы буенча төрки түгел дигән фикер әйтәбез.

Чуаш теле-ЛАР рәвешендәге күплек күрсәткече булмаган бердәнбер төрки тел. Чуаш телендә күплек төшенчәсе САМ яисә СЕМ иҗекләре ярдәмендә белдерелә. Шулай итеп, бик кызык хәл барлыкка килә: кайбер галимнәр исәпләгәнчә, чуаш теле төрки телләрнең иң борынгысы, иң әүвәлгесе, ләкин башка төрки телләргә хас-ЛАР анда юк. Ничек болай булган?

Чуашларны борынгы болгарларның варислары дип исбат итәргә тырышучы галимнәр өчен иң күңелсезе шунда – чуаш теле ярдәмендә Болгар-Булгар дип тә, Биләр дип тә әйтеп булмый. Чуашча Болгар-ПАЛКАР дип, Болгарның башкаласы Биләр шәһәре ПҮЛЕР дип атала.

Тарихи чыганакларның берсендә дә ПАЛКАР дигән сүз телгә алынмый. Грек-латин, гарәп-фарсы, әрмән чыганакларында, рус елъязмаларында бары Болгар турында гына сүз бара. Ибн Фадланда бу сүз БЛГАР дип, Ибн Рустәдә, Гардизидә һәм Бакридә БЛКАР дип языла...

Мәхмүд Кашгарый монгол яуларыннан ике йөз еллар элегрәк яши. Аның сүзлегендә күптөрле төрки кабиләләр телгә алына, аларның тел үрнәкләре теркәлә. Ләкин М.Кашгарый чуаш телен яисә аңа охшаш телне белми. М.Кашгарый теркәгән тел фактлары болгар-чуаш, хазар-чуаш теорияләренә тулысынча каршы килә. Мәсәлән, кайберәүләр Чуаш сүзен САВИР-сувар сүзеннән чыгара. М.Кашгарый язганча, суварлар болгарлар, кыпчаклар, бәҗәнәкләр белән якын тугандаш. «Башка төрки телләрдә АЙАК диелсә, кыпчак, йәмәк, сувар, болгар телләрендә АЗАК диелә», – дип яза М.Кашгарый. Әлерәк кенә күреп киткәнчә, чуаш телендә «аяк» АЗАК та, АЙАК та

түгел, ә УРА. Һәм менә шушы сүзләр генә дә суварның чуаш була алмавын тулысынча исбат итә булса кирәк»[72].

Чуваш халкының этник тарихы һәм теле, күп гасырлар элек ислам динендә булганлыгы мәсьәләләренең хәзергә өйрәнелеп бетмәгән кайбер үзенчәлекләрен ачыклау – әлбәттә, белгечләр вазифасы.

## Тау ягындагы борынгы кала урыннары

Минһаҗетдин Җәбәли шәһри Болгарны болай дип тасвирлап үткән: «Болгар кальгасе бик олуг кальга булган. Шәһәр үзе йөз чакрымга кариб булган, унике пулад булган, хәддин мәдрәсәләр булган». Ул шулай ук борынгы Болгар илендәге шәһәр-калаларның кайберләрен санап үткән һәм болай язган: «Болгар тарафында кала, шәһәр, ныгытма урыны чиксез күп ки, шулар җөмләсеннән мәшһүрләре: Бүләр, Кече Болгар, Сәмәндәр, Бараж шәһәре һәм Казан шәһәре. Безнең Тау ягында Зөя буенда дүрт кала бар: берсе – Кири авылы янында Кошман шәһәре, янә берсе – Өтәк авылы янында Казан шәһәре, тагын берсе – Борындык янында Белыйби каласы, янә берсе – чуваш авылы янында Зәршәр авылының басуында – Хәзәр шәһәре. Мөселман зиратлары күп». Шул рәвешчә, автор Тау ягындагы чуваш һәм татар авыллары тирәләрендә борынгы кала урыннары булуын искәрткән һәм башка тарихи атамаларга да тукталган.

Тау ягындагы – Зөя елгасы буендагы борынгы кала урыннарына башка тарихчылар да әһәмият биргәннәр. Мәсәлән, С.М.Шпилевский 1877 елда басылган хезмәтендә Өтәк авылы янындагы кала урынын һәм Япанчы каласын тасвирлаган[73]. Казан император университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте тарафыннан тарихчы Гайнетдин Әхмәрев 1909 елда Зөя һәм Тәтеш өязләрендәге археоло-

---

[72] Фәттах Н. Чуаш теле һәм аның борынгылыгы // Мәдәни җомга. – 2022. – 30 декабрь (№51). – Б. 16–17. Авторның үз имлясы (мәсәлән, «чуаш» дип язуы) саклanды.

[73] Шпилевский С.М. Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии. – Казань: типогр. ун-та, 1877. – С. 490–495.

гик урыннарны тикшерергә барган. Кири авылы янында иске кала урыны турында Износковның хәбәре булса да, Г.Әхмәрев андый искелек калдыкларына юлыкмавын һәм картларның да андый нәрсә булганын хәтерләмәүләрен белдергән[74]. Югыйсә, Әхмәревтән өч дистә ел әүвәл М.Җәбәли дә кала урыны бар дип язган булган.

Өтәк авылы (русча атамасы Городище) хәзерге вакытта Яшел Үзән районына керә. Г.Әхмәрев 1909 елгы махсус сәфәрендә Зөя елгасының сул ягында урнашкан татар авылы Өтәктәге әүвәлге кала урынын тасвирлаган, аннан 1 чакрымнан артыграк арада җир асты юлы ачыклануын язган[75].

Ул урынны Минһаҗетдин Җәбәлинең «Казан» шәһәре дип язуы ялгышлык белән булгандырмы, әллә Казан ханлыгы чорына бәйләп караудан шундый атама белән дә йөртелгәнме – бу мәсьәләгә, ихтимал, тарихчылар ачыклык кертә алыр. Һәрхәлдә, Тау ягының бу төбәгендә «Казан» дип аталган торак урыннары башка чыганакларда юк шикелле. Әлеге төбәкнең Тау Иле авылы янындагы борынгы кала урынында элек Казан ханнары яшәгән дигән риваятькә[76] охшаш ниндидер бәйләнеш, бәлки, Өтәк очрагында да булгандыр.

Хәзерге Кайбыч районының Борындык авылы янындагы борынгы кала урыны тарихчылар тарафыннан «Япанчы» шәһәрлеге дип йөртелгәнлеге мәгълүм. Гайнетдин Әхмәрев ни өчен шулай аталганын, Казан ханлыгы чоры яугире Япанчыга бәйлелеген беркем дә белмәвен, халык арасында аның нинди дә булса исем белән йөртелмәвен язып калдырган. Археологик табылдыкларга нигезләнеп, Әхмәрев бу каланы Болгар чорына нисбәтле дип билгеләгән[77]. Ул урынны

[74] Гайнетдин Әхмәрев: тарихи-документаль җыентык..., 2000. – Б. 322.
[75] Шунда ук. – Б. 323–324.
[76] Шпилевский С.М. Древние города и другие булгарско-татарские памятники..., 1877. – С. 490; Гайнетдин Әхмәрев: тарихи-документаль җыентык..., 2000. – Б. 322. Бу галимнәр әүвәлге биләмә документларында (грамоталарда) шундагы шәһәрлек тирәсендәге җирләрне Казан ханы Мөхәммәтәмин исеменә бәйле булган дип язганнар.
[77] Гайнетдин Әхмәрев: тарихи-документаль җыентык..., 2000. – Б. 324.

Минһаҗетдин мулла «Япанчы» исеме белән белдермәгәнлеге һәм башкача – «Ак би» («Белый би»), «Бузай» рәвешләрендә теркәгән булуы да кызыклы.

Әхмәрев язганча, Борындык авылы биләмәсендәге ул урында якын-тирә төбәктә яшәгән татарлар ел саен «Кала алды» дип аталган җыен уздырып килгәннәр, аннан соң җыен Татар Наратлысы авылында үткәрелә башлаган (анда 7 авыл халкы катнашкан). Гайнетдин Әхмәревнең Гөбенә елгасы буендагы Япанчы каласы урынына багышланган махсус тикшерүе элегрәк – 1894 елда да басылып чыккан[78]. Әлеге мәкаләсендә ул «Кала җыены»на меңнәрчә татарлар килгәнен әйткән. Татар Наратлысы авылының Хуҗа Ишмөхәммәтев (1860 нчы елларда вафат булган) язмаларына һәм җирле халык риваятьләренә караганда, бу урында утка табынучы мәҗүсиләр яшәгән. Татарлар куып җибәргәч алар төньякка – Идел елгасының аргы ягына күчеп киткәннәр. Г.Әхмәрев халык риваятен дә бәян иткән: Бүләрдән хан улы Нурат ике мең кешелек гаскәр белән бу каланың хакименә ясак түләтергә килгән. Мондагы хан түләүдән баш тарткач, Нуратның кардәше дә шул хәтле үк гаскәр белән килеп, каланы яулап алганнар һәм яндырганнар. Бу урындагы археологик табылдыкларга нигезләнеп, Әхмәрев шәһәрлек халкының мәҗүсилектә булганын раслаган, охшаш әйберләр чирмеш һәм удмуртларга хас икәнен язган[79].

М.Җәбәли Зәршәр дигән атаманың «Хәзәр шәһәре» дигәннән кыскартылып үзгәргәнен белдергән. Ул хезмәтенең икенче бер урынында Тау ягы татарлары «шәһәр» сүзен «шәр» дип кенә әйтүләрен дә искәрткән[80].

Минһаҗетдин Җәбәли Бәчек һәм Төрләмәс авыллары янында борынгы тарихи урыннар барлыгын язып калдырган. Ул Бәчек басуындагы «Тугыз түбә» дигән урынны хәзәрләр

---

[78] Шунда ук. – Б. 218–222.

[79] Шунда ук. – Б. 220–221.

[80] Каюм Насыйри да үз туган авылы Шырданның атамасына карата «шыр» – «шәһәр» сүзе булып, анда кешеләрнең Болгар шәһәреннән килүенә бәйләп, «шәһәрдән» дип әйтүдән Шырдан атамасы чыккан, дип язган.

белән сугышырга килгән гарәп гаскәренең өч йөзләп киез чатырлары торганнан калган дип аңлаткан. Бәчеккә күршедәге Төрләмәс исемле чуваш авылы басуында («Турхан басуы») борынгы хәзәр шәһәрен гарәпләр яулап алганнар, Турхан – субашы (ягъни гаскәр башлыгы) булган дип язган. «Гарәп гаскәренең чатыр урыннары» дип, Минһаҗетдин мулла үзе генә фаразлап язганмы, әллә ул турыда элек җирле риваятьләр йөргәнме – билгесез.

Бәчек авылы янындагы серле калкулыкларны Каюм Насыйри да кызыксынып тасвирлаган. «Урысбага кыры белән Бәчек авылы арасында тугыз җирдә кечерәк өй урыны кадәр түбәсыман тау кебек булып торган урыннарны күреп, монда ни бар икән дип атны туктатып, арбадан төшеп, ул түбәсыман җирләрне һәркайсын як-ягыннан яхшылап тикшереп карадык. Әмма, һичбер шөбһәсез, үзеннән-үзе булган түбәләр түгелдер. Мәгәр адәм кулыннан чыккан эшләрдер. Юлның уң ягында берсе бар, бигерәк билгеле. Биеклеге җирдән аршын ярым кадәр; түбә булып таусыман тора. Түбәсендә урта җире азрак баткан, чокырланып тора. Түбәнең әйләнә җире чокыр булып, гүя, туфрагын алып өстенә ташлаганга охшый. Гүя, астында бер баз кебек зимләнкә булып, базның түшәме җимерелгәч, уртасы төшеп киткән шикелле. Ул җирне хәзердә Рысбуга кешеләре «Тугыз түбә» дип йөртәләр икән. Картлардан сорашкач мәгълүм булды, аларның риваяте буенча угрылар, качкыннар зимләнкәсе булгандыр... Әгәр дә әмер булып, шул җирләрне казып каралса, бәлки бер-бер төрле иске нәрсәләр вә һәм шул замандагы әсәрләре табылмас иде микән дип күңел гуаһлык бирәдер. Шул авыл халкы гәрчә «Тугыз түбә» дип йөрсәләр дә, ул түбә тукыз гына түгел, без санадык – уникеләп бардыр һәм бер тирәдәдер»[81].

Бәчек авылыннан 2 чакрым төньяктагы һәм Төрләмә станциясеннән 2 чакрым көнчыгыш тарафтагы борынгы

[81] Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре..., 1926. – Б. 48; Каюм Насыйри: әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык..., 2017. – Б. 265–266.

курганнарны тарихчы Гайнетдин Әхмәрев тә телгә алган[82]. Ул Бәчек һәм Төрләмә янында егермеләп курган барлыгын билгеләгән.

Совет заманындагы һәм аннан соңгы чордагы тарихчылар тарафыннан Яшел Үзән районының төп археологик һәм эпиграфик истәлекләре арасында Бәчек курганнары («Васюковские курганы») да әйтелгән һәм ул бронза чорына карый дип билгеләнгән («абашевская культура»)[83]. Фәндә билгеле булганча, «Абашево» исеме белән бәйле курганнар Идел һәм Көньяк Урал, Дон елгасы буйларында якынча безнең эрага кадәр икенче меңьеллыкның 2–3 нче чирекләренә нисбәтле. Бу археологик истәлекләр галимнәр тарафыннан 1925 елда тасвирланган һәм 1950–1970 елларда өйрәнелгән. Татарстанда андый төр археологик культурага караган урыннар Яшел Үзән районының Бәчек һәм Карашәм авыллары янында, Югары Ослан районының Йолдыз авылы һәм Актаныш районының Такталачык авылы тирәләрендә ачыкланган.

Монда әйтеп һәм искә алып үтелгән борынгы тарихи урыннарның соңгырак тарихчылар тарафыннан да өйрәнелгәнлеге белән бергә, М.Җәбәлидә теркәлгән атамалары бүтәнчә («Ак би», «Казан», «Бәһрә», «Бузай») һәм фәндә билгесез булулары ягыннан игътибарга лаек.

## Хезмәттә тасвирланган ташъязма истәлекләр

Борынгы чорлардан калган ышанычлы язма чыганаклар – кабер ташлары галимнәрнең игътибарын җәлеп иткән. XIX гасырда яшәгән татар тарихчылары Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов, К.Насыйри Идел буендагы борынгы болгар-татар ташъязмаларын өйрәнгәннәр.

Минһаҗетдин Җәбәли дә тарихи әсәрендә, башка чыганаклар белән бергә, борынгы кабер ташларына әһәмият биргән

[82] Гайнетдин Әхмәрев: тарихи-документаль җыентык..., 2000. – Б. 322.

[83] Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – С.131–132; Зеленодольский регион: проблемы истории и культуры..., 2003. – 368.

дип, алда әйтеп уздык. Аның эпиграфик истәлекләргә аеруча җитди мөнәсәбәттә булганын үз хезмәтенең исем вариантлары ук күрсәтеп тора. Чөнки ул аларда кабер ташларының ышанычлы дәлил икәнлеген, кайсы чорныкы булуларын, хәтта нинди язу төрендә эшләнгәннәрен дә ачык итеп язган.

Ул үзе имам булып гомер кичергән Бәчек авылындагы борынгы кабер ташын күчереп ясавы ягыннан аерым игътибарга лаек. Аның рәсеме төп-төгәл үк булып җитмәсә дә, шундый рәвештә теркәп калдыруы ягыннан әһәмиятле. Минһаҗетдин мулла ташъязманың алгы, арткы һәм ян-якларындагы язуларын күчереп, таш рәсеме рәвешендә теркәгән.

Минһаҗетдин Җәбәли Бәчек ташъязмасының 1–3 юлларындагы язуларын дөрес күчереп алса да, елын «тарих тукуз йөз йитедә» дип һәм аннан соңгы мәгълүматны (мәрхүмнең исемен һ.б.) ялгыш укыган. Ташъязманың 4–7 юлларындагы мәгълүматны ул «Шәгъбан бине Әсәд бине Әмур хан бине Әбамган бине Шыгал хан бине Төнихуҗа угылы Бәчүкә» дип, мәрхүмнең төп шәҗәрә буыннары рәвешендә теркәгән. Кабер ташындагы кеше исемнәре Минһаҗетдин мулла кульязмасында өч мәртәбә кабатланган. Аларның исемнәрендә бераз аерма бар:

1) «...Төнихуҗа угылы» (ташъязманың рәсеме эчендә, 23б кәгазьдә);

2) «...Төнихуҗа Бәчүкә угылы» (23б кәгазь читендә);

3) «...Төнихуҗа угылы Бәчүкә угылы» (23б кәгазь читендә).

Боларның беренчесендә «Бәчүкә» дигән исем юк. Шулай ук Минһаҗетдин мулла ясаган рәсемдә «хуҗа» дигәннән соң «Бәчүкә» дип укырлык бернинди хәреф элементлары да күренми. Ихтимал, ул «хуҗа» сүзенең ахыргы – бормалы хәрефен «Бәчү» дип кабул итеп, шуңа 7 нче юлдагы «кяфер» сүзенең «кя» («кәф» һәм «әлиф») иҗеген кушып – Бәчүкә рәвешендә укыган дип фаразларга мөмкин. Гәрчә үзе 7 нче юлдагы «кяфер...» гыйбарәсен дә текстында кабатлаган.

Икенче һәм өченче пунктлардагыча язылышлар авторның кабер ташына карата аңлатмасында теркәлгәннәр. Икенчесендә

Минһаҗетдин хәзрәт укылышындагы кабер иясе «Шәгъбан бине Әсәд»тән соң күп буыннар рәвешендә «бине», «бине» дип тезеп, нәсел тармагы чылбырының иң әүвәлге бабасы, имеш, «Бәчүкә» исемле булган дип аңлашыла. Өченчесендә Бәчүкә исеменнән соңгы «угылы» сүзе артык язылган дип гөманларга мөмкин. Һәрхәлдә, ташъязманың рәсемендә Бәчүкә дигән исем бөтенләй юклыгын кабатлап әйтәбез.

Минһаҗетдин хәзрәт ташбилгенең елын ялгыш һиҗри 907 дип укыган дата, милади буенча 1501–1502 елларга туры килгән булыр иде. Үзе укыган рәвештәге исемнәргә карата «Бу таш белдерә – Бәчек авылы җиде йөз елдан бирле авыл булып яшәвен» дигән аңлатмасына караганда, һиҗри буенча 700 елны киметкәч, XIII гасыр башы (1213–1214 еллар) күзаллана. Шул рәвешчә, хезмәтнең авторы Бәчек авылының Болгар җимерелгәнче үк булганын белдергән.

Хезмәттәшебез Ирек әфәнде Һадиев белән бергә 2013 елда Яшел Үзән районындагы борынгы кабер ташларын өйрәнгән вакытта бу ташъязманың текстын күчереп, үзен фотога төшергән идек. Әмма без күргәндә аның алгы ягындагы түбәнге юлларының язулары тулысынча сакланмаган һәм таш туфракка тирән баткан иде. Ташъязма текстының безнең тарафтан укылган өлеше (алгы ягы):

1) калә Аллаһу Тәбарәкә вә Тәгалә

2) көллү мән галәйһа фанин вә йәбка вәҗһү

3) Раббикә Зөл-Җәлали вәл-Икрами

4) тарих тукуз йөз кырык йитед-

5) -ә шәгъбан айында хан Мурамга ба-

6) -рганда Туйхуҗа угылы ...

7) кяфер [кулындин шәһид булды]

Арткы ягында:

1) Бу ләүхне гыйалы

2) Бәйтән(?)

3) бина кыйлды

Уң ягында: Калә эн-нәби галәйһиссәлам әд-дөнья мәзрагатүл-ахирәти.



*Бәчек авылы зиратындагы 1540 елгы кабер ташы*

Сул ягында: Калә ән-нәби галәйһиссәлам әд-дөнья сагать фәҗгальһа тагать.

Үлчәмнәре: 141 x 54 x 26 см.

Һиҗри 947 елның шәгъбан ае милади буенча 1540 елның декабренә туры килә.

Бу эпиграфик истәлекнең Минһаҗетдин мулла тара-

фыннан ясалган рәсеме буенча тарихи ташъязманың хәзерге вакыткача сакланмаган диярлек ахыргы юллары ачыклана. Аның рәсемендәге 7 нче юлда: «кяфер кулындин шәһид булды» дигән сүзләре аермачык укыла. Бу исә без күреп укыган текстны тулыландыруы ягыннан бик әһәмиятле.

Хезмәт авторының рәсемендә һәм аңа карата аңлатмада «Төнихуҗа» дип язылган исемне шулай уку ихтималы да бар. Әмма Җәбәлинең Бәчүкә дигән фаразы авылга исеме берегеп калган Бәчек (гүяки, кабер ташы иясенең иң әүвәлге бабасы) исеменә яраштырылган фантазиядән генә тугандыр.

Кабер ташының арткы тарафындагы язулары бик начар сакланган. Минһаҗетдин хәзрәт рәсеменнән күренгәнчә, ташъязма шул заманда ук таушалганлыктан, андагы сүзләре тулаем укырлык булмаган.

Мәгърифәтче галим Каюм Насыйри «Археология материаллары (Зөя өязе авыллары буенча)» мәкаләсендә Бәчек авылы һәм аның зиратындагы борынгы кабер ташы турында да язган. (Бу мәкалә беренче мәртәбә 1926 елда басылган һәм аннан соң К.Насыйриның «Сайланма әсәрләре»нә (1974, 2005 еллар) һ.б. җыентыкларына кертелгән. Каюм Насыйри мәкаләсендә Бәчек авылы зиратындагы борынгы ташъязма ядкяр һәм аңа бәйле мәгълүмат бу рәвешле тасвирланган: «Хәзердә Бәчек авылы зиратында бер таш бар; күп сүзләре уалып төшкән, укырга мөмкин түгел. Без мулла Нигъмәтҗан вә һәм Габделкави белән барып укып, язып алдык. Калган сүзләре бары ошбудыр: «тарих тукуз йөз йитедә» дигән сүз күренә вә һәм «Шәгъбан бине Әсәд» дигән сүзе бар. Моның язылганына һәм дүрт йөз елга кариб, ягъни язылганына 383 еллар буладыр. 1490 нчы елларда язылгандыр[84]; Казан алынмастан күп элгәредер. Риваять кылалар: Шәгъбан бине Әсәд дигән адәм Бәчек авылында бик зур голәмадан, кәрамәт иясе адәм булган, имеш, диләр. Хәттә, бәгъзе картларның риваяте буенча, ул ташны ниндәен кеше

[84] Ташта язылган датаны 907 ел рәвешендә ялгыш укып һәм аны 1490 елларга туры килә дип, К.Насыйри хаталанган. Алда әйткәнебезчә, 907 һиҗри ел милади буенча 1501–1502 елларга туры килер иде.

язып куйганын белгән адәм юк. Гүяки, таш шунда үзеннән-үзе булган, имеш, диләр. Илле җиденче ел Бәчек авылының Сәйфулла мулла эткәмез мәрхүмгә сөйләгәне хәтеремдә калгандыр: кайда булса да, бер җирдә мөдәррис булып дәрес әйткән адәмдер»[85]. К.Насыйри мәкаләсенең кулъязмасында кабер ташы иясе турында мондый юллар теркәлгән: «Анда бер газиз бар икән дип риваять кыйлалар... Бик кәрамәт иясе адәм диләр» (ягъни, изге зат булганын сөйләгәннәр). Ташның үзе турында «Хәтта бәгъзе картларның риваяте буенча кодрәт белән ясалган таштыр, диләр»[86] (Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән).

Каюм Насыйри язганга караганда, кабер ташында аның елы («тарих тукуз йөз йитедә» һәм «Шәгъбан бине Әсәд» дигән исеме генә танылган. К.Насыйри «Шәгъбан бине Әсәд»нең укымышлы зат булганлыгын Сәйфулла мулладан[87] риваять итеп теркәвеннән күренгәнчә, Бәчек зиратындагы кабер ташы иясенең исеме К.Насыйрига һәм Минһаҗетдин муллага, хәтта аның әтисе Сәйфулла хәзрәткә хәтле үк Шәгъбан бине Әсәд дип ялгыш укылган булган һәм халык арасында шул рәвешле хаталы исем телгә алып йөртелгән.


Бәчек зиратындагы таш текстының да аерым сүзләре әүвәлге бер чорда ялгыш танылуына бәйле рәвештә шул авылның имамы Сәйфулла хәзрәт, аның улы Минһаҗетдин мулла һәм Каюм Насыйри да бер төрле үк исемнәрне – «Шәгъбан бине Әсәд» дип укып һәм язып килгәнлекләре гайре табигый күренеш түгел. Ягъни, алар үзләренә хәтле үк кемнеңдер ялгыш итеп укыганына ияреп, хаталы исемнәрне тәкрарлаган булулары бик мөмкин. Фәннең эпиграфика тармагы белән шөгыльләнгән белгечләрнең дә борынгы кабер ташларындагы

---

[85] Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре..., 1926. – Б. 47; Каюм Насыйри: әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык..., 2017. – Б. 264–265.

[86] Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «601т» шифры белән саклана торган кулъязма, 19а кәгазь.

[87] К.Насыйри исемен атаган Бәчек мулласы Сәйфулла – нәкъ менә Минһаҗетдин хәзрәтнең әтисе булган.



*Бәчек зиратындагы кабер ташыннан Каюм Насыйри күчереп алган текст өлеше*

кайчандыр ялгыш укылган гыйбарәләргә иярүе һәм кабатлавы мәгълүм[88]. Борынгы кабер ташларына һәм алардан ялгыш укылган исемнәренә бәйле уйдырма риваятьләр халык арасында бүтән эпиграфик истәлекләр уңаеннан да сөйләнгән.

Тагын шуңа да игътибар итәргә кирәк, К.Насыйри Бәчек ташъязмасының күренгән урыннары дип санаулы гына сүзләрне (ике юллык) һәм аларны да ялгыш танып, теркәп калдырган. Әмма замандашы Минһаҗетдин мулла исә, исемнәрне һ.б. гыйбарәләрне хаталы күчергән булуына карамастан, барлыгы 7 юллы текстны тулаем язып алган. Өстәвенә, янякларындагы һәм арткы ягындагы күренгән хәтле язуларны да күчергән.

[88]Мәсәлән, Биектау районының Ямаширмә авылы зиратындагы 1382 елгы кабер ташыннан ялгыш танылып, «Инүк» дип фаразланган һәм китаптан-китапка күчеп килгән исемнең дөресе – Габделмөлүк булганлыгы ачыкланды; Теләче районының Тәмте авылы янында аерым каберлектәге исемнәр «Абыз Риким Чиремеш улы Язнаш» дип, тарихи китапларда күчәкүчә йөртелсә дә, дөреслектә «Чиремеш улы Яныш» икәнлеге тәгаенләнде (*Мәрданов Р., Һадиев И. Ямаширмә зиратында – Алтын Урда һәм Казан ханлыгы истәлекләре // Безнең мирас. – 2018. – №10. – Б. 17–18; Һадиев И., Мәрданов Р. Теләче төбәгенең борынгы ташъязма истәлекләре // Безнең мирас. – 2022. – №12. – Б. 18*).

Каюм Насыйриның Зөя өязе авыллары тарихы кулъязмасы җыентыгында Бәчек авылындагы кабер ташының ике юлын гади карандаш белән күчереп алган фрагменты сакланган[89]. Язуы – «Шәгъбан айында хан Мурамга ба» өлеше һәм ялгыш «Чәләби Хуҗа» рәвешендәге кеше исеме.

Кабер ташындагы язуларны һәм хәреф элементларын дөрес диярлек рәвештә күчереп алган булсалар да, Каюм Насыйри да, Минһаҗетдин Җәбәли дә укылышта ялгышканнар. Мөселман календаре буенча ай исемен белдергән «шәгъбан»ны алар кеше исеме дип аңлаганнар һәм аннан соң уелган «айында» сүзен «Әсәд» дип, шулай ук хаталанганнар. Ә мөселман каберенә куелган кабер ташында «Мурам» (Муром) атамасы язылган булу ихтималын күз алдына да китермәгәннәр, күрәсең. Шунлыктан, рус каласы атамасының хәреф-иҗекләре мәрхүмнең бабалары исеменең аерым өлешләре рәвешендә кабул ителгән. Ташъязмадагы «хан Мурамга барганда» дигән гыйбарәне алар «Әмур хан бине Әбамган» рәвешендә укыган. Бу уңайдан, гомумән, татар палеографиясенә хас бер күренешне искә алып китү дә урынлы булыр – гарәп хәрефләрендә язылган нинди дә булса иске текстта берәр рус яки Европа сүзе-атамасы очраганда, сирәк һәм гайре табигыйрак күренеш булганлыктан, тәҗрибәле археографлар да сагаеп кала.

«Хан Мурамга барганда» дигән гыйбарә бу ташъязманың милли тарихыбыз өчен кыйммәтле чыганак буларак әһәмиятен ачык күрсәтә. Казан ханлыгы чорыннан сакланып калган татар ташъязма истәлекләрендә «урус килгәндә», «Мәскәү явы килгәндә» кебек берничә факт мәгълүм[90]. «Кяфер кулыннан шәһид булды» дип язылган, XVI гасырның беренче ярты-

[89] КФУның Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә «601т» шифры белән саклана торган кулъязма, 37б кәгазь.

[90] Мәрданов Р., Һадиев И. Әтнә төбәгенең ташъязма истәлекләре. – Казан: Татар. китап нәшр., 2018. – Б. 202; Мәрданов Р., Һадиев И. Балык Бистәсе районының борынгы ташъязма истәлекләре // Безнең мирас. – 2023. – №6. – Б. 33–34; Гариф Н. Казан ханлыгы чоры ташъязмалары. – Казан: ТФА Тарих ин-ты басмаханәсе, 2010. – Б. 72–73.

сыннан хәзерге замангача сакланган дистәләрчә кабер ташлары Мәскәү белән Казан, рус-татар сугышлары чорларына нисбәтле. Ә менә Казан ханын күздә тоткан, «хан» титулы анык итеп язылган, безгә билгеле татар эпиграфик истәлеге шушы – Бәчек зиратында гына сакланган.

Тарихтан мәгълүм булганча, әлеге ташта язылган 947 елның шәгъбан аенда – ягъни, 1540 елның декабрендә Казан ханы Сафагәрәй зур гаскәр белән рус җирләренә яу чабып, Муромны һәм башка калаларны камап, яулап, күп әсирләр алып кайткан. Бу хакта тарихчы Һади Атласи болай язган: «Урысларның татарлар белән дуслыклары ничаклы булса, татарларның да урысларга дуслыгы шул чаклы гына иде. Болар арасында бер яктан илчеләр йөрсә, икенче яктан гаскәр йөреп, бер йортның икенчесен кырган чаклар күп буладыр иде. 1540 елның 18 декабрендә Сафагәрәй хан Кырым, нугай, казанлылардан җыелган 30 мең яу белән, искәртмәстән Муром өстенә һөҗүм итте. Сафагәрәй хан Муромны ике көн камап торды. Явының бер өлешен тирә-яктагы авылларны таларга җибәрмеш иде. Урыслар Казан йортына баскынлык иткәндә нинди ерткычлыклар кылсалар, татарлар да Русия өстенә баскынлык кылганда шуларны кылалар иде...»[91].

Гомумән, 1540 елда «кяфер кулыннан шәһит» булган мәрхүмнәрнең ташъязма истәлекләре Әтнә районының Иске Өҗем авылы янындагы аерым каберлектә, Кече Әтнә авылының борынгы зиратында, Югары Сәрдә авылындагы аерым каберлектә[92], Комыргуҗа авылы зиратында[93], Арча районының Татар Кадрәге авылы зиратында хәзергәчә сакланган булуына нигезләнеп, ул кабер ияләре дә нәкъ шул вакытта – Сафагәрәй ханның Муром явы чорында һәлак булганнар дияргә нигез бар.

---

[91] Атласи Һ. Себер тарихы. Сөен-бикә. Казан ханлыгы (Тарихи әсәрләр). – Казан: Татар. китап нәшр., 1992. – Б. 313.

[92] Мәрданов Р., Һадиев И. Әтнә төбәгенең ташъязма истәлекләре. – Казан: Татар. китап нәшр., 2018. – Б. 186, 201, 505.

[93] Гайнетдинов А. Әтнә районы эпиграфик истәлекләре. – Казан: ТР ФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих ин-ты, 2017. – Б. 145.

Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты фәнни хезмәткәре А.Гайнетдиновның «Яшел Үзән районы эпиграфик истәлекләре» хезмәтендә (26–27 битләрдә) Бәчек зиратындагы тарихи ташъязма тексты бирелгән һәм фоторәсеме урын алган. Кабер ташының датасы һәм башка мәгълүматлары дөрес укылган[94]. Гайнетдинов бу таштагы мәрхүмнең исеме К.Насыйри тарафыннан ялгыш танылган булуын искәрткән. Әмма гыйльми оешма белгече ташъязма истәлектәге «Хан Мурамга барганда» гыйбарәсенә бәйле тулырак тарихи мәгълүмат биргән булса, Бәчек зиратындагы бу ташъязманың коры мәгълүматын җиткерү белән чикләнүдән тыш, фәнни яктан нигезле тикшереп, әһәмиятен дә билгеләсә, әлбәттә, бик күркәм булыр иде. Тик андый мәгълүмат та, Минһаҗетдин мулла кульъязмасында әлеге ташбилгенең рәсеме барлыгы, шулай ук К.Насыйри кульъязмаларында шушы кабер ташының ике юлы күчермәсе саклануы турында да А.Гайнетдинов китабында бер сүз дә язылмаган. Гәрчә, фәнни хезмәтләрдә язма чыганакларны комплекслы итеп өйрәнү тәҗрибәсе бар. Татар эпиграфик истәлекләренә багышланган китапларга мөрәҗәгать итүчеләр фәнни бәяләмәгә, тәфсилле аңлатмаларга аеруча мохтаҗ.

***

Минһаҗетдин Җәбәли хезмәтендә чуваш авыллары зиратларындагы мөселманнарга куелган башка ташъязмалар да искә алынган.

---

[94] Шунысын искәртергә кирәк: А.Гайнетдинов, үзенә хас булганча, ташъязманың уң һәм сул яннарындагы язуларын бутап биргән. Ягъни, кабер ташының уң кырындагы текстын «сул ягы» дип һәм сулыныкын «уң ягы» дип ялгыш билгеләгән. Шул ук Бәчек авылы зиратындагы Минһаҗетдин мулла кабер ташының уң һәм сул якларының текстлары да аның тарафыннан ялгыш (бутап) тәкъдим ителгән. А.Гайнетдинов кабер ташларының уң һәм сул якларын билгеләү мәсьәләсендә үзенең ялгышын танымавы өстенә, аны башкаларның хатасы итеп күрсәтә (*Һадиев И., Мәрданов Р. Татар теле – фән теле: тарихи чыганакларга багышланган татарча фәнни хезмәтләрне нәшер итү культурасы турында. – Казан, 2021. – Б. 28*).

Гомумән, XIX һәм XX гасырлардагы галимнәрнең язганнарыннан хәзерге Чувашстандагы борынгы зиратларда Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларына, шулай ук XVII–XVIII гасырларга нисбәтле мөселман кабер ташлары булуы билгеле. Һ.Йосыпов Чувашия АССРның 22 торак пунктында борынгы мөселман кабер ташлары барлыгын искәрткән булган[95].

Чувашстандагы татар-мөселман кабер ташлары Венер Усманов тарафыннан өйрәнелеп, әле узган 2022 елда гына басылып чыккан китабы күп нәрсәләргә ачыклык кертергә ярдәм итә.

Шигали авылының иске зиратындагы ике кабер ташы турында Минһаҗетдин мулла язганнан аларның XVI гасырга нисбәтле булуын чамаларга мөмкин[96]. Әлеге ташларда уелган даталарны һәм мәрхүмнәрнең исемнәрен Минһаҗетдин мулла һиҗри 140 ел («Әсәд кяфер кулындин шәһид») һәм 900 нче ел («Әсәди улы Тенеш кяфер кулындин шәһид») дип таныган.

Беренчесенең елы чынлыкта 940 булып, «тукуз» сүзе танылып җитмәгәнлеге аңлашыла, ә икенче ташның «тукуз йөз» дигәннән соңгы саннары укылмаган. Боларның шулай икәнен галим Каюм Насыйри язмаларыннан да аңлап була. Мәгълүм булганча, К.Насыйри да Шигали авылы тарихын язган һәм аның зиратындагы әүвәлге мөселман кабер ташларын тасвирлаган. Минһаҗетдин мулла текстында әйтелгән ташларны К.Насыйри бу рәвешле язган: «анда өч-дүрт таш бар, язулары бик нәфис, ташларның берсендә «...йөз кырык тукызда», «йөз» дигән сүзнең алдындагысы җимерелеп төшкән». Ташларның икенчесен ул: «тукыз йөз дә иллектә Хаҗ угылы Шиш...»[97] дип таныган.

---

[95] Шунда ук. – Б. 24.

[96] Совет чорында Чувашстанның Янтиковский районындагы Шигали авылы зиратында XVI гасырның беренче яртысына нисбәтле кабер ташы саклануы турында татар эпиграфика белгече Һарун Йосыпов китабында да мәгълүмат теркәлгән (*Юсупов Г. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.–Л.: «Наука», 1960. – С. 26*).

[97] Каюм Насыйри: әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык... – Б. 271–272.

Шигали ташъязмаларындагы кеше исемнәре дип «Әсәд» һәм «Әсәди» рәвешендә Минһаҗетдин Җәбәли укыган сүзләр «айында» дигәнне ялгыш танудан чыккан. Шундый ук хаталы укылышны Бәчек авылы зиратындагы ташъязма мисалында да күреп үттек. Минһаҗетдин мулла икенче таштагы «Тенеш» исемен дөрес укыган, ә К.Насыйрида ул «Хаҗ угылы Шеш» дип бирелгән.

Минһаҗетдин мулла кулъязмасының шушы ташларны тасвирлаган 15б кәгазендә «рәсме госманийә вә пашаи рәсем» дигән гыйбарә кулланылган. Ягъни, госманлы төрекләренә, аларның да хәрби һәм хөкүмәт хезмәткәрләре даирәсенә хас язу төре дип тәгаенләнгән. Әмма госманлыларда «пашаи рәсем» дигән термин булганлыгы билгеле түгел. Минһаҗетдин мулла мондый атаманы остазы Гали ишаннан ишеткән булуы ихтимал. Чөнки ишан хәзрәт Урта Азиядә, Әфганстанда һәм Һиндстанда белем эстәгән. Ә ул якларда гарәп язуының «фарсы язуы» дип тә билгеле булган «тәгъликъ» төре киң таралган. Фараз кылуыбызча, тәгълик төрен кулланган төбәкләр нәсех һәм сөлес төрләрен «госманлы язуы» дип атаганнардыр. Бәлки, ул язу төрләре изге урыннарга хаҗга баручы мөселманнарга рөхсәт документлары биргән төрек хәрбиләре тарафыннан кулланылган булуына нисбәттә «пашаи» дип тә йөртелгәндер.

«Тенеш» исеме уелган кабер ташы хәзерге вакытта Шигали зиратыннан китерелеп, Чуваш Милли музеенда саклана. Аның фотосурәтләрен һәм эпиграфик ядкярләрне өйрәнүче Венер Усманов тарафыннан күчереп ясалган рәсемен Чувашстан Республикасындагы мөселман эпиграфик истәлекләренә багышланган китапта күрергә мөмкин[98]. Усманов китабында бу ташъязманың «тукуз йөз дә иллик йитедә» дигән датасы – һиҗри 957 елга (милади 1542–1543 елларга) каравы һәм Тениш Хаҗи улының каберенә куелган булуы язылган. Әмма «Хаҗи» (К.Насыйрида: «Хаҗ») дип укылган исемнең чынлык-

[98] Усманов В. Чувашстан Республикасы татар эпиграфик һәйкәлләре. – Казан, 2022. – Б. 71, 84.

та «Хәмаж» икәнлеге эпиграфик истәлекнең рәсеменнән ачык күренә[99], һиҗри 957 ел исә, дөреслектә, милади белән 1550 елга туры килә.

Минһаҗетдин Җәбәлинең «Мартын чуваш авылы Зиршир зиратында[100] мөселман ташы... меңдә йөздә дип, башкасы беленми» дигән мәгълүматы да бар. Бу истәлекнең төгәл елы, бәлки, 1106 булгандыр. Чөнки Шигали авылындагы Мартын каберлегеннән («Мартыновский могильник») 1992 елда Чабаксар шәһәренә – Чувашстан Дәүләт гуманитар фәннәр институтына китерелгән ташъязманың 1106 елгы икәнлеге билгеле. Шул ук институтта 1976 елда Шигали авылыннан китерелгән 1132 елгы ташъязма да саклана[101]. Һиҗри 1106 һәм 1132 еллардагы кабер ташларының милади буенча даталары 1694 (1695) һәм 1719 (1720) елларга туры килә[102].

Минһаҗетдин мулла хезмәтендә кайбер борынгы ташъязмаларда «әл-хаҗ Чәләби», «әфәнде» һ.б. язылганлыгы да әйтелгән. Ул Бакырчы күле янындагы кабер ташында «Мөхәммәд Чәләби» исеме язылган, ди. Бу ташъязмадагы исемнәрне 1855 елда К.Насыйриның әтисе Габденнасыйр хәзрәт тә «Мөхәммәд Чәләби» рәвешендә укыган булган[103.]

---

[99] Шунда ук. Китапның бит саннары куелмаган фото һәм график сурәтләре өлешендә.

[100] Аңлавыбызча, шул ук Шигали зиратының бер өлеше «Мартын зираты» дип йөртелгән. Чөнки К.Насыйри Шигали зиратында дип, һиҗри 1126 һәм 1130 еллардагы ташларны тасвирлаган (*Каюм Насыйри: әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык..., 2017. – Б. 272*).

[101] Фотолары һәм рәсемнәре китапта басылган: Усманов В. Чувашстан Республикасы татар эпиграфик һәйкәлләре. – Казан, 2022. – Б. 80, 81.

[102] Шигали зиратындагы XVI һәм XVIII гасырлардагы кабер ташлары мөселман чувашларныкы булып исәпләнсә дә, алар татар телендә язылганнар, текстларында бер генә чуваш сүзе дә юк. Җучи Олысына буйсынган Болгар вилайәтенең борынгы кабер ташларында XIV гасыр урталарына кадәрге чорда «чуваш сүзләре» (дөреслектә – борынгы болгар теле элементлары) кулланылган булса да, аннан соң XV–XVIII гасырлардагы эпиграфик истәлекләрдә алар бөтенләй юк.

[103] Каюм Насыйри: әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык..., 2017. – Б. 261.

Әҗбаба (Хаҗибаба) исемле чуваш авылында хаҗи Мөхәммәт Чәләби дигән кешегә бәйле риваять тә булган. Ул изге зат хаҗга баргач Истанбулда мәдрәсәдә укытып калган, ватанына кайтса – мөселман чувашлар диннән язып беткәннәр. Шуңа күрә, имеш, үзен Бакырчы зиратында җирләргә васыять әйтеп калдырган. Бу мәгълүматлар иң әүвәл К.Насыйриның 1877 елгы календарендә (46–47 битләрдә) дөнья күргән, аннан соң галимнең төрле еллардагы җыентыкларында да басылды[104]. К.Насыйриның хәзерге Яшел Үзән районындагы Татар Танае авылында сакланган XVI гасыр кабер ташында «әфәнде» дигән сүз укыганлыгы мәгълүм[105].

Иске ташъязма истәлекләрнең тарихи чыганак буларак әһәмиятен аңлап эш иткән Минһаҗетдин Җәбәли – татар эпиграфикасын өйрәнгән шәхесләр арасында телгә алынырга лаек зат.

Сүз уңаеннан, аның замандаш якташларын – Тау ягының тарихка һәм тарихи истәлекләргә мөкиббән киткән бүтән укымышлыларын да искә алырга тиешбез. Мәсәлән, хәзерге Яшел Үзән районындагы Кече Шырдан (элекке исеме – Югары Шырдан) авылы мулласы Габденнасыйр хәзрәт 1850 нче елларда, аның улы – мәшһүр галим Каюм Насыйри бераз соңгырак чорда иске кабер ташларын кызыксынып өйрәнгәннәр, хәзерге Буа районындагы Әлки авылы мулласы Баһаветдин хәзрәт тә борынгы кабер ташларын тикшерүгә әһәмият биргән, Шиһабетдин Мәрҗани тарихи хезмәтләрен язганда аңа күп ярдәм күрсәткән[106]. Баһаветдин мулла күчереп алган борынгы каберташ язуларының кайберләре хәзергәчә

[104] Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. 4 томда. Т. 1 / төз:. М.Гайнетдин. – Казан: Татар. китап нәшр., 2003. – Б. 350–352; Каюм Насыйри: әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык..., 2017. – Б. 261–262.

[105] Каюм Насыйри: әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык..., 2017. – Б. 250.

[106] Әхмәрев Г. Ватан вә милләт тарихы хакында // Казан мөхбире. – 1906. – 14 апр.; Шул ук // Гайнетдин Әхмәрев: тарихи-документаль җыентык..., 2000. – Б. 191.

сакланган. Нәтиҗә ясап әйтсәк, Минһаҗетдин мулла яшәгән чорда татарларның борынгы кабер ташларын кызыксынып өйрәнергә тырышкан якташлары булган. Әйтелгән әлеге шәхесләрдән соңгырак чордагы якташлары – хәзерге Яшел Үзән районының Татар Наратлысы авылында туган Гайнетдин Әхмәрев тә борынгы эпиграфик истәлекләрне өйрәнүдә күп тырышлык күрсәткән.

## Китапның эчке төзелеше турында

Бу китапта Минһаҗетдин Җәбәли кульязмасындагы текстларның чагыштырмача тулырак һәм эчтәлеге ягыннан эзлеклерәк булган, безнең тарафтан II вариант дип билгеләнгән текст өлеше алдан урнаштырылды. Аннан соң кыскачарак I вариант һәм III вариант рәвешендәге өлешләре урын алды. Алда әйтелгәнчә, «вариант» дип атавыбыз төптөгәл мәгънәсенә туры килеп үк бетми һәм алар бөтенесе дә бер-берсен тулаем кабатламый, ә бәлки тулыландыра торган каралама текстларны тәшкил итә.

Китапта башта автор текстларының гамәлдәге татар язуындагы транслитерацияләре, аннары хәзерге татар әдәби теленә күчермәләре урнаштырылды.

Хезмәтнең авторы тарафыннан гарәп телендәге төрле китаплардан күчерелгән күләмле өземтә һәм цитата өлешләре тексттагы үз урыннарында татарчага тәрҗемә ителгән кыскача аннотация итеп, квадрат җәяләр белән аерып язылды. Төп текстка кертелгән һәм кертелмәгән барлык өземтәләр турында кульязманың тасвирламасы мәкаләсендә тулы мәгълүмат бирелде һәм кайберләре шунда күчерелде.

Текстның теле мәсьәләсендә, алда әйтелгәннәргә өстәп, берничә урында берәр абзац күләмендәге, катлаулы телдә язылган озын җөмләләре барлыгын искәртәбез. Авторның җөмлә төзелешләре һәм стиле үз чорына хас рәвештә. Текстның хәзерге телгә күчерелгән өлешендә дә алар үзгәртелмәде. Шулай ук ул «вә», «ки» һәм «әмма» теркәгечләрен бик еш кулланган. «Әмма» теркәгече бу автор

текстында төп мәгънәсеннән тыш, «шуннан, тагын, янә» кебек мәгънәләрдә дә файдаланылган.

Транслитерацияле текстта хәрефләрне кульязмадагыга якын рәвештә бирергә тырыштык. Ягъни, гарәп язулы татарча текстларда «уау» һәм «йа» хәрефләре белән бирелгән *-ы, -е* авазлары кульязмада ничек булса, монда да шулай язылды. Мәсәлән, *өчүн, күрүб, булуб, барыб* һ.б. Төп чыганакта бер үк сүзнең төрлечә язылышлары үзендәгечә сакланды. Мәсәлән, магул–мәгул–мугул, Чыңыз–Чингиз, Кафказ–Капкас–Кабкас, Мәскәү–Москва–Мәскау, Питербурх–Питырбург, Абстралия–Австралия һ.б. Автор кулланган аерым атамаларның синонимнарын җәяләр эчендә бирдек, мәсәлән, «татар (хакан)» һ.б.

Автор кульязмасында бернинди дә пунктуация билгеләре юк. Бу басмадагы бөтен тыныш билгеләре безнең тарафтан куелды.

Әсәр текстының транслитерация өлешләрендә кульязманың битләре башланган урыннарны ике кыек сызык белән аерып (*// 10а кәгазь* рәвешендә) күрсәттек. Аларның нумерациясе рәттән бармавының сәбәбен – җыентыкның кәгазьләре буталганга бәйле булуын – алда әйтеп үткән идек.

Кульязмада төшеп калган хәрефләрне, иҗекләрне, кайбер очракларда төшеп калган дип фаразланган аерым сүзләрне квадрат җәяләр эчендә өстәп яздык.

Китапның ахырында Җәбәли кульязмасының тасвирламасы һәм сүзлек бирелде. Сүзлектә кереш мәкаләдәге өземтәләрдә очраган һәм тасвирлама мәкаләсендәге гарәп һәм фарсы алынмалары, борынгы төрки, архаик һәм гади сөйләмдә кулланылган сүзләр тупланды.

***

Бу китапны басмага әзерләү дәвамында күрсәткән ярдәмнәре өчен Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең директор урынбасары Ирек Һадиевка, китапханәнең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге

мөдире Айрат Заһидуллинга, КФУның Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе директоры урынбасары Эльмира Әмирхановага, сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге мөдире Энҗе Сабировага, шул ук бүлекнең хезмәткәрләре Рәисә Шәрәфиевага, Алсу Зиннәтуллинага һәм Айрат Сәмигуллинга, тарихчы Рәмзия Абзалинага, тарих фәннәре кандидаты Ильяс Мөстәкыймовка рәхмәтләремне юллыйм.

# ТӘВАРИХЫ БОЛГАРИЙӘ ВӘ ТАТАРИЙӘ

## (текст транслитерациясе)

## [II вариант]

// (*38б кәгазь*)

Әгузү билләһи минәш-шәйтанир-ражим.

Бисмилләһир-Рахмәнир-Рахим.

Әлхәмде Лилләһи Раббил-галәмин вәл-гакыйбәтү лилмөттәкыйн вәс-саләтү вәс-сәлямү галә сәйидина Мөхәммәдин вә алиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн вә галә җәмигыль-әнбийа вәлмөрсәлин вә галә мәляикәтикә әл-мокаррибин вә галә әһли тагатикә әҗмәгыйн мин әһлис-сәмавати вәл-ардыйн.

Әмма бәгъдә, дине исламийәдә шәригате гарраи Мөхәммәдийәдә[1] милләте сөннийи мостафавийәдә фиркаи наҗийәи сөннийә улан әһлес-сөннәт вәл-җәмагать фиркасендә Әбелмансур әл-Матуриди мәзһәбенчә игътикад идәрәк, вә заһир гамәлдә имам әгъзам Әбү Хәнифә Куфи[2] рәхмәтуллаһи Тәгалә галәйһи мәзһәбендә вә кауленчә гамәл идүб, вә шәкердләре – имам Мөхәммәд вә имам Әбү Йосыф вә Хәсән бине Зийад вә Зөфәр[3] кауленчә иҗтиһад идәрәк, фәтваэз-заман берлә гамәл идәрәк, силсиләи суфийәи галийә мөрәххәсиһи вә мәэмүриһи минәр-рәсүли саллаллаһу Тәгалә галәйһи вә

---

[1] *Мөхәммәд* – мөселман пәйгамбәре, ислам динен нигезләгән, дини, иҗтимагый һәм сәяси юлбашчы, Гарәбстанда беренче ислам дәүләтен оештырган Мөхәммәт ибне Габдулла ибне Габделмоталлиб ибне Һашим (570–632).

[2] *Әбү Хәнифә Куфи* – ислам диненең мәшһүр галиме, мөхәддис, хәнәфи мәзһәбен нигезләүче Әбү Хәнифә ән-Ногман бине Сабит (699–767).

[3] Әбү Хәнифәнең монда әйтелгән дүрт шәкерте – иң бөек һәм мәшһүрләреннән. *Имам Мөхәммәд* – Мөхәммәт ибне Хәсән ибне Фиркад әш-Шәйбани (752–835); *Имам Әбү Йосыф* – исламдагы беренче казый, фәкыйһ Әбү Йосыф Ягъкуб ибне Ибраһим әл-Куфи (731–804). *Имам Хәсән бине Зийад* – мәшһүр фәкыйһ; *Имам Зөфәр* – мәшһүр ислам галиме Зөфәр ибне әл-Һөзәйл ибне Кайс ибне Сәлим әл-Ганбәри әт-Тәмими (728–775).

алиһи вәссәлләм иля Әбүбәкер әс-сиддыйк[4] (разый Аллаһу Тәгалә ганһе)дән рөхсәтән вә мөҗазән вә ишарәтән, хатты иршад берлә шәҗәрәи суфийә идүб зоһур идән силсиләи Габделхаликъ әл-Гыйждуванидә[5] улан тарикаи Нәкышбәндийә хөҗагян[6] хәзрәтләренең тарикаи хөфйә галияи мәрзыйәи мәшһүрәдә тәхлийә вә тәхлийә нийәте берлә каблән Аллаһ диб, мән – Минһаҗетдин Сәйфулла угылы Бәчектә имам (асле ватан тәркә җөмләсендән улан Мамадыш илендән бабайлар унике кемсәнә имам булуб үткәннәрдүр), бер рисалә тәэлиф идүб, кәндү нәселләремез вә һәмширләремезне бәйан вә гайан итмәк[7] нийәте берлә, бу китаб «Мөнтәхәб фи әхвали әкрядел-мөхтәлифә вә әтракел-мөхтәлифә фи арзыйль-Болгар вәт-татар» дәйү исем вирүб, тәварихы кадимәдән иске мазарларда улан ташлар хикәйәте буйынча вә кадими әлфаз вә лөгать буйынча вә татарларның мөхаварәт истигъмаль итдүк кәлимат вә әлфазларындин әхәз вә фәһем идүб, вә көтебе тәварихтан вә лөгать китабларындин вә бәгъзе тәрҗемәи төрекдән әхәз вә фәһем вә тәфәккер идүб, җәмыг вә тасниф итдүм. Гарәби «Нисабел-интисар» рисаләсе вә тәрҗемәи камус улан «Укйанус»[8]

---

[4] *Әбүбәкер әс-сиддыйк* – Мөхәммәт пәйгамбәрнең якын кешесе һәм вафат булганда үзе урынына калдырган беренче хәлиф Әбүбәкер Габдулла ибне Госман (якынча 572–634). *Сиддыйк* – «тугры» мәгънәсендәге, хөрмәтләү һәм олылау сүзе.

[5] *Габделхаликъ Гыйҗдувани* – Урта Азиядә мөстәкыйль суфичылык мәктәбен нигезләгән Габделхаликъ бине Габделҗәмил әл-Гыйждувани (1180 яки 1220 елда вафат булган). Аның тәгълиматын Нәкышбәнди суфичылык тармагы тулаем кабул итеп, камилләштергән.

[6] *Тарикаи Нәкышбәндийә хөҗагян* – XIV гасырда оешкан суфичылык тарикате. Габделхаликъ Гыйждувани тәгълиматын һәм Әхмәд Ясәви суфичылык мәктәбен тулыландыру нигезендә барлыкка килгән. Оештыручысы хуҗа Баһаведдин Мөхәммәд Нәкышбәнд (1318–1389) исеменә нисбәт ителеп, «Нәкышбәндия» дип аталган.

[7] Кулъязмада бу сүз «итекмәк» дип, хаталы язылган.

[8] *«Укйанус»* – госманлы галиме Мөтәрҗим Гасыйм әфәнде тарафыннан 1814 елда тәмамланып, госманлы солтаны Икенче Мәхмүдкә тәкъдим ителгән гарәпчә-төрекчә «Әл-Укъянусел-бәсыйт фи тәрҗәмәтил-Камусил-мохит» сүзлеге. Бу китап – гарәп теленең филолог галим Фирузабади (1415 елда вафат)

китабы, тәрҗемәи «Борһане катыйг» улан «Тибйан нафигъ»[9] вә «Мәгърифәтнамә»[10] китабларыдыр, вә Табаррийә тарих[ы] улан «Тәварихы Табаррийә»дүр[11].

Әмма үземез Түнтәр Галимөхәммәд[12] бине Сәйфулла мәдрәсәсендә тәгълим алуб, сарыф вә нәхү вә мантыйк вә фәлясуф вә хикмәтел-гайн вә кәлям вә ысул, «Тәүзыйх» китабы вә башка [дин] вә мәган бераз истимагъ идүб, «Тәлхыйс» вә «Мотаувәл»[13]дәресләре дә вә бөйлә хазир вә истимагъ идәрәк, мәсаиле фәннидән «Һидайә», «Шәрхе викайә» вә «Мөхтәсар»[14]

---

төзегән аңлатмалы сүзлегенең тәрҗемәсе. XIX гасырда өч һәм дүрт томлыклар рәвешендә Истанбулда, Каһирәдә берничә мәртәбә басылган.

[9] *«Тибйан нафигъ»* – XIII гасырда яшәгән Мөхәммәд әт-Тибризи әсәре. Тулы исеме «Тибъян нафигъ тәрҗемәти Борһане катыйг. Әл-хәййа әл-гаммә лидирасәтел-көтебе каумийә».

[10] Госманлы төрек галиме, энциклопедист, суфи шагыйрь Ибраһим Хаккыйның (1703–1780) «Мәгърифәтнамә» әсәре гакыйдә мәсьәләләренә, шул исәптән суфичылык (Нәкышбәндия тарикате) тарихына багышланган. Бу әсәр үзенчәлекле энциклопедия сыйфатында: анда суфичылык белән бергә, төрле фәннәр (астрономия, математика, анатомия, психология, философия) буенча да мәгълүматлар тупланган. И.Хаккый ислам дине белән төрле фәннәрне үзара килештерүгә зур әһәмият биргән. Автор үзе белдергәнчә, бу әсәрен язар өчен ул 400 чыганакны кулланган. Бу китапта беренче мәртәбә Кояш системасының фәнни тасвиры язылган. Хаккыйның шулай ук медицина, анатомия, физиология, арифметика, философия, әхлакка багышланган, төрек, фарсы һәм гарәп телләрендәге 15 китабы һәм трактатлары бар.

[11] Фарсы тарихчысы һәм дин галиме Әбү Җәгъфәр Мөхәммәд ибне Җәрир ибне Йәзид әт-Табарриның (839–923) «Тарихер-рөсул вәл-мөлек» – пәйгамбәрләр һәм патшалар тарихы. Аны «Тарихе Табарри» (Табарри тарихы) дип йөрткәннәр. Бу хезмәттә Коръән иңгәннән алып, 915 елга кадәрге мөселманнар тарихы тәфсилле тасвирланган (625–915 еллар арасындагы елъязма рәвешендә) һәм әлеге китап тарихчылар өчен беренчел чыганаклардан исәпләнә.

[12] *Галимөхәммәд* – автор үз остазының исемен шушы рәвештә язган. Башка чыганакларда: Мөхәммәтгали.

[13] *«Мотаувәл»* – күркәм сөйләм (бәлягат) буенча дәреслек итеп кулланылган китап.

[14] *«Һидайә»* – Борһанеддин әл-Мәргыйнәнинең (1197 елда вафат булган) фикъһ буенча гарәп телендәге хезмәте; *«Шәрхе викайә»* – Гобәйдулла бине Мәсгуд Таҗешшәрига (1346 елда вафат булган) тарафыннан язылган фикъһ

вә хәдистән «Мишкяте мәсабих»[15] дәресене истимагъ идүб, фәне тәсаувыфтан «Тарикаи Мөхәммәдийә» вә «Хадими» вә «Морадел-гарифин» вә «Мәсләкел-мөттәкыйн»[16] китабларыдан дәрес алуб, лилләһил-хәмд, мәзкүр хәзрәти ишанның кәндү хәйатында рөхсәте берлә Тау тарафына – Бәчек (асылда Бичек) авылына имам улуб, тәзкирәи хәйрийә вә садакаи җарийә[17] булса иде дәйү тәэлиф итдем.

Мәзкүр хәзрәти ишан утыз сәнә микъдар тәхсыйле гыйльмез-заһир вә батыйн[18] иткән Һиндустан мәмләкәтендә вә Бохараи шәрифдә. Казан мәмләкәтләренә рожуг идүб, кырыкилле йыл микъдар дәрес әйткән гыйльмез-заһирдан вә гыйльмел-батыйндан. Кәнд үзе мөҗаз кемсәнәдүр, хатты иршад берлә гыйльмез-заһир вә һәм әл-батыйн өчен. Туксан йәшәб, рәҗәб унбишендә, җомга көн вафат һәм мәдфүндер ки [Түнтә]р карйәсендә. Рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васыйгатән.

Мондан соң мәнакыйбе хәзрәти ишан йазылур[19].

---

китабы; *«Мөхтәсар»* – Гобәйдулла бине Мәсгуд бине Таҗешшәриганың «Мөхтәсарел-викайәт фи мәсаилел-һидайә» исемле, фикъһ буенча гарәп телендәге әсәре.

[15] *«Мишкяте мәсабих»* – XIV гасыр галиме Вәлиэтдин Мөхәммәт ибне Габдулла әл-Хатыйб әл-Гомәри әт-Тәбризинең «Мишкятел-мәсабих» исемле, хәдисләргә аңлатмалар җыентыгы.

[16] *«Тарикаи Мөхәммәдийә»* – Мөхәммәт Биркәви әсәре, татар мәдрәсәләрендә ислам әхлагы буенча дәреслек итеп кулланылган. *«Морадел-гарифин», «Мәсләкел-мөттәкыйн»* – төрки шагыйре Аллаһыяр Суфиның (Әбү Мөхәммәт Аллаһыяр бине Аллаһколый, 1616–1713) фарсы телендәге әсәрләре.

[17] *садакаи җарийә* – дәвамлы файдасы булырдай игелек; бу очракта автор Мөхәммәт пәйгамбәрнең «Әгәр бер кеше вафат булса, өч нәрсәдән кала, аның гамәле киселер: дәвамлы сәдака, файдалана торган гыйлем һәм дога кылучы изге бала» дигән хәдисен күздә тоткан.

[18] *гыйльмез-заһир вә батыйн* – суфичылыкта: Коръәннең һәм хәдисләрнең тышкы (ачык) һәм эчке (яшерен) мәгънәләре.

[19] Кулъязмада шушы искәрмә генә теркәлгән, шигъри тексты юк.

***

// (*12а кәгазь*) Йукарыда мәзкүр вә мәстур мәктүбате гарәбийә ифадә идәр ки, «Хәзәр» вә «Биляде җәбәлел-фәтех» арзы бер васыйг арыз улуб, эчендә өмаме мөтәкәссирәләр этраке мөхтәлифәдән улуб, шәһәр-билядләренең сәрхәде йәэҗүҗ вә мәэҗүҗ сәдденә[20] кадәрледер.

«Хәзәр» вә «Җәбәлел-фәтех»нең мәшһүр биляд вә шәһәрләре Сәмәндәр шәһәредүр ки, бер олуг тәхетле кальга булгандыр, үзенә гарәбчә «Сәрир»[21] дийәрләр. Йегерем сәнә микъдары көмүшдән вә алтундан тукып йапылмышлардур. Әмма ул Сәмәндәр шәһәрене урыс таифәсе хәраб-у-һәлак вә набуд-у-начиз итмешдүр. Мәзкүр Сәрир һаман бардур.

Вә дәхи «Җәбәлел-фәтех»нең мәшһүр шәһәре вә биляде Болгар шәһәре вә кальгаседүр.

Нух галәйһиссәламнең вәләде улан Самдан мөншәгыйб улан гаҗәм таифәсе «гъад» кауме улуб, анлар – көрдләрдүр вә башкордлардур вә башка этраке мөхтәлифәләрдүр ки, хәзәр вә хәзәз халкы, чуаш вә чирмеш вә мукшы вә ар (бутяк) вә башка тәваиф – болгардур.

Болгар мәмләкәте вә арзы – шималь вә гарби Русийә берлә күрше мәмләкәт һәмсәнварлардур ки, көндүзе өч сәгать йарым

---

[20] *йәэҗүҗ вә мәэҗүҗ сәдде* – дини риваятьләрдә тасвирланган имансыз кыргыйлар. Искәндәр Зөлкарнәйн зур дивар (сәдд) төзетеп, аларны башка халыклардан аерып куйган. Коръәндә «Әл-Кәһф» сүрәсенең 82–102 нче аятьләрендә бу вакыйга тасвирланган. Дини риваятьләрдә диварларның икәү булганлыгы һәм аларның берсе – Кавказ яки Урал таулары, Бөек Кытай стенасы белән дә тиңләштерелгән. (Чынлыкта, Кытай стенасы Александр Македонскийдан соңгы чорда төзелгән). Рабгузи китабында (1859) Искәндәр дивары турында 430–432 битләрдә язылган. Урта гасырлардагы географлар күзаллавынча, яэҗүҗ-мәэҗүҗләр хәзәр җирләреннән көнчыгыш тарафта булганнар.

[21] *Сәмәндәр* – Хәзәр каһанлыгы чоры шәһәре һәм бераз вакыт башкаласы булып торган. Каспий (Хәзәр) диңгезенең көнбатыш ярында. Хәзерге Дагстанның шәһәр тибындагы посёлогы. *Сәрир* – Дагстан территориясендә VI–XVI гасырларда булган дәүләт исеме. М.Җәбәли VII гасырдагы Иран патшасының Сәриргә җибәрелгән алтын тәхете турындагы риваятьне күздә тоткан.

йирдә рус берлә мөлякый улуб, Болгар арзы дийәләр, Капкас тарафларындан кар җауган йирләргә кадәр. Дәхи Болгар (вә Хәзәр вә Хәзәзийан) арзы йегерем ике мең фәрсәхдүр[22].

Болгарның кальгасе йөз чакрым йиргә җәйелүб җаткандур, хисары – кирпич, тукыз чакырым булгандыр. Хәзерендә Болгар шәһәре урыны диб мәзкүр сур вә хисарны зийарәт кыйлсалар, Искәндәр Руми бу Болгар кальгасене хәкиманә бәрвәҗһи хисар пәйда идүб, хәляикыны мөэмине халис кыйлуб китдүге китабның йукарысында бәйан кыйлган идүк. Искәндәр тәгъмире заман Болгарны ике мең йыл вә сәнәдән артыгракдур, вә Болгар нам куйуб китмешдүр. Йукса, замане кадим «Җабәлкаһ» дийәрләр иде. ...[23]

«Алты бармак» китабында[24] мәзкүр хикәйәи мигъраждан мәфһүмдүр ки, пәйгамбәремез Мөхәммәд мостафа саллаллаһу Тәгалә галәйһим вә алиһи вәссәлләм хәзрәтләренең замане сәгадәтләрендә булган Болгар шәһәрегә Булга (вә Бүлге, вә Кара Идел) йанында Болгар вилайәтләренә мәнсүб улан хәляикъ әкраде мөхтәлифә вә әтраке мөхтәлифә улдыклары вә замане сәгадәтдә дине ислам берлә мөшәррәф булдыкларун тәварихе фәннидән улан «Нисабел-интисар» вә башка китаблардан нәкыль вә ривайәт кыйларак вә төрки вә көрди ләфызларындин әхәз вә бәйан идәвәз ки, анлар – Болгар халкы – барча нәүгысе берлә төрк вә көрд халыклары вә нәселләредүр ки.

---

[22] *фәрсәх* – ераклык үлчәве, җайдак тарафыннан 1 сәгатьтә үтелгән юл озынлыгына (якынча 6–7 километрга) тиң, ә кайбер очракларда 10 чакрым чамасы дип исәпләнә.

[23] Кулъязманың бу урынында «Гъад кауме Салих пәйгамбәр өммәтләредүр» дип башланып, йәэҗүҗ вә мәэҗүҗләр телгә алынып, «мәшрикъ вә мәгърибдә улан «Җабәлкаһ» вә «Җабәлсаһ» шәһәрләренең халкы» дигәннән соңгы дәвамы кәгазь читенә язылган һәм таушалып, танылмаслык дәрәҗәгә килгән. Андагы 1–2 җөмлә укылмый.

[24] «*Алты бармак» китабы* – дини-әхлакый әсәр, авторы госманлы галиме Мөхәммәд ибне Мөхәммәт Чокрыкчызадә (1623 елда вафат). Бу әсәр Мөхәммәд пәйгамбәргә багышланган, анда шулай ук тарихи, тәрбияви һ.б. мәгълүматлар да тупланган. Башта кулъязма күчермәләрдә күп таралган. Казанда беренче мәртәбә 1861 елда басылган.

Әкраде мөхтәлифәләрнең башлычасы башкорд халкыдур, ләфзан вә мәгънән «баш көрд»дүр. Анлар кадим заманда «гъад» исемендә булуб, Салих пәйгамбәр дәгъвәте берлә мөэмин булмышлардур ки, Көрдстан халкыдур.

// *(12б кәгазь)* Башкорд (вә башкөрд) халкы бик мөтәнәүвигъ улсалар да, башлычасы «си» башкортыдур ки, ...[25] кәлимәләренең «җиме фарсый» берлә «ча»[26] әда иделәчак хәреф «син» вә «си гарәби» әйдәрәк әда идәрләр. Мәсәлән, «сәй исдүм» вә «сәй исдүм»[27] дийәрләр ки, Казан татарларынча «чәй ичдүм» димәк улур. Вә Бозаулык буй башкортлары ки «ч» хәрефе йөртмеш.

Вә дәхи «кый» башкорт димәк мөмкин улур ки, тәмам булган кәлимәләренең ахырында «кый» ләфзын идхаль илә тәмаме кәлимә вә кәлям идәрәк, вакъфән вә тәкәллем идәрләр. Мәсәлән «чәй ичдүм кый» вә «китаб укудум кый» дийәрләр. Пирме мәхкүматында әксәрийән бу лөгатьдүр.

Вә дәхи «һи» башкорды димәк мөмкиндүр ки, «син гарәби» берлә әда иделәчак мәүзыйг «һи» хәрефе берлә әда идәрләр. Мәсәлән, «һин кем булаһың?» дийәрләр. Уфа вилайәтләрендә улан башкордлардур, монларның «син» хәрефе йукдур. «Әлгыйльмү гыйндә Аллаһи Тәгалә дәгъ ма йәрлибүкә иля ма ля йәрлибүкә»[28].

Әтраке мөхтәлифәләрнең башлычасы чуаш халкыдур ки, суас (вә сүәс вә сүс) каумедүр ки, төрк нәүгысендән Уз тарафларындагы кальгаи Сивас халкы кебидүр. Лисан вә кафтан вә калпак вә тәкыйа вә сугуб йасадыкы шәйләр исбат идәр ки, кә-әннәһә, анлар төрекләрдүр. Мәсәлән, йыл башы ай – март

---

[25] Кулъязманың бу урынында кәгазьнең иң өстәге читендә язылган берничә сүз танылмый. Бары тик «димәк, ...смендүр ки...» рәвешлеләрен генә чамаларга мөмкин.

[26] Кулъязмада ялгыш «ха» дип язылган.

[27] Бу гыйбарәләрнең беренчесендә сүзләр гарәп әлифбасының өстендә өч ноктасы «с» хәрефе белән, икенчесендә «син» хәрефе белән язылган.

[28] *Әл-гыйльмү гыйндә Аллаһи Тәгалә дәгъ ма йәрлибүкә иля ма ля йәрлибүкә* – пәйгамбәр хәдисе: «Үзеңне шиккә төшерә торган нәрсәдән аерылып, икеләнү тудырмый торганга мөрәҗәгать ит!»

дийәрен чуашлар «нәүрүз» дийәрләр, төрекләр һәм «нәүрүз» дийәрләр. Җомга көн «эрне кун» дийәрләр, төрки «әзинә көн»дүр. «Пәйгамбәр куляне» – «пәйгамбәр колынды(?)», «күсрә перлә кәйе» – «кырык берлә кит», «җумартачы» – «йомартайы», «ман хурланмизыр» – «мән хурланмийур», «каймизыр» – «гәлмийүр», «бармазыр» – «бармайур», «бахыт пулад» – бәхет булур», «теләй пулад» – «теләй булур», вә «талига» (вә талиха) пулад» – «талига булур», «асыл пулад» – «асыл булур», «бәрәкә пулад» – «бәрәкәт булур», «савап пулад» – «савап булур». «Тур» дийәрләр – «тары» димәк улур ки, Ходай исемедүр. «Ине» дийәрләр – төрки «инәҗәк»дүр. «Пыракъ йулдаш» – «парах йулдаш», «лайах пулад» – «ляих булур», «чух» – «йух». Вә чух лисанлары ныйсьфендән зийадәсе гарәби вә төркидүр. Әмма Русийәгә мөҗавәрәт идүб, бу заман бәгъзе әлфазлары русидур. «Фа» хәрефе җукдыр, «ха» хәрефе илә әда идәрләр. Мәсәлән «франсус» дигән сүзне «хрансус» дийәрләр. Уйын исемләре: «зурнай»дур – төрки «зорнай»дур.

Ушандак чирмеш халкыдур җөббә вә тухийә кийәрләр. «Җөббә» дидеге сүз «сөббә»дүр, гарәбидүр, сәүбдүр. «Тухийә» – «тукыйа», йәгъни тукып йапылмышдур. Вә һакәза чирмеш халкы ләфызларында төрки вә гарәби ләфызлары чукдур. Чирмеш чуашны «кирык мари» дидегендин анлар бер җенес икәнчелегене исбат би-лисани нәфсиһи вә нәүгыйһидүр. Йәгъни, «тау чирмеше» димәк улур. Әмма чирмеш татарларны «суас» дийәрләр, ар(бутяк)лар татарны «бигер» дийәрләр.

Вә һакәза мукшы халкы вә мурдва халкы монлар җөмләсе әтраке мөхтәлифәләрдүр. Әмма монлар җөмләсе кадим заманда «гъад» каумендән мәгъдүд улуб, Азәрбәйҗанә күрше мәмләкәт улуб, вә бер заман Әфридун[29] хөкүмәтендә калуб, атәшпәрәст вә башка мәҗүси гамәлләрендә күренәләр. Йукса, Болгар барча тәвабигате берлә йегерем ике мең фәрсәх йир кадәр әтраке мөхтәлифә вә әкраде мөхтәлифә улуб, ислам динедә улдыкдары бәйан вә гайан кыйлынадур ки.

---

[29] *Әфридун (Фәридун)* – 1066 елда Дәрбәнт хакиме итеп билгеләнгән шәхес.

// *(13а кәгазь)* Бу заман дәүләте Госманийә синҗагында булган Македонийә арзында Ийанҗә[30] кальгасендә Искәндәр тәвәллед идүб, Искәндәр хәким Зөфөнүн румилар вә сакъләбиләргә ләһ[31], пуләк вә чеһ, нимеч, венгрус (йәгъни, бингер) вә әфлякъ вә Бугдан халкы берлә килүб, Болгар кальгасене хәкиманә тәгъмир вә бина идүб, каумене Ибраһим динедә кыйлуб, үзе сәдд тарафына китмешдүр.

Болгар арзына «Арзыль-Хәзәр» вә «Дәшти кыпчак» вә «Хәзәр» дийәрез ки. «Нисабел-интисар» китабында [*гарәп телендәге өземтәнең мәгънәсе: «Хәзәр иленең һәм Җәбәлел-фәтехнең җире киң, анда хисапсыз төрле төрки халыклар яши һәм патшалыклары да төркинеке, Искәндәр төзегән диварга чиктәш»*].

Вә Болгарны Искәндәр тәгъмир итдүге «Тәварихе дәваир» китабында һәм мәзкүрдүр.

Әмма Болгар шәһәре вә нахийәи төрк вә хәзәр (вә хәзәрдүр[32]) ки, Искәндәр бинасындан каблә бар булмакы «Алты бармак» китабындан мәгълүм улур ки: «Ривайәт улынур ки: хәзрәти Рәсүлуллаһи Тәгалә галә вә алиһи вәссәлләм бойурды ки, Җәбраил галәйһиссәлам бәне йәэҗүҗ вә мәэҗүҗә илтде. Анлары иманә вә Аллаһы Тәгаләйә гыйбадәтә дәгъвәт итдем – кабул итмәделәр вә исламә килмәделәр – җөмләсе җәһәннәм әһеледүр. Андан бәне ике шәһәрә илтделәр – бере мәшрикъда вә бере мәгърибдә, һәрберенең ике бең дәрвазәсе вар иде. Бер дәрвазәдән ул дәрвазәйә бер фәрсәх ирде. Ул мәшрикъда улан

[30] *Ийанҗә* – Искәндәр Зөлкарнәйн (Александр Македонский) – рәсми мәгълүмат буенча Пелла шәһәрендә безнең эрага кадәр туган шәхес. Антик чордагы Пелла каласы булган урын янында «Яница» исемле күл мәгълүм, Ийанҗә дигән атама шуны белдерә торгандыр.

[31] *сакъләби* – сәкъләб (сәкалибә) этнонимы, соңгы дәвер галимнәре билгеләвенчә, Көнчыгыш Европаның урманлы җирләрендә яшәгән бөтен халыкларга карата кулланылган, аны аерым бер халыкка гына нисбәт итү дөрес түгел һәм тарихи текстларда тәрҗемәсез генә язу кулай. *Ләһ (лях)* – чехларның берничә этнографик төркеменең гомуми атамасы.

[32] «хәзәр» сүзенең беренчесе гарәп әлифбасындагы «зә» хәрефе белән, икенчесе «зәл» белән язылган.

шәһәрнең халкы «гъад» кавеменең мөэминләрендин, йәгъни нәселләрендин иде, Салих галәйһиссәламә иман китүрмешләр иде, сөрйани дилендә «Бәркайна» дийәрләр иде, вә гыйбрани дилендә «Җабәлкаһ»[33] дийәрләр ирде. Динә дәгъвәт итдем вә гыйбадәт тәгълим итдем – кабул итделәр».

Иншаллаһу Тәгалә, мәшрикъда улан мөэмин шәһәр вә «гъад» кауме – Болгар кальгаседүр ки, «Арзыль-Болгар» – сәдднең күрше мәмләкәтедүр вә мокаддимәседүр. Дәхи дә сәдд тарафына чыкуб киткүчеләр вә баргучылар Болгар аркылы йөргәнләрдүр. Нитәккем Искәндәр Руми.

Әмма «Тибйан нафигъ» тәрҗемәсендә мәзкүрдүр ки: «Җабәлкаһ галәме мисал илә галәме җисмани илә рухани арасында бер зәми галәме нуранидур» дигән.

Без дийәрез ки, рәсүлуллаһ бу галәме шәһадәтдә тәблигы рисаләт идәрәк, хосусан, даре тәклиф – бу дөнйадур, гъад кауме – бу дөнйададур, вә һәм йәэҗүҗ вә мәэҗүҗ шәһәре – бу дөнйададур, мәшрикъ тарафы – бу дөнйададур, галәме нурани да нә шәркый вә нә гарби, җиһан – мөтәсавийәтеликъдамдур. Йәки Җабәлкаһ вә мөтәгаддид улсун, безнең дә күңелемезгә килүр ки, гүйә, Җабәлкаһ шәһәре – Болгар шәрифдүр.

---

[33] *Җабәлкаһ* – борынгы китапларда (мәсәлән, Х гасыр тарихчысы Табарри хезмәтендә, XIII гасыр галиме Зәкәрия әл-Казвининең «Гаҗаибел-мәхлукат» китабында) Җабәлкаһ (Җабәлка) һәм Җабәлсаһ (Җабәлса) исемнәрендәге калалар турындагы риваятьләр теркәлгән. Мәсәлән, Рабгузиның «Кыйсаселәнбийа» китабында (Казан, 1859, 525 бит) Мөхәммәт пәйгамбәрнең Җабәлка шәһәренә бәйле вакыйгалары тасвирланган. Әлеге легендар шәһәрләр, имеш, зөбәрҗәттән төзелгән һәм алар Каф тавы артында урнашкан дигән хәбәрләр дә бар. Ул калалар гъад кавемнәренеке дигән сүзләр очрый. Төзелешләре буенча һәр тарафы унике мең фәрсәх озынлыгындагы, камиллекне символлаштырган квадрат шәкелендә, аларның 12 мең капкалары булып, кыямәт көненә хәтле 12 мең кеше саклый. Кайбер чыганакларда ул шәһәрләр җисмани түгел, ә образлар дөньясында («галәмел-мисал»), башкаларында, имеш, ике дөнья арасында урнашканнар дип аңлатылган. Суфичылыкта бу шәһәрләр чынбарлыктагы дип тасвирланган. Гомумән, әлеге ике серле кала суфичылыкта киң яктыртылган. Аларны Әфганстандагы Бәлх һәм Һерат шәһәрләре белән тәңгәлләштерү омтылышлары да булган.

***

Вә фи «Нисабел-интисар»: [*гарәп телендәге өземтәнең тәрҗемәсе: «Сәедбаттал Газый «Төхфәтел-ләбаб» китабында болай дигән – Болгарда гъад кавеменең кешесен күрдем, ул 27 зирагтан (терсәктән) озынрак. Шул кеше атны, кечкенә сабыйны алган кебек кенә, култыгы астына кыстыра. Болгарның Башкорт дигән җирендә хәзер дә гъад халкы калдыклары бар. Болгар җирендә мөселман төркиләр яши, алар габбаси хәлифәләреннән әл-Мәэмүн һәм әл-Васикъ*[34] *Билләһи заманында ислам динен кабул иткәннәр һәм әл-Каим Би-әмриллаһ*[35] *вакытында яңартканнар 30 мең сыркәү төрки кабиләләр. Сыркәү – төрки телендә ир-ат җәмәгатеннән кардәше, агасы, балалары – барлыгы 100-дән 1000-гә хәтле. Солтан Сәбектәгин вакытында ислам динен кабул иткәннәренең хисабы юк (бик күп). Төркиләрдән ислам динен кабул итмәгән имансыз-кяферләрен үтергән»*].

***

Гъад бине Гауз бине Сам бине Нух галәйһиссәлам дә каддкамәтләре йөз йегерме аршун («Алты бармак»).

Татарча гъад[не] «арагыт», «гуҗ» вә «гыҗ» диб әйтәләр, «алыплар» диб һәм әйтәләр.

// (*13б кәгазь*) Болгар вә Казан хәляикы барча әтраке мөхтәлифәләре вә әкраде мөхтәлифәләре берлә Салих галәйһиссәлам кулындин вә телендин мөэмин булганлар-

---

[34] *әл-Мәэмүн* – 813–833 елларда габбасилар хәлифәсе булган Әбелгаббас Габдулла ибне Һарун әл-Мәэмүн (786–833). *Әл-Васикъ Билләһи* – 842–847 елларда идарә иткән габбаси хәлифәсе. Шушындый ук мәгълүматны Ш.Мәрҗани «Рисаләтел-интисаб» китабыннан күчергән: «Болгар җире – мөселман төрекләре иле. Алар Габбасилар хөкем сөргән заманда Мәэмүн һәм Васикъ биллаһ хәлифәлеге вакытында мөселман булдылар; икенче мәртәбә әл-Каим Би-әмриллаһ хәлифәлегендә утыз мең йорт мөселман булды» (*Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар..., 1989. – Б. 54, 134*).

[35] *Әл-Каим Би-әмриллаһ* – фатимыйлар хәлифәлегенең икенче хәлифәсе Әбелкасыйм Мөхәммәд ибне әл-Мәһди әл-Каим Би-әмриллаһ (893–946).

дур. Бу заманга өч мең сәнә кичмешдүр ки, шимдики заман – һиҗрәт сәнәи 1295[36].

Вә дәхи Болгар халкы Искәндәр Руми заманында мөэмин булганлардур. Болгарны Искәндәр телендин иманә килдүк заманына ике мең дә ике йөз унбиш сәнәдүр. Шимдики һиҗрәт тарихы 1295 сәнәдүр.

Вә дәхи Болгар халкы Җабәлкаһ намендә булуб вә гъад кауме җөмләсендән булуб, мигъраҗдан кайтканда рәсүлуллаһ үзе дәгъвәт идүб, анлар кабул итмешләрдүр ки, мең дә өч йөз дә биш сәнә үтмешдүр[37] ки, шимди замане һиҗрәт 1295 сәнәдүр.

Вә дәхи тукузынчы һиҗрәт[38] берлә өч сахабә килмешләрдүр ки, Мәдинәи мөнәүвәрәдән килгән сахабәләр исеме: Габдеррахман бине Зәбир, вә дәхи Ханзали бине Рәбигъ, вә дәхи Зәбир бине Җөгъдә. Дәват – Зәбирә, тайак – Ханзалийә, дәстар – Габдеррахманга вирүб, өчәгүсе истимдад берлә кирамәт заһир булуб, мөселман кыйлуб киткәнләрдүр[39].

Дәхи хәзрәти Гомәр (разый Аллаһу Тәгалә) заманында вә хилафәте заманында Габдеррахман сахабә хәзазийанлар берлә бик сугышуб, Дәрбәнддән чыкуб, сәддкәчә улан Бәләнҗәрне[40],

---

[36] Һиҗри 1295 ел милади буенча 1878 елга туры килә.

[37] 1305 һиҗри елны 1295 (1878) елдан киметкәндә 612 нче ел туры килә. Мөхәммәт пәйгамбәрнең мигъраҗ (җисмани һәм рухани күккә ашу) вакыйгасының төгәл елы билгесез, аны якынча 621 елда булган дип язалар.

[38] *тукузынчы һиҗрәт* – һиҗри 9 нчы ел милади буенча 630 елга туры килә.

[39] Бу исемнәр һәм аларга бәйле вакыйга Мөслиминең «Тәварихы Болгарийә»сендә һәм Таҗетдин Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» әсәрендә телгә алынган. Соңгысының төрле күчермәләрендә Ханзали исеме Хантал дип тә язылган. Тугызынчы һиҗри елга нисбәт ителгән әлеге вакыйганы Минһаҗетдин Җәбәли нәкъ менә ул китаплардан алгандыр дип әйтеп булмый. Ихтимал, авторлар әүвәлге, башка бер үк язма чыганактан файдаланганнардыр.

[40] *Дәрбәнд* – Каспий диңгезе буендагы борынгы мәшһүр кала, урта гасырларда «Бабел-әбваб» исеме белән дә аталган. VIII гасыр башыннан гарәп хәлифәлегенең Кавказдагы дини, хәрби һәм сәяси төп үзәге булган. Хәзерге Дагстандагы шәһәр. Бәләнҗәр – урта гасырлар чоры шәһәре. VII–IX гасырларда Хәзәр каһанлыгының эре үзәге, кайбер мәгълүматлар буенча – беренче башкаласы. Хәзерге Дагстан территориясендә.

Русь вә Аланны – ике йөз йул кадәр фәрсәнг йирне мөселман кыйлуб киткәндер. Кинә Мәсләмә исемле гарәб, Габделмалик бине Мәсләмә[41] Сәгыйдь әмере берлә, Турхан субашы[42] иркән – Хәзәрийан вә Хәзәр халкыны сугышуб, мөселман итүб киткәндер.

Турхан мәүзыйгы мөхарәбәсе безнең күрше авыл – чуаш авылының Төрләмәс басуында «Турхан басуы»[43] диб әйтә – шунда булган. Төрләмәс авылы кадим шәһри Зәршәр кырында, Шуршу йанында – Кызылйарда кальга булгандур – Хәзәр шәһәредүр. Чуашча Зәршәр дийәрләр (чуашлар төрек нәүгысе булганга күрә, кәлимәләрендә мәхзүфат чукдыр, мәгани әһеленә хәфи дәгелдүр).

Дәрвакыйгъ, гарәб гаскәренең урыны безнең Бәчек басуында бардур – «Тугыз түбә» дийәрләр. Өч йөз кадәр түбә урыныдыр ки, гаскәриләрнең кийез эүләренең урыныдур – «чадыр» дийәрләр.

Дәхи дә Болгарны бер заман Хытайдан Чыңыз хан чыкуб истиля идүб, күб хәляикъларны хәраб итүб китмешдүр. Тамга андан калмышдур.

Бер заман Әфридун улы Тур хөкүмәтендә калмышдур ки, «түрә» ләфзындан беленә вә һәм нәүрүз вә чимек[44] уты җыймакдан беленә.

---

[41] *Габделмәлик бине Мәсләмә* – дөресе: Мәсләмә бине Габделмәлик (739 елда вафат булган), өммәви хәлифе Габделмәлик ибне Мәрванның (646–705) улы, мәшһүр гаскәри җитәкче, 732 елда Дәрбәндне яулап, анда гарәпләрне урнаштырган.

[42] Кульъязмада «субашы» сүзенең астына З.Максудова тарафыннан гади карандаш белән дулкынсыман итеп сызылган һәм сүз өстенә сорау билгесе куелган, кәгазь читенә «чин исеме?» дип теркәлгән (чин – дәрәҗә).

[43] *Төрләмәс* – хәзерге Чувашстан Республикасының Козловка районындагы Төрләмә авылы. Турхан – тархан, аксөяк. Бу атама чувашларда «князь, би» мәгънәсендә кулланылган. Алар халык тарафыннан юлбашчы, хөкемдар һәм хаким итеп сайлап куелган зирәк акыллы, гадел һәм хөрмәт казанган кешеләр. «Турхан» атамасы белән бәйле урыннар чувашларда күп.

[44] *чимек* – «Семык» бәйрәме. Бу хакта тарихчы Г.Әхмәрев болай язган: «Рус халкының «Троица» бәйрәме вакытында «Симек» җыены була, татарча «Чимек» диләр. Славян халкының шул вакытта «Симек» бәйрәме булган,

Дәхи дә холәфаи Габбасийандан Мәхмүд Сәбектәгин[45].

Вә дәхи Чыңыз хан чыкуб Болгарга, Мәскауга истиля идүб, тамга салмак гадәт кыйлуб киткәндер.

Вә йәнә һиҗрәт тарихы сикезенче йөздә фетнәсе улуб, Аксак Тимер[46] үзбәк шәһәрләрүн хәраб итмешдүр, әл-гадәм итмеш. Шул заман беткән мөселманларның хисабун Аллаһы Тәгалә үзе генә белә. Болгарның ничә мең шәһәрләр вә авылларун һәлак кыйлуб китмешдүр.

Шундан качуб вә посуб калдык мөселманлары Казан шәһәрен бина идүб, йөз ун йыл карар идүб, ул мәкянне йаратмай, Казан суы тамагында Казан каласун салып китмешләрдүр. Йөз йылдан артыграк тормышлар.

// (*14а кәгазь*) Һиҗрәт тукыз йөз алтмыш бердә гакърәб бөрҗендә 2 нче көн[47], йәкшәнбә көн, Казан[ны] Мәскәү урыс алган. Казанда утуз мең мөселманлар гаскәре булгандур. Әмма урыс йөз утуз мең гаскәре берлә килгәндер. Йите йыл орышканлардур.

Фарә-фүрәләр фил-җөмлә уйнамаз улды,
Каһвәханәләрдә каһвәләр кайнамаз улды.
Боҗырга диб тозак салдым,
Боҗырга диб тозак салдым.

---

пасхаларыннан җиде атнадан соң булганга күрә, исемен дә «Симек» (семык) дип атаганнар». Әхмәрев әлеге – мәрхүмнәрне искә алу йоласының төрле халыкларда ничек үткәрелгәнен дә кыскача тасвирлаган (*Гайнетдин Әхмәрев: тарихи-документаль җыентык..., 2000. – Б. 39, 75.*).

[45] *Мәхмүд Сәбектәгин* – газнәвиләр империясен нигезләгән солтан Яминеддәүлә Габделкасыйм Мәхмүд ибне Сәбектәгин (971–1030).

[46] *Аксак Тимер* – Урта Азия һәм Кавказ тарихында яулап алу сугышлары белән танылган Әмир Тимер, Тимерләң (1336–1405). Алтын Урданы тармар иткән, Иранга, Кавказ аръягына, Һиндстанга, Кече Азиягә һ.б. яу чапкан. Татар дастаннарында һәм риваятьләрендә Болгар шәһәрен җимерүче итеп тасвирланса да, анысы чынбарлыкка туры килми. Идел буена 1391 һәм 1395 елларда басып кергән, әмма Болгарны алганлыгы турындагы хәбәрләр чыганаклар белән расланмый.

[47] Һиҗри 961 елның 2 нче гакърәб (чаян ае) миладидан белән 1554 елның 23 октябренә туры килә. Елның дөресе – 1552 елга туры килә торган һиҗри 959 ел булырга тиеш.

Суйыр боты өзелде,
Суйыр боты өзелде.

Болгар вә Казан әтрафында сакин улан әтракел-мөхтәлифәләр вә әкрадел-мөхтәлифәләргә: татарлар вә чуашлар вә чирмешләр вә мукшылар вә мурдвалар вә бутякләр вә мишәрләр вә төмәнләр вә башкордлар вә нугайлар үзә өч мәртәбә бик олуг сугыш булуб, хәляикълары аз калуб вә шәһәрләре мәгъдүм улуб, исемләре бетмешдүр ки, анларның әразыйсыны «арзы мәват икән» диб әйтәләр кадим заманда.

Вәхаләнки, Болгар өч мең йылга кариб замандан бирле бар шәһәрдүр ки, әксәр билядләре үзбәк шәһәре дийәрләр. Дәрвакыйг, Болгар әтрафында кальга вә шәһәр вә хисар урыны бихәдд вә биниһайәдүр ки, җөмләсендән мәшһүр кальгаләре: Бүләр, Кече Болгар вә Сәмәндәр вә Бараҗ шәһәредүр вә Казан шәһәредүр. Безнең Тау йагында Зөйә буйында дүрт[48] кальга бардур: бере – Кири авылы йанында Кошман шәһәредүр, вә бере – Өтәк авылы йанында Казан шәһәредүр, вә бере – Борындык йанында Билыйби каласыдур, вә бере – чуваш авылы катында Зәршәр авылының басуында – Хәзәр шәһәредүр. Мөселман зийарәтләре күбдүр.

Болгар шәһәренең һәлак улмасы – Чыңыз хан берлә сугышуб бик күб беткәндүр вә һәм Аксак Тимер бөтеннәй хәраб итмешдүр. Вә һәм урыс ушандак хәраб итмешдүр. Хәзерендә Болгар халкы бик аз калмышдур. Әмма Болгар әтрафында әнвагъ хәляикълар һәм бардур, хәзерендә татарлар эчендә мәркүздүр.

«Татар» дидегемез сүз татарча «татар»дур, әмма гарәбчә «тәтар» дийәрләр.

«Татар мәмләкәте мәшһүрдер, андан әгъля миск килүр вә ул мәмләкәтдә сакин улан төркләр дәхи «татар» дийенүр» («Тибйан нафигъ»).

Иске тәварих китабларында Болгар халкыны Дәште Кыпчак, Болгар вә Кырым вә Казан, нугай, сакъләб вә хәзәзийан

---

[48] Кулъязмада «өч» дип ялгыш язылган.

вә хәзәр вә үзбәк татары, Тур вә төрк нәселе дийәрләр. (Бәгъзе ривайәтдә «сакъләб» димәк – дөрес ирмәс, дийәрләр).

Фарсы халкы һәм «татар» дийәр вә әксәрийан «үзбәк» дийәрләр. Хосусан, Бохараи шәриф халкы – сартлар, тазҗикләр халкы, үзбәк – «татар» дийәрләр. Әмма төрекмән халкы, хивалыклар «татар» дийәрләр вә «Болгар халкы» дийәрләр. Сарт халкы, Кукан, вә Ташкәндләр «нугай» вә «татар» вә «үзбәк» дийәрләр. Ушандак төрекләр (Госманийә халкы) «татар» дийәрләр.

Әмма «татар» ләфзы кадими ләфыз улуб, изафи мәгънәсүн галә вәҗһет-тәхкыйк белмәк бик мөшкилчә улуб, ихтималате мәзнунәләр улса да, лөгать вә тәварих китабларында исем вә гыйлем мәгънәсендән башка мәгънә ифадә булмайуб, мәхыз бер вилайәт вә бер таифәгә исем улмакун ишгар итдүкләрендин, мәгънәи махсуса галәмә вилайәт мөсәбасендә улуб, кадим заманда бер кеше исем[е] улса да, мөрүрез-заман илә әүляде кәсирәсе хасил улуб, таифәи махсусаи мөтәнәүвига вә бер җәмгыйәте газыймийә тәшкил идүб, әтрафе галәмә мөнтәшир улдыкларындин, кә-әннәһә, татарлар ныйсьфеддөнйа вә ныйсьфе көррәи арызы ихата кыйларак, анларны белмәйән кеше улмаса да, һәнүз хакыйкатьләрне бәйан вә мәүзыйгы зоһурларыны бәйан вә гайан зарури улдыгы бу заманда әзһәре минәш-шәмсдүр ки, һәр фәрдне истидга идәр.

// (*14б кәгазь*) Татарларның бәйаны руханийәт хәзрәти солтан Хуҗа Әхмәд Йәсәви[49] (рәхмәтуллаһи Тәгалә ганһе рәхмәтән васыйгатән): «Мәгърибдә – тәрсә, Вөстада – җәһүд, мәшрикъда – татар».

Төркестанда тасныйф кыйлынган «Бакырган китабы»:

Сөбхан Изем үзедер
Ул Мостафа бойурды.
Бабам Арслан тигүрде,
Шәйхем Әхмәд Йәсәви.

---

[49] *Хуҗа Әхмәд Йәсәви* – Урта Азиядә яшәгән мәшһүр суфи шагыйрь (1166 елда вафат булган) Әхмәт Ясәви.

Мостафаның хиркасен
Киде, йиде локъмәсен,
Тотды Кәгъбә хилкасен
Шәйхем Әхмәд Йәсәви.

Бакса – Кәгъбә күрәлгән,
Басса – йирләр тәрәлгән,
Ләдүн гыйльме вирелгән
Шәйхем Әхмәд Йәсәви.

Асылы ирер хандан,
Белмәс аны күб надан.
Белүр аны Хакъ Йәздан,
Шәйхем Әхмәд Йәсәви.

Исхак баба йирене,
Шәйх Ибраһим колыны,
Мәшаихләр олугы
Шәйхем Әхмәд Йәсәви.

Йассы суының арасы,
Йатур гәүһәр парәсе.
Мәшаихләр сәзасе
Шәйхем Әхмәд Йәсәви.

Карчыганы кушлаган,
Шонкар, лачын ушлаган,
Сансыз мөрид башлаган
Шәйхем Әхмәд Йәсәви.

Шәригате арастә,
Тарикате пәйвәстә,
Хакыйкатьдә шаистә
Шәйхем Әхмәд Йәсәви.

Көн тугарындин батарга,
Тәрсә, җәһүд, татарга,
Коллык кыйлыб сатарга
Шәйхем Әхмәд Йәсәви.

Унсигез мең галәмдә,
Аты мәшһүр кәлямдә,
Үзе Дарессәламдә
Шәйхем Әхмәд Йәсәви.

Баблар бабы Хорасан,
Сансыз төмән – Һиндустан.
Бабалар башы – баба Арслан,
Шәйхем Әхмәд Йәсәви.

Атам аты азгусы,
Йопар булуб тузгусы,
Ике җиһан көзгүсе
Шәйхем Әхмәд Йәсәви.

Хәзрәт берлә сохбәтлек,
Илйас берлә өлфәтлек,
Хакъ кашында хөрмәтлек
Шәйхем Әхмәд Йәсәви.

Төркестанга баралың,
Хезмәтендә булалың,
Өлеш бирсә, алалың,
Шәйхем Әхмәд Йәсәви.

Баба Мачин – ул солтан,
Мөрид булды бигөман,
Хәким хуҗа Сөләйман[50]
Шәйхем Әхмәд Йәсәви.

[50] *Сөләйман* – бу шигырьнең авторы, Урта Азиядә яшәгән мәшһүр суфи шагыйрь (1186 елда вафат булган) Сөләйман Бакыргани. Аның әсәрләре татарларда дәреслек буларак кулланылган.

Мәзкүр татарларның җәмгыйәт вә җөмһүрийәтләре Хытайи шимали тарафы улан Татарстане кадим арзындан зоһур вә хоруҗ идүб, Амур суының Татар диңезенә койдукы җир «Татарыски пырлиуф» – «Татар бугазы»ндан чыкуб, дийаре Шәрыкдә Магул, Чин вә Мачин вә Кашкар, Зәмин, Тибетләр вә Төмән, Һиндустан вә Һинде чини тарафларында татарлар кидәрәк, бер хәйлчәсе Туран вә Төрек вә Уган вә Әфганстан вә Бәлүҗистан тарафларына кадәр татарлар варуб, Иран мәмләкәте үзәрендә Көрдестан зәмине вә Дәүләте Госманийәдә улан әразыйда Мисыр вә Йәмән вә Рум иле тарафларында вә Болгарстан вә сакъләб, ләһ, пуляк вә чеһ, нимеч, венгрус (Венгрийә) тарафларында татар вардур. Вә Алманийә (вә Алан вә Иланд), вә Русь, Бәләнҗәр, Белый сарда, та сәдде йәәҗүҗ вә мәәҗүҗ мөнтәшир уларак, берничәсе бәррү гатикъдан бәррү җәдиди улан Америкаи мәшһүрнең шимали Америка улан инглизләр мәмләкәте корбе улан әрканҗиле җәдид бәйнендә интишарлары мәзнун улуб, хосусан, Йапонийәдә мәзһәбе шафигыйда мөтәмәккинләрдүр дийәрләр. Татар диңез[е]дән кичүб, җәзирә бә-җәзирә кичәрәк ирешмешләрдүр.

// (*15а кәгазь*) Ош[бу] татарлар күб такым, нәселләрдә булуб, бу заманда ибтидаән татарлыкны белмәк бик мөтәгассир исә дә, бик иске тәварих китабларында улан хикәйәт вә «татар» ләфзы вә лөгать китабларында мәзбур улдыгындин татарларның бик иске вә көй (вә авыл) вә әлфазе кадимәләрендин беленүр ки, татарлар бу заманда әнвагъ лөгатьләрә вә әнвагъ әлбисәләрә вә әнвагъ мәскәнә вә пик мөтәнәүвигъ әшкял вә сурәтләр пәйда идүб, төрле-төрле мәмләкәтләргә мөсафәрәт вә мөҗавәрәт вә бик сәйәхәт идүб, әҗнәбләрдән әшкялне әхәз идүб, җәмгыйәте мәзкүрәне бади нәзардә бу заманда булган татарларны кадим хан заманында булган татарларга бик әҗнәб халәтдә вә әшкялдә күрәҗәкләре бәдиһи улдыгындин, кә-әннәһү, татарлар бу заманда татарлыкдин чыкмыш кебидүр.

Әмма Казан вә Болгар татарларының табигатьләрендә хәмакать мәркүздүр, нитәкки «Тәзкирәтел-хөкем табакателөмәм» китабында мәзкүрдер. Әмма татарлар бик мөтәнәүвигъ

исемдә: магул татарлары дийәрләр вә кимәк татарларыдур ки...[51] дийәрләр вә ... татарлар[ыдыр] вә ... татарларыдыр, хырхыз татарларыдыр. Хәзәр (вә хәзәз, хакан, һәзар вә Чине фәгъфур) халкы вә шәркый улдыкларындин бу мәгънәйе ифадә идәр.

Вә дәхи татарларның табигатьләре әҗнәбдән әшкяле гаҗибәне әхәзгә бик мәййальдүр ки, кадим заманда анлар күчеб йөргүче халыкдур, нитәкки бу заманда кыргызлар лисане халь берлә үзләре дога кыйлдыкларындин мәхзүфат вә тәбдилят вә тәхвилят вә тәхрифатлары чукдыр ки. Бу заман әксәрийан лөгатьләре русидур, хосусан, җәһаләтдә калмыш гавамларында. Әмма хәваслары бер парә Асийәи вөста вә лисане госманийә берлә тәкәллем идәрләр вардур.

Хан заманында вә Болгар вә Казан хөкүмәте заманында татарлар һәрбер нәүгысе берлә арзыр-Рум вә Кырым вә Капкас халкы кеби тәкәллем кыйлганлардур. Чөнки Болгар халкы барча әкраде мөхтәлифә вә әтраке мөхтәлифәдүр ки, либасда вә тәкәллем вә ханә әсбабында асыл төрк нәүгысенә раҗигълардур.

Хәзерендә Казан татарларының иске вә кадими лисан вә лөгатьләре[ндә] чуаш вә чирмеш вә мукшы вә ар халкы тәкәллем идәләр. Кадим заманында, хан заманында һәркайусы чуаш либасы вә лисаны күк булганлардур.

Хәзерендә Казан җирендә мөселман татарларының авыл (вә көй вә карйә) исемләре чуаш теленчәдүр: Орымширмә, Караширмә, Икшермә, Мулчирмә – монлар барчасы Мишә суы буйында. Әмма Тау йагында чуаш авыл вә көй вә карйәләренең исемләре бу заман Казан татарларының телендәдүр ки, мәсәлән, Шыгали, Кызылҗар, Төшкилде, Туктамыш, Айдар, Куак авылы, Җөлки. Казан җирендә авыллар: Мәмәш, Мөндеш – чирмеш лисаны кебидер. Мәчкәрә вә Йаңгул – ар лисаныдур, вә Пыжмара вә Шода. Тау йагында чуаш авыллары: Әҗбәбә – Хаҗи бабадур, Зәршәр – Хәзәр шәһәрдүр, Алибучы – Гали башы вә башкалары ушандак Казан татары теле берлә чуаш вә башка болгар халкының лисанлары катушуб беткәндер ки, борын заманда бер лисан вә бер фәмдүр.

---

[51] Кулъязманың бу җөмләсе кәгазь читендә язылганлыктан, бик таушалган, сүзләре беленми.

// (*15б кәгазь*) Караширмә дигән сүз, «кара» мәгълүмдүр – төрки вә татардур, әмма «ширмә» дигән сүз «чирмә» дигән сүздүр ки, татарча «җырма» вә «җырмак» дийәрләр ки, төрекчә «җырмак» вә «йырмаг» дийәрләр. «Орым» дигән сүз «озун» дигән сүздүр, халис хәзәр (вә чуваш) теледүр. «Икшермә» – «Ике җырма»дур, «Мулчирмә» – зур вә мул чокырдур вә җырмадур.

Аз гына башкалык илән кәлимә башка лөгать кеби күренәдүр вә беленәдүр. Әмма әрбабел-гыйлем тизлек берлә фәһем идәр. Әксәрийан Тау йагында чуаш вә мишәр вә мукшы таифәсе улуб, анлар һәм кадим замандан калган төрк лөгате берлә тәкәллем итсәләр дә, мөрүрез-заман берлә кәлимәләрендә бик тәгайер вардур. Әмма дөнйа күрдеге кемсәнә тиз фәһем идәр, мәсәлән, Тау йагында татарлар җаһил адәмләре «шәһәр» дигән сүзне «шәр» диб сүләшәләр, «карыз» дигән сүзне «карыч» диб әйтәләр, «бәхет» дигән сүзне «бәкыт» диб әйтәләр, «талыйга (вә «талига») йолдызы» дигән сүзне «тәлдәй» диб әйтәләр. «Йахшы» дигән сүзне «җакшы» вә «йакшы» диб әйтәләр. Әгәр дә асыл төрки китабларун күрмәйенчә торыб, җәһаләтдә калсалар, йөз йылда тәмам телләре башкаруб, татарлыкдан чыкуб, башка кавем булуб беленүрләр иде, нитәк бу заманда чуаш таифәсе хакыйкый төрк нәүгысендән булуб торуб, башка җенес вә башка таифә күренәләр. Вәхаләнки, анлар хан заманында мөселман булганлар. Әмма анлар лисанларында тәмам төрке хакыйкыйдур. Чирек лөгатьләре русийәдүр ки, дүрт йөз йылдан бирле бу йак мөселманлыкны пыракмышлардур ки, Русийә издихам кыйлмак берлә. Йукса анлар (йәгъни, чуашлар) тукуз йөз йылга кариб мөселман булуб тормышлар.

Чуаш авылы (вә көй вә карйәләренең) корбендә пыракмыш иске кадими мөселман чуаш мазарларында күрендеге ташларның замане тарихы хикәйәт идәр ки, җөмләдән Шыгали[52] чуаш авылында мөвәххәдләр вардур ки – унике ханә. Мазарларында улан бер таш айәте кәримә Коръәндән йазылмыш,

[52] *Шыгали* – хәзерге Чувашстан Республикасының Урмар районындагы Иске Шигали авылы.



*Минһаҗетдин Җәбәли Шигали зиратында өйрәнгән, Тенеш исемле кешегә куелган 1550 елгы ташъязма истәлек (фото В.Усмановның «Чувашстан Республикасы татар эпиграфик һәйкәлләре» китабыннан алынды)*

мәгърәкәдә шәһид улмыш чуашдур ки. Асты «тарихе һиҗрәт йөз кырыкда рабигыль-әүвәлдә Әсәд кяфер кулындин шәһид булды, вә ма тәдри нәфсүн би-әййи ардин тәмүтү»[53] диб йазылган, рәсме госманийә вә пашаи рәсемдүр. Икенче ташда «Вә ма

[53] *вә ма тәдри нәфсүн би-әйии ардин тәмүтү* – Коръәннең «Локман» сүрәсендәге 34 нче аять, мәгънәсе – һичбер кеше кайсы җирдә үләчәген белми.

тәдри нәфсүн би-әййи ардин тәмүтү» йазылуб, тарихе һиҗрәт «тукыз йөздә Әсәди угылы Тенеш кяфер кулындин шәһид бул-ды». Бу йазу ифадә идәр ки, мәзкүр Шыгали авылы мең йыл мөселман булуб, соңра җәһаләтдә калмыш улдыгын белдерүр вә ислам дине пыракмыш улдыкларун хикайәт вә гайан идәр.

Мәзкүр мазарга өч көй күмгән: Тегеш, Кызылҗар[54], Шыгали. Вә башка илләрдә дәхи дә моның мисалы күбдүр. Вә боның имсале чуаш авыллары мөселман мазарларын пыракуб, тәнассыр итде[ке]ндән[55] соңра башка мазарстан йапмыш улсалар да, һәнүз галә халиһи мазарлары мәгълүм вә ташлары күбдер, һәммәсе тарихе һиҗрәте әксәрийан тукыз йөздүр.

// (*16а кәгазь*) Бу мазарга өч авыл халкыны дәфен иткәнләр, вә хәтта өчәр көнлек йиргә кавем-кабиләсе булса, китүрүб дәфен иткәнләрдүр. Ислам гадәтләрене үзә, нитәк «Шәрхе әрбәгыйн» китабында мәзкүрдүр ки, [*бу урында мәрхүмне җирләү һәм каберенә билге өчен таш кую турында пәйгамбәрнең гарәп телендәге хәдисе язылган*].

Хан заманында чуашлар барчасы мөселмане хакыйкый вә хәзәр халкы (вә Хәзәзийан халкы вә төрк нәселе), бәлки хакыйкый төрк улдыкларыны пыракмыш (вә пырахкән) мазарларында улан ташлары хикәйәт идәдүр ки, ул бичаралар кадим заманда мең йылга кариб мөселман булуб тормышлардур.

Кабер өстенә таш куймак – сөннәте рәсүлдүр вә кавем вә нәселләрне бер мазаргә дәфен кыйлмак һаман сөннәтеррәсүлдүр. Кадим заманда чуашларда һәммәсе бу фигыльләре булгандыр. Мазарлар вә әфгальләре вә лөгать (вә лисанлар) хикәйәт идәдүр, бәдиһи мәгънәдүр – чуашларның пыракмыш мазарларында улан ташларның әксәрендә урыс берлә мөхарәбә вакытында мәгърәкәдә шәһид улмыш чуаш

[54] *Тегеш, Кызылҗар* – хәзерге Чувашстан Республикасының Урмар районындагы чуваш авыллары. Риваятьләр буенча, Шигали, Кызылъяр һәм Тегеш авыллары Болгардан килгән кешеләр тарафыннан нигезләнгән. Чуваш галимнәре язганга караганда, Кызылъяр авылын татарлар нигезләгән һәм ярты халкы мөселман (татар), яртысы мәҗүси (чуваш) булган.

[55] Кулъязмада: итдендән.

таифәләредүр ки, анлар кадим хан заманында мөселманлар икән.

Вә дәхи хәзерендә тәгам йимәк вә чимек морад итдүкләрендә кирәк бай, вә кирәк фәкыйрь – кяффәтән чуаш халкы «бисмилләһи» вә «исме Аллаһи» вә «исмилләһ» берлә тәгам тәнавел идәләр вә һәм һәрбер эшкә шөруг кыйлганда. Вә дәхи кыз никах итүб алганда мәһәр тәгайен кыйлалар. Вә дәхи җомга көнне «азна көн» диб (йәгъни, «азинә» – төрки теледүр), гайде мәсәррәт кыйлалар. Ләкин папаслар бик нәһи кыйлалар.

Вә һәм Болгар шәрифдә ташларның әксәре чуаш лөгате берлә йазылуб калдыгындан бәлки Болгарның гасаба халкы чуаш булса кирәк диб фәһем иделәдүр. Вә чуашларның бик зур вә галим вә галляматез-заман адәмләре булган Әҗбаба дигән чуаш авылында булган Хаҗи бабадур вә һәм ике Әренкә вә Шулкан, Акйегет авылы вә Бакырчы күле, Җуансы. Ырмар[56] дәфен кыйлган мазарда булган таш һиҗрәт тарихы тукуз йөз, Мөхәммәд Чәләбидүр[57] ки – лисане госманийәдә уникe фәнне җамигъ булуб, тәкъва вә суфи вә Ходаи кеше дигән сүздүр. Чөнки асыл гарәбдә «җәләб» вә «чәләб» дийәрләр, Аллаһы Тәгаләнең исемедүр (әмма «Аллаһы» – мөгаррәбдүр) ки, ил ләфзындан ул ил ләфзы сөрйанидур, Ходай вә Тәңре мәгънәсендәдүр.

---

[56] Автор бу җөмләләрне буталчыграк язган. Чөнки монда күрсәтелгән атамаларның барысы да чуваш авыллары түгел. Әҗбаба һәм Ырмар (Урмар) – Чувашстанның Урмар районындагы чуваш авыллары. Ә Әренкә, Шулкан дигәннәрен ачыклый алмадык. Әренкә дигәндә, бәлки, хәзерге Яльчик районындагы Аранчы авылы күздә тотылгандыр. Бакырчы һәм Акъегет – хәзерге Яшел Үзән районындагы татар авыллары. Чувашстандагы Иске Урмар авылы да элек Акъегет исеме белән йөртелгән. Җуансы дигәндә, бәлки, Яшел Үзән районындагы Юынчы (Сөнчәләй) авылы күздә тотылгандыр. Һәрхәлдә, бу атамаларның дөрес вариантлары шул төбәктә яшәүчеләргә мәгълүмдер. Иске Урмар (Акъегет) авылы зиратында 1736 (һиҗри 1149) елгы һ.б. мөселман кабер ташлары бар икән.

[57] *Мөхәммәд Чәләби* – Каюм Насыйри язганнарга караганда, мондый исемле изге кеше үзе Әҗбаба авылыныкы булып, Бакырчы зиратында җирләргә дип васыять әйткән һәм аның XVI гасырда куелган кабер ташы хәзергәчә сакланган.

Китабларда мәзкүрдүр, бер заман Мәскәү урыс халкы Казан истиля кыйлмак нийәте берлә чыкгандыр ки, тарихе һиҗри тукуз йөздән[58] бераз мөкаддәмрәк, гаскәре йөз утуз мең кадәрледән ким кыйлмагандур. Мәзкүр гаскәрнең [йөреше] // (*16б кәгазь*) бу йулы Хәзәр шәһәре вә хәзәр (вә хакан) халкы – чуашларга тугры килүб, анлар берлә алтмыш-йитмеш йыл микъдары мөхарәбә итдекләрен фәһем итдерән ташлар вардур ки, чуаш таифәсе өсләрендә йитмеш йыл микъдар урыс гаскәре басуб йатмышдур. Чуашлар урыс берлә мөхарәбә идүб, урыс галиб килүб, чуашның күб кемсәнәләре шәһид улдыкларун мәзкүр пыракмыш мазарлары хикәйәт идә.

Әмма урыс гаскәре басуб йатканда чуашларны гамь тәнассыр кыйлурга вакыт булмай калуб, чуашлар исламдин җәһаләтдә вә мәҗүсилекдә калмышлардур ки, мөселман булдук заманларында һәм мәҗүсилек галәмәтләре бар иде. Чөнки кяффәтән татарлар да вә көрдләр дә вә төрекләр дә – Болгар әтрафында сакин хәляикъ, гъад кауме булдукларындин, гъад кавемләре атәшпәрәст булдукларындин вә кирәмәт[59] тотмак вә уйун вә җыйунларны кабил улдыгындин[60] пәйда улуб җиһанә калыкмышдур.

Голямаи гыйзам манигъ кыйлсалар да, бил-көллийәт мәныгъләнмәй, бәгъзе әмякин вә мәүзыйгда зоһуры мәзнундур ки, бәлки вакыйгъдур. Мәсәлән, хатты горефдә мөселман татарның гъад вә Әфридун хөкүмәте заманындин калган фигыльләре – кирәмәт тотмак бар. Бәгъзе кемсәнәләрнең келәтләрендә капчык вә кисә берлән акчалар күбдүр, йаз көне нәүрүз әйтүб йөрмәк кеби, вә дәхи Олы көн утдан сикерешүб чыкмак кеби Әфридун гамәледүр. Чимек көне бәйрәм йасаб, чимәк уты җыймакларыдур ки, борун заманда кыз вә хатунлар ахшамдан соң җыйулышуб, урманга баруб чимек[61] уты

[58] Һиҗри 900 нче ел миләди буенча 1495 елга туры килә.

[59] *кирәмәт* – Идел буе халыкларындагы мәҗүсиләрдә келәү (табыну) һәм корбан китерү урыны (гадәттә, изге агачлык).

[60] Кулъязмада: уландин.

[61] Кулъязмада З.Максудова бу сүзнең астына гади карандаш белән дулкынсыман сызган һәм кәгазьнең уң читенә сорау билгесе куйган.

җыйуб кайтуб, ул нәбат (вә утлар) берлән госел койунмаклар кеби, адәм[не] сагъ (вә сәламәт вә таза) кыйладур диб, Олы көн сач тарамаслар иде. «Олы тәре козылган» көн диб, җыл да бер бәйрәм йасуб, сиксән камәт вә сиксән илек берлә җанлар кабердән чыкганун карамак кеби. Вә шилык бәйрәме йасуб, бер йегет атга бенүб, өй сайын берәр җомырка җыйуб, күб булгач җыелышуб ашамаклары кеби, сабан туйлары кеби. Тау йагында сабан туй өй сайын сыра эчүб йөрүб, артдан кызыл йомыркалар өләшмәк кеби. Монлар барчасы Тау йагының вә башка татарларның гъад каумендән вә Кабил[62] әүлядындан калмыш шәйләрдүр. Хосусан, Әфридундан калдыклары вардур бер парәсе.

Урыс Казанны алгач мөселманларны бик тарлык кыйлмышдур ки, хәзерендәге мөселманлар тау-чокыр арасындан качуб калуб, бүгүн заһир вә хариҗ улуб, күб булмышлардур.

// (*17а кәгазь*) Хәзерендә мөселманлар күб булмышлардур. Бәр фараз вә бәр тәкъдир, татарлар ислам динедән мәныг кыйлалар, әлгайазе билләһи, сүммә әлгайазе, һич дин берлә мөтәдәйин улмасалар, әлбәттә, анларның бәгъзесе чуаш кеби кирәмәт вә башка шәйләрне иҗад кыйлурлар. Бара-бара, һәммәсе мәҗүси кеби булурлар, нитәкки Мәскәү чуашлар өсләрендә йатуб, ислам гамәлләрүн изһарга рөхсәт бирмәй вә һәм тәнассыр кыйлмай, мәҗүси кыйлмышдур ки, анларның мәҗүси булдыкларына тәхминән дүрт йөз йыл бардур. Алай да, чуашларның бәгъзе карйә (вә көй вә авылларында) мөвәххәдләре вардур ки, әйтәләр: «Безнең чуаш вә чирмеш вә башка тәваиф кадим хан заманында барчасы мөселман булганлар», – диб. Чуашларның мөвәххәдләре, йәгъни тәнассыр кыйлмай вә һәм мәҗүси булмай калганларының исемләре – Әлмәмәд вә Бикми вә Шили вә Заид вә башка, кыз-хатунлары – Шәрбостан вә Гөлбустан вә Сафийиәбанудур. Монлар ислам динен изһарга икътидарлары булмадыгындан, күбесе тәнассыр кыйлалар. Вә урыс анларны бик тәфтиш кыйладур. Анлар җаваб вирәләр: «Адәм

[62] *Кабил* – Адәм пәйгамбәрнең улы.

галәйһиссәлам дине вә Турхан динендә» – диб. Йукса анларны бер оргурдан орыб, нәсари кыйлалар. Анлар иске бабаларун бик сагыналар.

Чуашлар дүрт йөз йылдан бирле ислам динен изһарга икътидарлары улмадыгындин, әксәрийән мәҗүслекдә күрүлүб, урыс халкы әйтәдүр: «Чуаш халкы кауме махсус вә шәкле махсус гаҗәйеб сирәт вә гариб сыйфат, Казан татарларына башка кавемләрдүр, кадим заманындук мәҗүси вә һәм икенче җенес» диб, «йазычный бирыда (вера)[63] булганлар» диб әйтәләр. Хәзер чуашлар татар булуб вә мөселман булуб бетәләр диб, бик тәфтиш кыйлалар.

Урыслар белмәйләр – чуаш таифәсе хан заманында татарлар күк мөселман булганларун, урыслар әйтәләр: «Хәзер генә фәлән татар авылы чуашдан татар булган», – диб әйтәләр. Дәхи дә соңрак әйтүрләр – «Барча татар чуашдан», – диб.

Энде без – мөселман татарлар әйтәмез: чуашлар көллисе татардан диб вә көллисе төрк (вә хәзәр вә хәзәз вә фәгъфуре Чин вә хакан) халкы, Болгарның гасаба халкы! Искедән мөселман булганлар, мең җыл мөселман булуб торганларун мәзкүр ташлар әйтә. Вә дәхи дә әфгальләре вә кийемләре әйтә. Күбдән түгел анларны урыс көчләб тәнассыр кыйлмакчы булуб, мәҗүс йасуб киткәнләрдүр. Хәзер урысның исенә төшкән тәнассыр кыйлу нийәте, чуашларның исенә төшкән ислам нийәте.

// (*17б кәгазь*) Чуашлар әйтәләр: «Безнең бабайлар барча хан булганлар, – диб, – вә мөселман булганлар», – диб. Кайда калды болгар берлә чуаш арасы? Чуашлар мазарларын күрүб бик йыглаучылары бардур.

Бәгъзе дүн кемсәнә анларны нәсари хакыйкый диб беләдүр. Анларда нә нәсарлык вә нә исламлык вә нә йәһүдлек. Мәҗүслекдән башка мәгънәләре йукдыр. Гъад заманындагы халәтләренә рөҗуг кыйлуб, мәҗүси булуб калмышлардур.

Ләкин анлар исламга бик мөстәгыйдләрдүр. Хан заманында чуаш вә чирмешләр вә мукшылар вә бутяклар – һәркайусы

[63] Кулъязмада «вера» сүзе гади карандаш белән теркәлгән.

мөселман булганлардур. Анларның мәҗүсилекләре дүрт йөз йыл мөддәтендәдүр. Йукса, Болгар кавеме әтраке мөхтәлифә вә әкраде мөхтәлифәләрдүр ки, йукарыда ләфзан вә мәгънән бәйан вә гайан кыйлдык – анлар халис мөселман булуб, биләр (вә бик) берлә мөрүрез-заман итмешләрдүр. Иске заманында булган кешеләр[64] исеме татарчадур: Тәтеш баба, Чуаш бабай вә Кармыш бабай вә Мукшы бабай вә Мамадыш бабай, Лайуш бабай, Чирмеш бабай, Малмыж бабай, Бутяк бабай, Ар бабай. Тау йагында авыл исемләре Мамадыш, Кармыш, Күгеш, Багыш, Даныш, Борнаш, Үтәмеш. Казан җирендә: Җуртыш, Әрнәш, Кош, Лаш, Мөндеш, Мәмәш, Чирмеш Иле. Мишә суы буйында: Караширмә, Орымширмә, Икшермә, Бүлчирмә, Кайынзар. Тау йагында: Шуширмә, Чирмешән, Кошман, Сатмыш, Карамисар. Чуаш авыллары: Җәмәш, Тугаш, Куак авылы вә башкалар – барчасы төрк лөгатедүр. Кадим хан заманындагы лөгатьләрдүр, барча кеше исемләредүр. Хәзерендә авыл вә кальга вә кавем исеме булуб калмышдыр ки. Әүвәл белмеш татарның әксәрийан кәлимәләренең ахырында «шин» хәрефе илә әда идәрләр ки, төрекләрнең һәм шулай белмешләрдүр, нитәк чуашмы вә чирмеш вә мукшы төрк хакыйкыйлардур.

Казан татарларының һәм телләрендә тәфрика-тәфрика берәр лөгать илән тәкәллем идәрләр, нитәкки авыл берлә авылның арасында лөгатьтә тәфавете кәсирә улдыгы вардур. Әмма әкраде мөхтәлифәләр вә әтраке мөхтәлифәләр ки – Болгар халкы бер-берсенең лөгатьләрүн бик дуст күрәләр. Ләкин тәфаветнең дәрәҗәи табигыйсе булса да, асыл бер кауме махсусның лөгатьләрүн үзләре бик йахшы дуст күреб, «менә бу безнең тел» диб әйтәләр.

Лөгатьдә чуашлар вә чирмешләр вә мукшылар вә мишәрләр вә төмәнләр вә башка Болгар хәляикы арасындагы тәфавет анларның бер-берсенә башка кавем икәнчелекне исбат вә тәказа кыйлмаганлыгы өчүн табигый вә асыл шәй берлә гаризый вә гарийәт шәйнең нишаны вә галәмат вә тәмәйез иделмәгә

[64] Кулъязмада бу сүз ялгыш ике тапкыр кабатлап язылган.

вә тәфрикасы пөрзаһирдур. Нитәк русийә лөгате[ндә] мәзкүр кавемләр дә көллийәтән тәкәллем идәрләр, ләкин һәммәсендә гаризый вә гарийәтдүр.

// (*18а кәгазь*) Шулкадәр вар ки, бәгъзе гарийәт вә гаризый лөгать һәм табигый вә хәлкый лөгать кеби уладур – кәсрәт тәкәллемдән вә кәсрәт истигъмальдән вә хәтта бер кавемнең бер лөгате мөрүрез-заман берлә тәгайере көллийе дөхуль идәр улдыгы әзһәре минәш-шәмсдүр. Нитәкки татар лөгате бу заманда бер лөгать вә бер кавемнең эчендә ничәмә мөхтәлиф хөруфләр вә кәйфийәт ихраҗында әзляф вә сауте кәлямдә ничә кадәр шөгъбәләр пәйда улмышдур ки – гыйбрәт ийәсе хәйрәтә китмешдүр. Мәсәлән, бер лөгатдүр ки: «бу йиргә кәл», төрек дийәр – «бурадә гәл», татар дийәр – «бу җиргә кил», чуаш әйтүр – «кунда кил». Һәммәсе монлар бер кавемдер. Безнең гыйльмемездә вә фәһемемездә адәмнең лисаны вә лөгате тәэсирате һавадан вә икълиме арздандыр. Мәзкүрәдән хасил улан әтгыймәдән табигатькә бер кәйфийәт тәваллед идәр улмакы фәһем улынмышдур ки, нитәк хатты истива тарафларында көндүз вә кичә һәр заманларда бәрабәрдер. Әмма хатты истивадан тәбагыд итдүкчә һәрбер дәкыйкадә тәбдил вә тәхвил бардыр – кичә вә көндүз бик озун, хәтта 2 маһдан зиядә көн булур булдыгы кеби табигатьләрендә ушандак зийәдә ноксан улуб, лисанларында вә һакәза. Нитәк суык һаваның тәэсире лисан үзә булмамакы бисарахәтән кәлимәләрне бозуб сүләштерә. Әмма татарлык, төреклек вә урыслык, франсуслык вә башка таифәлык асыл нәсәбнең шөгъбәсене асылдан бер кәйфийәте дигәр берлә хоруҗны хикәйәт вә хәзрәти Адәмнең зөррийәтене фәләнчә шәгыбдә вә исем вә мәузыйгы зоһурыны бер хас исем берлә хикәйәтдүр ки, һичбер дингә тәгаллекыны хикәйәт дәгелдүр. Әсхабел-гыйлем вәл-лөгать гыйндендә әзһәре минәш-шәмс мәгънәдүр ки, әүвәлийат җөмләсендән мәгъдуд казбәдүр.

Бәгъзе дүн вә надан кемсәнәләр мәзкүр гонван илә үзләрен мәганидән идүб вә тәфахир вә тәкәббер идүб, татарлар арасында «Мин – татар!» дәйү хикәйәт идәр ки, моради

– мөселманлыкдур. Һәйһат! «Татар» ләфзындан мөселманлык вә нәсарлык, йәһүдлык вә һәм мәҗүсилек бер таифәи махсусыны хикәйәтдүр. Әмма мөселманлык вөҗүд тасдыйк бил-җөнан вә икъраре бил-лисан улуб, заһирдин хариҗ гамәле ислам идәр улса вә садәдел-иман вә кәсеб идәрәк нурландырса, тәхкыйкан ул зат «мөселман» дийәрез. Кирәксә таифәи француз улсун, вә кирәксә таифәи гарәб улсун, вә кирәк таифәи урыс улсун вә кирәксә чуаш улсун – безнең пәйгамбәремез Мөхәммәд мостафа һәммә җиһан әһленә кяффәтән пәйгамбәредер ки, «ләү лякә лә ма хилькатил-әфляк»[65].

Әмма Болгар халкы арасында әнвагы таифә мәркүздүр: гарәб вә фарс вә төрек вә көрд вә Рум вә Хытай вә Асийаи вөста халкы вә сәкъләб (вә сакъләб) халкыдур ки, Ләһстан халкы ләһ-полякдур, вә Чеһстан халкы чеһ, нимечдүр вә венгрус халкыдур ки («бингер» дийәрләр). Вә төрекмән вә чыгытай вә олунгалы вә Кашкар, Зәмин халкы һәм бардур вә Һиндустан халкы һәм бардур. Әрзыр-Рум вә Бәгъдад халкы һәм бардур – монларның барчасыны бәйан вә гайан кыйламыз.

// (*18б кәгазь*) Әүвәл белмәк кирәкдер кем, асыл адәм Һиндустанда[66] булса да, Нух галәйһиссәламдән соңра өч йирдән хоруҗ иткәнләр һәрбер йиргә вә һәрбер төрле сәбәб берлә, Ходай Тәгалә үзе беләдер.

Гарәб вә рум вә фарс вә дәхи вөстаи арызда уланлар Самә мөнтәсибдүр ки, Нух галәйһиссәлам кәндү хәйатында әүлядына робг мәскүне[67] кыйсмәт идүб биргәндүр ки: биляде Шам вә җәзирәи гарәб, Гыйракы вә Фарсы вә Хорасаны. Ки вөстаи арыздыр Сама вирде, ки әүлядының әфзалы вә әршәде иде. Сам балалары вөстаи арыздан хоруҗ иткәнләрдүр.

Вә Чин-Мачины, Төркестаны Йәфәсә вирде ки, вә әтракь

---

[65] «*Ләү лякә лә ма хилькатил-әфляк*» – Син булмасаң, бу дөньяны барлыкка китермәс идем (ялган хәдис).

[66] *асыл Адәм Һиндустанда* – Адәм пәйгамбәрнең Һиндстан җиренә иңгәнлеге күздә тотылган.

[67] *робг мәскүн* – җир йөзенең кешеләр яшәргә яраклы дүрттән бер (коры җир) өлеше.

(вә хакан) вә йәэҗүҗ вә мәэҗүҗ Йәфәсә мөнтәсибдүр ки, дийаре мәшрикъда әксәрийан ватанлары улуб, Шәрыкдан хоруҗ иткәнләр. Әмма дийаре мәгърибе вә зәнкибары вә хәбәше вә Һиндустаны вирде ки вә дүкәли сийаһләр һинд вә зәнкибар вә хәбәшә вә Судан – Хам әүлядын[дан]дур[68]. Хам әүляды Африкадан вә Һиндстандан хоруҗ идәр.

Әмма мәзкүр вә мәзкүр Болгар мәмләкәтләренә гарәб кавемләре хәзрәти Гомәр заманында дәгъвәт өчүн килүб вә мөхарәбә идүб вә тәваттан идүб калдык гарәбләр татарлар эчендә мәркүз улмышдыр ки, Курмыш өйәзендә Мәдинә[69] авылы дирләр – төрк кавемләре берлә вә гарәбләрдер.

Бер заман – холәфаи габбасийә заманында хәлифәләр биш мәртәбә чыкуб, Болгарны тәҗдидел-ислам вә фәтех әйләгәнләр. Бәгъдад халкы вә төрек халкы күбесе татарлар эчендә мәркүздүр ки – анларга «мишәр» дийәрләр. «Һәмшир» димәк улур ки, асылда «һәмшәһир»дүр – Бәгъдад фарси вә төрки вә гарәби тәкәллем кыйлмакы. «Һәмшәһир» фарси ләфзындан мәэхуздыр ки, «бер шәһәрдәш» димәк улур ки, урысча «земляк» дийәрләр. Төрекләр бер-берсенә «һәмшир» вә «әмшир» дийәрләр вә «әмшири» дийәрләр, сүзне кыскартуб сүләрләр.

Әмма фарс халкы Әфридун хөкүмәте заманында килүб, татарлар эчендә мәркүз улуб, татар халкының исемләре (әксәрийан кызларында) фарси улмакы калмышдур: Шәрбану, Шәрбостан, Гөлбизәр, Гөлҗай, Гөлҗан кебек исемләр. Әфридун халкының килмәге өч мең йылга кариб булдыгыннан, анларны йакыйн бик мөшкилчәдүр, алай да чуаш халыкларында әсәрләре бардур. Авыл исемләре әксәрийан фарсы ләфзында улдыгындан, хакан (һәзар вә хәзәр) халкы чуаш улдыгындан.

Әмма көрдләр – башкордлардур. Төрке хакыйкыйлар – чуаш вә чирмеш вә мукшылардур вә башкалардур.

---

[68] Кулъязмада: әүлядындур.

[69] *Мәдинә* – хәзерге Түбән Новгород өлкәсенең Пильна районындагы Мәдәнә авылы күздә тотылган.

Әмма Хытай халкы Болгарга күбрәк Чыңыз хан вә Аксак Тимер берлә килгәнләрдүр. Хытай, мангул халкы Болгарда күбдер. Мәсәлән, әүвәл исемләр Чутай вә Йангул, кеше исемләре: Атнагул вә Кодигул вә Муллагол вә Айдагул вә Җомагул кеби. Вә «алпавыт» (вә «албагут») – «мөбариз» мәгънәсенәдер ки, магул лисаны вә лөгатедер. Монлар барчасы магул лисаныдур ки, әһеленә хәфи дәгелдүр.

Вә Асийаи вөста лисаны һәм күбдүр, мәсәлән, «диһкан» дигән сүз, «ыспай» дигән сүз – монлар фарсидур. Ки «рыскал» – «русхал»дур, «хәл ирешмәк» дигән сүз. «Ыспай» дигән сүз – «сипаһи» дигән сүздүр ки, гази вә сугыш халкы йахшы чапанлар кийүб йөргәч матур, ыспай кеше диб әйткәнләрдүр.

// (*19а кәгазь*) Вә Һиндстан халкы, вә Кашкар, Зәмин вә Асийаи вөста халкы Аксак Тимер берлә килүб калуб, татарлар эчендә мәркүздүр ки, төмән халкыдур вә каралардур. Болгар вә дәхи дә Искәндәр Руми берлә сакъләбләр (вә сәкъләб), ләһ вә чеһ, венгруслар вә болгарлар килүб калуб татарлар эчендә мәркүз улуб калмышлардур.

Бу бәйандан лязем улан будур ки – Болгарның әтрафында сакин халыкларның асыл нәсәбе бик мөншәгыйб улуб, Нух әүляды улан Сам, Хам, Йәфәс – көллисенең балалары Болгар шәһәрендә улдыклары йакыйн мәсабәсендә бер мәгънәдүр. Йукса, асыл Болгар халкы әтраке мөхтәлифә вә әкраде мөхтәлифәләр булуб, чуаш вә чирмеш вә мукшы вә мурдва вә бутяк вә татарлардур – Сам берлә Йәфәсә мөнтәсибләрдүр, нитәкки «Тәнбиһел-гафилин»[70] китабында мәзкүрдүр ки [*гарәп телендәге өземтәнең кыскача мәгънәсе: «йөз илле кавем яәҗүҗ-мәәҗүҗләр тәмугда янар. Илле төрле халык: румнар, хәзәрләр, сәкъләбләр ... Һиндстан, хәбәш, мәгърибләр, көнчыгышта алты халык: төрки, хакан, гуз, тогр, кимәк, йемәкләр җәһәннәмнән имин булыр»*].

// (*19б кәгазь*)

[70] *«Тәнбиһел-гафилин»* – X гасыр галиме Әбүлләйс әс-Сәмәркандинең дини-әхлакый әсәре.

## Татарларның сабак чираты (вә кизүе)

Әүвәл – әлиф-би[71]

Икенче – әлиф-би иҗеге.

Иҗәк дигән сүз «һиҗәк» дигән сүздер, гарәбидер. Кәлимәләрне вәзен берлә һиҗа вә тәһәҗҗи идәрәк, асыл кәлимәне хәрәкәт вә сөкүн вирүб, татар ләфзы берлә иҗәк идәрләр. «Иҗек» – татарчадыр. Мәсәлән, «мин» – «мим» астда, сыйга сәкен – «мин» диб иҗекләрләр ки, татарчадыр.

Өченче – әбҗәд[72] укырлар.

Дүртенче – әбҗәд иҗәге.

Бишенче – әлиф-бине сүрә кыйлуб укурлар, йәгъни тәнзыйм вә тәртил берлә.

Алтынчы – әбҗәдне сүрә кыйлуб укырлар.

// (*20а кәгазь*) Йиденче мәртәбә – «Иман шарты»[73] дигән китабны укурлар, иҗек вә сүрәсене.

Сигезенче мәртәбә – Һәфтийәк, иҗекне вә сүрәсене укурлар. «Бәдәвам», «Тәкый гаҗәп», «Башлагали»[74], «Мәрйәм ана китабы» китаблары берлә.

Тукызынчы мәртәбә – Кәлям шәрифне сүрә кыйлуб укурлар. Иҗек кыйлмак гөнаһ дийәрләр. «Йосыф» китабы, «Бакырган» китабы, «Сөбател-гаҗизин»[75] китабы вә башка төрки рисаләләрне укурлар.

Бәгъзе кемсәнә хәтме көтеб кыйлур.

Унынчы мәртәбә – «Йәк хикәйәт» (фарси китабы) вә

---

[71] *Әлиф-би* – әлифба.

[72] *Әбҗәд* – саннарны әлифба хәрефләре ярдәмендә белдерү ысулы.

[73] *«Иман шарты»* – гарәп әлифбасын һәм ислам дине нигезләрен өйрәтү дәреслеге.

[74] *Һәфтияк* – Коръәннең җидедән бер өлешеннән торган китап; *«Тәкый гаҗәп»* – Сөләйман Бакырганиның «Ахыр заман» әсәре; *«Башлагали»* – «Кисекбаш» дастаны, *«Мәрьям ана»* – С.Бакыргани әсәре.

[75] *«Йосыф» китабы* – XIII гасыр болгар-татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре; *«Бакырган» китабы* – төрки-татар суфичылык шигърияте тупланган җыентык; *«Сөбател-гаҗизин»* – XVII гасыр төрки шагыйре Аллаһыяр Суфиның шигъри-әхлакый әсәре.

«Хәмде би хәдд» вә «Шөрутес-саләт» вә «Тәгълимес-саләт»[76] китабыны укурлар.

Унберенче мәртәбә – «Бостан», «Гөлстан»[77], «Дөррел-мәҗалис» вә «Морадел-гарифин» китабларыны вә «Сагълүк» вә «Мөхтәсар»[78] китабларыны.

Бәгъзе кемсәнә хәтмел-китаб мәртәбәсе – мәдрәсә[дән] чыкарлар.

Вә әгәр дә күп укыйачак булса, монларны көллисене укурлар:

Әүвәл – сарыф, сарфави «Шәрхе Габдулла».

Икенче – «Кавагыйд» (озын вә кыскасыны), вә «Тәркиб», вә «Әнмүзәҗ»[79].

Бәгъзе кемсәнә хәтем идүб, чыкар мәдрәсәдән.

Өченче – «Кяфийә», «Шәрхе мулла»[80] укуб, мәдрәсәдән чыкарлар бәгъзеләр.

Дүртенче – фәне мантыйкдан «Исагуҗи», «Мулла Садыйк», «Шәмсийә», вә «Гакаид», вә «Сөллям»[81] укуб, чыкарлар бәгъзеләр мәдрәсәдән. Көтебе мәсаилдән фикъһ,

[76] *«Хәмде би хәдд»* – мәшһүр әдип Фәридеддин Гаттарның «Пәнднамә» исемле, фарсы телендәге шигъри нәсыйхәтләр китабы; *«Шөрутес-саләт»*, *«Тәгълимес-саләт»* – намаз шартларын һәм кагыйдәләрен өйрәтү буенча Дагстан галимнәре язган гарәп телендәге әсәрләр.

[77] *«Бостан», «Гөлстан»* – XIII гасыр шагыйре Сәгъдинең фарсы телендәге мәшһүр поэмалары. «Бостан» исемлесе кулъязмада «Гөлбостан» дип язылган, ул татар кулъязмаларында шундый исем белән дә йөртелгән.

[78] *«Сагълүк»* – XVI гасыр галиме Әбелләйс әз-Зилинең «Һәдиятес-сагълүк, шәрхи Төхфәтел-мөлүк» исемле, шәригать нигезләренә багышланган, гарәп телендәге китабы.

[79] *«Кавагыйд», «Тәркиб»* – гарәп теле грамматикасы нигезләре; *«Әнмүзәҗ»* – Мәхмүд бине Гомәр әз-Зәмәхшәринең (1075–1144) «Китабел-әнмүзәҗ» исемле, гарәп теле грамматикасы.

[80] *«Кяфийә»* – Ибне әл-Хаҗибнең (1249 елда вафат булган) гарәп телендәге әсәре; *«Шәрхе мулла»* – гарәп теленең морфологиясе буенча фарсы телендә язылган трактат.

[81] *«Исагуҗи»* – XIII гасыр галиме Әсиреддин бине Гомәр әл-Әбһәри тарафыннан грек телендәге әсәрне эшкәртеп, гарәп телендә язылган «Китабел-Исагуҗи» исемле, мантыйк буенча хезмәт; *«Мулла Садыйк»* – «Исагуҗи» китабына хашия (аңлатмалар) рәвешендә, гарәп телендә язылган хезмәт; *«Шәмсийә»* –

«Һидайә» вә «Шәрхел-викайә» китабларын укурлар.

Бишенче – «Тәһзиб», «Хикмәтел-гайн», «Мулла Җәлал» вә «Тәүзыйх» вә «Тәлхыйс» вә «Мотауваль», вә «Тәҗрид»[82]. Хәтеме көтеб мәртәбәседер. Бу мәртәбә надирдыр Болгар йортында.

## [I вариант]

// (*26б кәгазь*)

Бисмилләһир-Рахмәнир-Рахим.

Әлхәмде Лилләһи Раббил-галәмин әл-гакыйбәтел-мөттәкыйн вәс-саләте вәс-сәлам галә сәйидина Мөхәммәдин вә алиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн.

Әмма бәгъдә, игътикадә мәзһәбем әһлес-сөннәт вәлҗәмагать улан имам Әбелмансур Матуриди хәзрәтләренчә игътикад идәрәк, вә гамәлдә имам әгъзам Әбү Хәнифә хәзрәтләре кауленчә вә шәкердләр[е] – имам Мөхәммәд вә имам Әбү Йосыф вә имам Хәсән бине Зийад вә имам Зөфәр кауленчә заһири гамәлдә гамәл идәрәк, вә силсиләи суфийәдән Әбүбәкер әс-сиддыйк (разый Аллаһу Тәгалә ганһе)дән зоһур идән силсиләи Габделхаликъ әл-Гыйҗдувани вә тарикаи Нәкышбәндийә хәфи улан тарикъда тәхлийә вә тәхлийә идәрәк Аллаһ диб, мән Минһаҗетдин бине Сәйфулла бине Мөхәммәдшәриф бине Гаделшаһ бине Габдеррахман әл-Маматыши әл-Җәбәли Тау йагында Гөбенә суы буйында улуб, мән Минһаҗетдин,

XIII гасыр галиме Нәҗмеддин Гали бине Гомәр әл-Казвининең мантыйк буенча гарәп телендә язган «Әр-рисаләтеш-шәмсийә фил-кавагыйделмантыйкыя» исемле хезмәте; *«Гакаид»* – Нәҗмеддин Әбү Хафса Гомәр Нәсәфинең (1068–1142) кәлям гыйлеменә багышланган гарәп телендәге әсәре; *«Сөллям»* – Габдешшөкүр әл-Бихари (1707 елда вафат булган) тарафыннан мантыйк буенча гарәп телендә язылган «Әс-сөллямел-голүм» трактаты.

[82] *«Тәһзиб»* – Сәгъдетдин Мәсгуд бине Гомәр Тәфтазанинең (1322–1390) «Тәһзибел-мантыйк» әсәре; *«Мулла Җәлал»* – Җәлаледдин Дәввәнинең (1426–1501) «Гакаидел-гыйздийә» исемле хезмәтен шәрехләп, гарәп телендә язылган китап; *«Тәүзыйх»* – «Тәүзыйхел-ысул» исемле, фикъһ буенча гарәп телендә язылган әсәр; *«Тәҗрид»* – хәдис гыйлеменә багышланган хезмәт.

заһирән вә батыйнән мөҗаз улган хәзрәти ишане камил вә мөкәммәл Галимөхәммәд Сәйфулла угылыдан вә кийәве Шәмсетдин Рәхмәтулла угылыдан тәхсыйле гыйлем идәрәк, Бәчек карйәсендә имам улуб, берничә мөддәт тәгълимес-сыйбийан идәрәк, бу рисаләне тәэлиф әйләдем.

Үземез һәр фәндә дәресне ишетүб вә биззат дәрес[кә күңел] салуб укыдыкымыз шөрякә бәйнендә әзһәре минәш-шәмсдер.

Ләкин, фәкыйрьлегемез өчүн, мәдрәсәдә күп заман карар идәлмәйүб, бер фәннең ишарәсеннән бер гыйбарә гокдәсен әгълял итдүкемез өчен хиссән мөтәнәдде[м] булынуб, нәфсемез җиһад мәртәбәсендә сакылмышдур. Ишаратес-сагатьнең нәмүнәсендәндүр ки, хак сөйләйән адәмне капуларыннан сөрәрләр.

Бу рисаләне «Мөнтәхәбет-татар» дәйү исем вирмешәмдүр ки, татарлар әхвалендән вә шөгъбәсендән бәхәс идәр, лөгать вә тәварих вә иске сүз вә иске авылларның әлфазләрендин фәһем идәрәк тәхкыйкат идәрез. Салих вә сәламәтмез вакытда халык берлә сүзләшүб йөрдекемез сүзләр ки, әмма сүземезне һәр дуст-иш бик тә фәһем идүб, мәхзуз улурлар иде.

// (*27а кәгазь*)

## Татарларның дәрес нәүбәте (вә чираты вә кизүе) ошбу рәвешчә

Әүвәл – әлиф-би сабагы, соңра – иҗек сабагы, соңра – сүрәдүр.

Иҗек дигән сүз гарәбидүр, асылда «һиҗәк»дүр ки, кәлимәләрне һөҗа вә тәһәҗҗи идәрәк укылур димәкдүр. Асыл кәлимәнең хәрәкәт вә сөкүн вә тасхихел-хөруф кәлимәне әйдек. «Һиҗәк» вә «иҗек» асыл кәлимәне ихраҗ идәр.

Бу иҗек гарәбдә лөгать вә хәреф вә мизан мәсабәсендәдүр.

Иҗек гамәле төрки улдыгы җәһәтилә асыл татарлар ихтирагъ вә ибдаг итдекләрдүр. «Сүрә» димәкләре кәлимәләрне игъраб бирүб, тәнзыймән вә тәртилән укымакдур.

Соңра – әбҗәд укурлар. Әбҗәдне вә һәм сүрәсен.

Вә дәхи «Иман шарты» укурлар, ижекне вә һәм сүрәсене.

Вә дәхи Һәфтийәк, ижекне вә сүрәсене. Вә төрки китаблары: «Бәдәвам», «Тәкый гаҗәп», «Башлагали», «Мәрйәм ана» китабыны.

Вә дәхи Кәлям шәрифне сүрә кыйлуб укурлар. «Йосыф» китабларыны, вә «Бакырган» китабун, «Сөбател-гаҗизин» вә башка төрки рисаләләрүн тапканча укурлар.

Кәлям шәрифтән соңра укурлар гарәби вә фарси китаблары: «Йәк хикәйәт», «Хәмде би хәдд», «Морадел-гарифин», «Дөррел-мәҗалис», «Бостан»[83], «Гөлстан», «Мәҗмәгыль-ләтаиф»[84], «Дәкаикыль-әхбар», «Тәгълимес-саләт», «Шөрутес-саләт» вә башка гарәби вә фарси китабларны.

Әгәр дә күб укыйачак булмаса, «Мөхтәсар» вә «Сагълүк» укуб, мәдрәсәдән чыгарлар.

Вә әгәр дә күб укыйачак улсалар, монла[р]ны көллисене укуб, сарыф укурлар, сарфави «Шәрхе Габдулла», «Кавагыйд», «Тәркиб», «Әнмүзәҗ», «Кяфийә», «Шәрхе мулла». Бәгъзесе монда һәм туктаб калурлар.

Вә дәхи укурлар «Исагуҗи», «Мулла Садыйк», «Шәмсийә», «Гакаид», «Сөллямел-голум», «Тәһзиб», «Хикмәтел-гайн», «Мулла Җәлал», «Тәҗрид» вә «Тәүзыйх» вә «Тәлхыйс» вә «Мотаувәл». Хәтеме көтеб мәртәбәседүр.

// (*28а кәгазь*)

Болгар вә Казанда улан мөтәнәүвигъ
татарлар хакан таифәсендән улуб, җөмләсе әтракел-мөхтәлифәләрдүр вә замане сәгадәтдә дине ислам берлә мөшәррәф улдыкларун игълам идән мәдлүл ләүхел-мәзар фи арзыйль-хәзәр минәл-болгар. Хакыйкател-Болгар әл-хакан әт-татар вә хакыйкатет-татар мин әтракь фи рәсмил-әхҗар рисалә[се]дүр

[83] Кулъязмада: «Гөлбостан».

[84] *«Мәҗмәгыль-ләтаиф»* – хәдисләр җыентыгы.

Мәдлүл ләүхел-мәзар әл-мәтрүк фи корбәти карйәтил-хәзәр (вәл-хәзәр)[85] мин арзыйль-Болгар вә хакыйкател-Болгар әл-хакан вәт-татар вә хакыйкатет-татар мин әтракь би-рәсмил-әхҗар әл-мәктүб би-рәсмил-Бәгъдад вәл-Госманийә вә көллүһүм мәктүб фи тарихи мийәтит-тисгыйә вәс-сәманийә

// (*28б кәгазь*)

Куснар катында Мартын[86] чуашы авылы Зиршир зийаратында мөселман ташы йазылган. Бик начар йазу: «Меңдә йөздә» диб, башкасы беленмәйдүр.

Нирсир (Җеншир, Йаншир, Шинзир дийәрләр), Мартийан дийәрләр. Җен шәһәре, Зиншәһәр, Шинзәр, Йершәр, Ир шәһәре. Суы – Шуршу, Шуршәр, Акшәһәрдүр. Акчура – Акшура хандур.

Сур суы, Шур суы – Ак су. Акчура – Акшура. Чура, Шура – икесе бер мәгънәдә, «ак» мәгънәсендә чуаш вә төрки лисаны үзә.

Йәгъни Мартийан авылы катында мөселманлар каберләр[е] күб. Бер ташда йазылган «меңдә йөз» диб. Ике сәтырдур.

Шул зийарат йанында бер шәһәр вардур – исеме Акшәһәр булса кирәк. Чөнки авылы Шуршәр зийаратыдур. Суыны Шуршу диб әйтәләр. Чуашча Аксу вә Акшәһәрдүр. Һәзәр шәһәре (Хәзәр шәһәредүр), хакан, һәзар шәһәредүр.

Һәзәр шәһәре, шәһәр вә халкы.

Йәки Зәршәр – Зәршәһәрдүр, замане әүвәлдә хәраб булмыш хәзәр шәһәредүр.

Йәки Зуршәр – Зур шәһәрдүр.

---

[85] Кулъязмада «хәзәр» сүзенең берсе «зә», икенчесе «зәл» хәрефе белән язылган.

[86] *Куснар* – хәзерге Чувашстан Республикасының Козловка районындагы авыл (рәсми исеме – Байгулово); *Мартын* – шул ук райондагы Мартыново (Йершер) авылы, XVIII гасырда Преображенское (хәзерге Аттиково) авылы крестьяннары нигезләгән.

Билыйби авылында кала бардыр, Борындук басуында. Каласының исеме Бузай йәки Акби йәки Белыйби каласыдур. Борындык, Шуширмә, Карашәм, Наратлы, Әҗәле, Танай, Мамадыш, Ышналыбашы үзә гашир булган.

Кири авылында кальга – Кошман (вә Бәһрә) каласыдур. Хуҗаш, Ачасыр, Исхак авылы (Исакува), Данайча (Таныча), Каинка (Кайыннык) авылларының гашире булган.

Өткәкдә[87] калька, бәлки кечкенә кальгадур. [*Гарәп телендәге өземтәнең мәгънәсе: «Хәзәр иленең һәм Җәбәлелфәтехнең җире киң, анда хисапсыз төрле төрки халыклар яши һәм патшалыклары да төркинеке, Искәндәр төзегән диварга чиктәш»*].

Тәварих китабларында мәзкүр улан хәзәр биляденең башлычасы Казан мәхкүматында Чабаксар кальгасенең зире идарәсендә улан Бугурудыски булыс корбендә Зәршәр авылының басуында улан шәһәр – Зәршәрдүр. Йәгъни, Хәзәр шәһәре димәк улур ки, һәзар, хакан падишаһының бәләдедүр.

Чуаш, мишәр вә төрек лөгатендә «ха» берлә «һә» арасында тәфрика йукдыр, тәләффезән бердүр, хәзеф берлә сүләрләр.

Зәршәр – һәзар (вә хәзәр) шәһәредүр.

Турхан – субашы булуб, Төрләмәс авылы булган хәзерендә.

***

// (*29а кәгазь*) «Албагут» – мөбариз мәгънәсендә («Кыйсасел-әнбийа» рисаләсендә, вәрәкъ 63)[88].

Чуашча «алпаут», татарча «алпавыт». «Алып бока ат» йәки «алыб бу ад» – магул лисаныдур («мангул» әйтеләдүр).

«Чәрик» – гаскәр мәгънәсендә, магул лисанында. Чуашча «чер» дийәрләр. Татарча «чирү» дийәрләр.

Чуашча «йарвых чиру» дийәрләр, иске тел – «сыру» (сирү)

---

[87] Өтәк атамасының иске телдәге яңгырашы, ихтимал, шулай – Өткәк рәвешендә булгандыр.

[88] Бу мәгълүмат 1859 елда басылган китапка туры килә: Кыйсасы Рабгузи. – Казан: ун-т табыгханәсе, 1859. – Б. 63.

дүр. «Сиры» – «сөрйани» дигән сүз, йазудур.

***

// (*31б кәгазь*) «Татар» дидекемез сүз татарча «татар»дур, әмма гарәбчә «тәтәр» дийәрләр бу заман. Иске китабларда гарәбчә «татар»ны «болгар халкы» вә «хәзәрийан», бәгъзе ривайәтдә «сәкъләб» диб әйтүче бардур. Фарсы халкы һәм үзбәк «болгар-татар» дип әйтүрләр, йәнә сарт (Бохара шәриф халкы) – «үзбәк» вә «нугай» вә «татар» диб әйтәләр. Төркмән-Хива халкы «нугай» вә «татар» вә «болгар» халкы диб әйтәләр. Сарт (Кукан халкы вә Ташкәнд халкы) ушандак «нугай» вә «татар» вә «Казан татары» дийәрләр.

«Татар» ләфзы бик кадими ләфыз улуб, изафи мәгънәсен белмәк мөшкилчә улуб, берничә ихтималате мәзнунәләр улса да, лөгать вә тәварих китабларында исем вә гыйлем мәгънәсеннән башка ифадә булмайуб, бер вилайәткә исем улмакун ишгар итдүкләрендин мәгънәи махсуса галәмә вилайәт мәсабәсендә улуб, замане кадимдә бер кешегә исем вә бер таифәнең исеме улуб, мөрүрез-заман илә әүляде кәсирәсе хасил улуб, таифәи махсусаи мөтәнәүвига вә бер җәмгыйәте газыймийә тәшкил идүб, әтрафе галәмә мөнтәшир улдукларындин, кә-әннәһү, татарлар ныйсфед-дөнйа вә ныйсфе көррәи арзы ихата кыйлдыклары мәгълүм улуб, Татарстане кадимдән зоһур идүб, мугул вә Асийаи вөста халкы вә Кашкар вә Кукан-Хакан вә Тибет, Төмән, Һиндустан, Чин вә Мачин[89], Әфганстан, Уган вә Катаган вә Билуҗистан вә Төркестан, Туран вә Көрдестан вә Госман-стан вә Болгарстан татары вә Кабкасдан та сәдде йәәҗүҗ вә

---

[89] Кульъязмада төп текстның шушы юллары арасында автор тарафыннан дүрт юллы шигъри парча карандаш белән язып өстәлгән:

Баба Мачин ул солтан,
Мөрид булды бигөман.
Мөрид булды сансыз төмән
Остазы шәйх Әхмәд Йәсәви.

Бу дүртьюллык Сөләйман Бакыргани шигыреннән. Өченче һәм дүртенче юллары Бакырганида бераз аермалы.

мәэҗүҗ уларак, берничәсе Америкаи шималинең әкъсасы улан иңлизләр мәмләкәте корбе әрканҗиле җәдид тарафларына интишарлары мәфһүмдер ки, Сибирийә тарафларының әкъсаи шәркы улан Берингоф бугазындин чыкуб, мәзкүр Америкаи шимальнең иттисале мәзнун вә мәфһүм улдыгындин Америкада халыкның кәсрәте вә бу бер гатикъдан адәмзадә хоруҗе улдыгы йакыйн мәсабәсендә бер мәгънәдүр[90].

Арыз көррәиш-шәкелдер ки, җуграфийун вә йунанийун вә бер парә хөкәмаи исламийун тәсрыйх кыйлмакдадур – хөҗҗәтел-ислам кеби. Иштә татарлар җәмгыйәте мәзкүрә улуб вә этрафе галәмә интишарларындин күп такым вә нәселләр көлли шәгъбәләре улуб, ибтидаән татарлыкны белмәк бик мөтәгайир исә дә, иске тәварих китабларында улан хикәйәт вә татар ләфзынең маддәсе лөгать китабларындин аларак вә Казан татарларының бик иске гөй вә карйә вә авылларының исемләрендин вә бәгъзе әлфазе кадимәдән татарлыкны белдекемездин соңра, татарларның кәсрәте вә нәселләрен вә татарлыкны бәйан мөмкин. Әһле гыйндендә йакыйнийат вә әүвәлийат кабилендә улан мәгънәдүр ки, зоһуры әзһәре минәш-шәмсдер.

Иштә татарлар әнвагы лөгать вә әнвагы әлбисә вә әнвагы мәскәнә вә пик мөтәнәүвигъ әшкял вә сурәтләр пәйда идүб, вә төрле мәмләкәтләргә мөсафәрәт вә мөҗавәрәт вә бик сәйәхәт идүб, әҗнәбләрдән әлсинә вә әлбисә вә әшкялләрене тәбдилән әхәзгә татарларның табигатьләре бик мәййәлдүр ки, җәмгыйәте мәзкүрә бади нәзардә бу заманда булган татарлар кадим заман татарларына пик әҗнәб халәтдә вә әшкялдә улдыгы мәфһүм улмакдадур.

---

[90] Авторның Беринг бугазы аша Төньяк Америка кыйтгасына борынгы төркиләрнең таралган булулары турындагы сүзләре игътибарга лаек. Аның бу фикере, күрәсең, рус матбугатыннан (ихтимал, «Гатцук газетасы»ннан алынгандыр. XIX гасырда яшәгән Америка галиме Отто Геригның, төрки телләр белән индеецларның телләре арасында шактый уртаклыклар табып, соңгылары борынгы дәверләрдә Азиядән күченгәннәр дигән фикергә килгән булуын сүз уңаеннан искәртик. Бу хакта галим Әбрар Кәримуллин язган иде (*Каримуллин А. Прототюрки и индейцы Америки: по следам одной гипотезы. – М.: ИНСАН, РФК, 1995. – 80 с.*).

// (*32а кәгазь*) Җәмгыйәте мәзкүрә вә татар бер такым тәбдил вә тәхриф булмайан таифәләренең әлбисә вә лисан вә г[адәт]ләрендин вә мәскәнәләрендин фәһем идәрәк, татарлар кадим замандин бирле лөгатьләрене вә әшкялләрене тәбдил вә тәхриф идәр улдыклары кәндүләренә тәбдилят вә тәхрифат вә тәхвилат улдыгында. Мәсәлән, Болгар замане сәгадәтдин соңра вә каблә бер белгән тәбдилийәт вә тәхрифат бер заман Искәндәр Руми (бөтен дөнйага мәшһүр, белмәйән кеше улмас) румилар вә башка тәваифләр берлә килүб, Болгар вилайәтләрене Ибраһим галәйһиссәлам динендә кыйлуб киткәндер.

Вә соңра Хытайдан Чингиз хан истиля иткәндер вә соңра гарәбләр, дәхи Бәгъдад, Гыйрак төрекләре истиля идүб киткәнләрдүр.

Вә бәгъдә Аксак Тимер истиля бөтен Болгарны гадәм идүб, халкыны һәлак идүб киткәндүр.

Бәс Болгар вә Казан вилайәтләрендә әнваг нәсел вә лисан булурга кирәк булса да, әнваг нәсел татарлар эчендә мәркүз вә мәдхүл улуб, вилайәтләре әл-йаум кәл-гадәмлеген сирәт вә һәйәтләрендин беленәдүр.

Вә дәхи Казанга Москва истиля иткәндүр 961 сәнәи һиҗрийә илән. Русийәдән качуб вә посуп калдык татарлар тәдриҗ-тәдриҗ Казан халкына ихтилят идәрәк вә кыргыз халкына ихтилят идүб, Асийаи вөста халкы саф мөселман улдык җәһәтилә күзләренә бик йахшы күренүб, Ташкәнд вә Кукан вә Сәмәрканд вә Бохараи шәрифтә әнваг голум вә тәдрис куәтле заман вакыт вә Хива вә Үргәнеч мәдрәсәләрендин тәгълим алуб, төрле-төрле фәннәргә маһир вә остад уларак Казан вилайәтләренә кайтуб, нәшре гыйлем вә тәгълим иткәнләрдүр.

Безнең Тау йагы үзә Каргалыда Вәлит ишан[91] хәзрәт-

[91] *Вәлит ишан* – үз чорында «Каргалы Вәлид ишан» дип танылган, 1802 елда вафат булган Вәлид бине Мөхәммәтәмин Җәбәли әл-Кайбычи. Тумышы белән Кайбыч авылыннан булып, Дагстанда һәм Бохарада белем алганнан соң Оренбург янындагы Татар Каргалысы авылында имам һәм ишан булган. Бу шәхес Ш.Мәрҗани һәм Р.Фәхретдин хезмәтләрендә югары бәяләнгән.

ләрендин вә башка хәзрәтләр мөселманлык галәимләрүн күп нәшер ителгәнләрдүр. Әүлийалар рөхсәте вә иҗазәте руханийәсе берлә. Йукса Тау йагы тәмам чуаш халкы кеби каралуб калган икән.

Тау йагының татар вә мөселманларының кар[а]лыклары бу заманда бик мөшаһәд күз алдында – гыйбадате малийәдә бик тәкясел идеб, дүрт йөз йыл җәһаләтдә калмыш чуаш таифәсе күк. Чуаш кеби малга бик мәхәббәт илә зәкят вә гошерне әда итмәйләр. Хәтта күбесе зәкят бирмәк вә гошер бирмәкне хәрам беләләр, бәгъзесе алай-болай хәйлә кыйлалар, садака бирмәкне «акча беткәч зарар буладыр» дип, бирмәйләр. Ислам әсәре бик зәгыйфьдүр.

Казан җирендә вә Уфа вә башка йахшы мөселман татарлар гыйбадате малийә бирмәктә вә башка исламийун гамәлләрендә мөҗтәһидләрдүр, сәһелчә вә ихлас берлә идәидә килгәннәрдүр. Бу тәбдилат вә тәхрифат бу заманда күб.

Мәзкүр Казан татарлары Асийаи вөстага ихтилят вә тиҗарәт вә мөгамәлят кыйлмак берлә вә Асийаи вөста халкының лөгатьләре берлә тәкәллем идәрәк, шимдики заманда Казанда вә әтрафында улан татарларның әксәре Асийаи вөста вә Госманийә лисаннары берлә тәкәллем идәләр[92]. Вә Казан җирендә, хосусан, Асийаи вөста теле берлә тәкәллем идәләр мулла, галимнәр вә хаҗбабалары вә диндар адәмнәре вә башка укыган кешеләре. Әмма гавам халкы әксәрийән Русийә лөгате берлә тәкәллем идәрәк, мәләкә хасил идүб, кәндү бабаларындин калган лисан вә лөгать кеби, әҗнәб лөгать икәнен белмәйәрәк, ихлас берлә тәкәллем идәр адәмләр күбдүр.

Казан татарларының иске сүзләре вә авыл исемләре вә иске кийем исемләре вә савыт вә саба исемләре башкорд вә кыргыз вә чуаш вә чирмеш вә мукшы вә ар лөгатьләре берлә кә-әннәһү бер фәм мәсабәсендәдүр. Гыйбрәт ийәсенә [мәгълүм] – иске

---

[92] Кулъязмадагы юллар арасына язылган бер өстәмә өлешенең тиешле урынын тәгаенләп булмады. Анда болай диелгән: «улдыкларыннан вә кәндү җенесләрендән улмыш чуаш таифәсе айырылуб калуб, бер таифәи махсуса күрелмешдүр, нәгузү билләһи Тәгалә».

заманда Казан татарлары берлә чуашларның // (32б кәгазь) тел бер булган. Мәсәлән, иске кийемнәр исеме: *такыйа, калпак, бөркәнчек, каш, бучиңчә, чүбә, ак чүбә, бибеч, чирбик, нагышлы чүбә, җилән, чапан.* Казан татарлары бу кийемләрне көллийәтән кигәнләр. Хәзердә мөселман татарларның карчыклар вә картлары әйтә вә һакәза җәһаләттә калмыш татарлар нәүгысе улан чирмеш вә чуаш вә мукшы вә ар (ватәк) вә му[р]дв[а] – бер халыкларның кийемләрене кийәләр. Әмма хәзерендә Казан мөселман татарлары кимәйләр.

Ушандак Казан җирендә авыл, көй вә карйә вә авыл исемләре чуашчадыр: Караширмә, Икшермә, Орымширмә, Булчирма – Мишә суы буйында; Әтнә, Кавал, Каензар; Җырыкчирмә дигән ар авылы, Таузар Иле – Шушма[93] суы буйында. Чирмешләр булган Чирмешән суы буйында. Вә башка авыл (көй вә карйә) исемнәрендә борынгы исемләр күп – хәзер Казанның мөселман татарлары мәгънәсен белмәйләр – һәркайусы кеше исеме.

Борынгы тел: *мәскәнәләр, кош, салаш, йаулаша, канат алды, актана асты, анбар, сарай, өй, бура, чалак, китәк, сарача, кәҗәнкә, әҗәтканә, әбрәсханә, әбрәкәй, мәмәшҗул.*

Тау йагында хурлаб әйткән сүз «гыйҗот, алпан-тилпән, ыжгыт, алангыр» күк, «котсыз, котың чыккан икән, котсыз җиз» күк, «җүләр, сумбый, Кырым чирүе» күк күб. *Нәчә чакрым майыттамал, кисрән, тенкәм корыда, талигым җук, ыспай* (салмак кеше)*, кан заманында, мургыр күк, «әҗәт (бурыч) бирдем, карычга алдым», сөмсез* вә һакәза тәгъбират чукдыр. Мәсәлән, «чүбә» дидеке ләфыз «сәүбә» булса кирәк, «нагыш» дигән сүз «нәкышь» дигән булса кирәк. «Бибеч» дигәне сүз «папуч»дыр, лөгате госманийәдер. «Чирбик» дидеке сүз «чадук»дур, лөгате госманийәдер. «Җынылан» дидеге сүз «чи илән» дигән сүздүр – саф татардур. «Әҗәтканә» дигән сүз «хаҗәтханә» мәгънәсендә.

Татар, чуаш телендә фарсый һәм бар, «гыж» дигән сүз – «Гуҗ» булса кирәк.

[93] *Шушма* – хәзерге Татарстанның төньягындагы Шушма елгасы күздә тотылган.

«Алгаз» дигән сүз – гарәби «әлгаз»дыр. «Алпан» дәйү сүз – «алыблар» дигән сүз. «Ыҗгыт» дигән сүз – «әз гъад» дигән сүз.

«Алангыр» дигән сүз, «алан» – мәмләкәтдүр, халкы һәм аландур. Санкт-Петербург каласының әтрафлары Алан дигән җир булса кирәк, «Алман, Алакан, Алманийә» дип әйтәләр, Балтыйк диңгезене «Аламан диңгезе» диб. Питербурх каласының әтрафындадур[94].

«Гыр» дигән сүз татар лөгатедер. «Хыр» дигән сүз, йәгъни батыр булып, үзен куркыныч коручы дигән сүз, татарның «мургыр» дигән сүзеннән беленә. «Мур» – халыкның исеме, «гыр» – «кырмак» мәгънәсендә. Болгара чуашча «мурхыр» диб әйтәләр. «Мыргыр», «Муркыргыр» дип әйтәләр. Амур мөхәффәф Амур суы буйындан килгән халыкдур, болгар вә татардур.

Болгарның әтрафында улан хәляикъ чуаш, чирмеш вә мукшы вә татарлар вә башка, вә мишәр, вә төмән, башка хәляикълар һәммәсе бер нәүгъ – асыл төрк шөгъбәсенә раҗигъ вә татар итлакына раҗигъ улалар. Әмма татарлык-төрклек, урыслык, франсуслык вә башка таифәлек асыл нәсәбнең шөгъбәсене хикәйәт улуб, һичбер дингә тәгаллекы улмадыгы әсхабел-гыйлем, әрбабел-лөгать гайнендә әҗәлли мин әл-фәхердер.

Бәгъзе дүн кемсәнәләр мәзкүр гонван илә үзләрен мәгънәган идүб вә тәфахир вә тәкәббер идәрәк «мин – татар» дийәр. Һәйһат! Татарлык ләфзындан мөселманлыкның вөҗүде мөселманлык тәсдыйк бил-җөнан вә икърарe бил-лисан улыб, хариҗи ислам гамәлләр булса, һәрнә таифә саддендә улыб вә кәсеб идәрәк хасыйл кыйлса, тәхкыйкан ул затны «мөселман» дийәрез. Кирәксә урыс улсун, кирәк франсус улсун, кирәксә гарәб улсун, кирәксә татар улсун вә кирәксә чуаш улсун, шулкадәр вар ки – Русийә халкын «татарин» мотлак әйтсәләр, мөселманлыкны морад кыйлуб әйтәләр. Үз мәмләкәтләренә

---

[94] Кәгазь читендә автор мондый искәрмә язган: «Питырбург катында улган диңезне Аламан диңезедүр («Гаҗаибел-мәхлукат» китабында) вә халкы «алан» – виланд халкыдур, Алманийә дийәрләр».

мәнсүб улан Казан мөселман вә Болгар тәвабигъларына мөселман һәйәтендә бер кеше күрсәләр – «татарин» дип итлакъ итдекләрендин фәһеме касыйр адәмләр тәхкыйк вә тәдкыйкдан башка «татар» ләфзына җәзмән «мөселман» мәгънәсен бирделәр. Бу тәглыйт вә тәхлыйт итмәкдүр[95].

Максадел-асыл – татар маддәсе вә татар барча нәүгысе илән дине исламны кайу замандан бирле тотадыр? Татар таифәсе [әүвәл] заманда кайу җирдә булган? Вә Казан татарларының барча шөгъбәсе улан таифәләрне хәзер әйтәмез, инша Аллаһу Тәгалә.

// (*33а кәгазь*) Татарлар кадим заманда Хытайның шимали вә шәркый тарафларында бер мәмләкәте нөфүз, халкы һәм татардур. Мәшһү[р] Амур суының мохыйте шәркый вә Татар бугазына койдукы җирләрдә бигрәк мәшһүр харита вә җиһаннамә вә һәйәте арзны йаздыкларында Амур суы тарафларыны вә Камчат халкыны ихата идәрәк күстәрәләр. 1876 сәнәнең «Гатсук» газитенең[96] 23 нче нумерында йазылмыш һәм шөйлә дәйү.

Күчеб йөрделәр, гун вә авар, мунгул. Татар һәм төрк халкы чыкмышлар Асийәнең эчендән – күбрәк Себер йагындан, Себер Асийәсендән. Соңра Асийәи вөстага килгәнләр, Бактарийанга[97]. Андан фарсийан Асийасына, андан Йаурупага чык-

---

[95] Бу кәгазь читендә язылган ике өстәмәнең төгәл урыннарын тәгаенләп булмады. Аларда болай язылган: 1) «Вә хәзрәти Адәм галәйһиссәламнең баласыны бер мөгаййән исем берлә вә гонван берлә замане зоһурны вә мәүзыйгы тәгайен мәнзилә улуб, һә...» (кәгазьнең чите таушалган булуы сәбәпле, бу урындагы берничә сүз җуелган); 2) «Вә хәзрәти Адәм дәрйаны фәләнчә исемдә вә мәүзыйгда зоһурның хикәяте улуб».

[96] *«Гатсук газите»* – танылган археолог, публицист һәм язучы Алексей Алексеевич Гатцук (1832–1890) мөхәррирлегендә һәм наширлегендә 1875–1890 елларда Мәскәүдә чыккан атналык, бизәлешле басма. «Крестный календарь» (православие диненең чиркәү календаре) кушымтасы буларак чыга башлаган әлеге басма 1875 елның 43 нче санынnан «Газета А.Гатцука» исеме астында нәшер ителгән һәм үз чорында шактый популярлыкка ирешкән.

[97] *Бактарийан* – хәзерге Таҗикстан, Үзбәкстан һәм Әфганстанның чиктәш өлешендәге борынгы (безнең эрага кадәр 2500 елдан алып безнең эраның 900 нче еллары) тарихи өлкә; Бактрия.

мышлар сигезенче йөз руми эчендә, Йаурупага чыкмыш урыс сахрасындан сигезенче йөз руми эчендә.

Ибраһим Хаккый «Мәгърифәтнамә» китабында йәэҗүҗ вә мәэҗүҗ бәйанында «Анлар Татарстане кадимнең ма вараэсендә» димеш.

Көррәи арзның һәйәтене китабәт идүб, Сибирийә тарафларының җәнүби шәркыйсе улан вә әкъсаи Сибирийә улан Амур суының шимали тарафына йазган «Татарстан» диб.

Тәварих китабларында вә фетнә бәйан кыйлдукы китабларда татарларны «сәддел-әсгарь әл-Искәндәри вә мокаддимәи йәэҗүҗ вә мәэҗүҗ» диб йаздукларындин җәмгыйәте мәзкүрә татарлар кадим заманда мәшрикъдә улуб, бу Казан, Болгар вилайәтләренә мөрүрез-заман вә Нух галәйһиссәлам заманыннан соң мөнтәшир уларак, Болгар вә Казанда уланлары һәм әнваг лөгать вә лисанлар илә тәкәллем идәләр[98].

Алат йулы татары, Гәлеч йулы татары, Арча йулы татары вә Җөри йулы татары вә Нугай йулы татары бәйнләрендә тәфавет бик күб телләрендә.

Алай да күп фән вә китаб вә тәҗрибә ийәсе садә, саф татарны бик сәһелчә белә, анларның әнвагы көллисе илә тиз заман тәкәллем идәргә буладур[99].

Татар маддәсе пәйгамбәр лисанына һәм вакыйг булып, бойурмышлар – «татар – Сәгъд вә татарда булыр» дип. «Сәгъд» – Табарри китабының бәйанына күрә, Сәмәрканддер.


«Татар» – бер бик хуш исле хушбуй җөмләсеннән, кәфур кеби, татар – ганбәр кеби мәшһүр хушбуйлардур. (Бу сүз «Алты бармак» китабында мәзкүрдүр).

Сәгъд вә татар – арзы мәшрикъда улдыгы мәшрух улдыгындан, татарлар кауме мәшрикъдан зоһур идүб, әтрафе

---

[98] Кульъязмада текстның бу урынында мондый җөмлә өстәлгән: «Шөйлә ки, адәмләр бер җенес Адәм галәйһиссәлам әүляды булуб Һиндустанда булсалар, төрле-төрле исемдә булуб, төрле урындан зоһуры килмешләр булган».

[99] Бу җөмләнең ахырында язылган «кәнде нәфсемнән мөшаһәд» дигән сүзләре авторның үзе тарафыннан сызылган.



*Кулъязманың 32а кәгазе*

галәмә мөнтәширдүр. Хәтта Йапунийә вә Америкаи шимали тарафларында улдыгы мәзнун улуб, Йапунийәдә татарлар нәүгысе дине исламда вә мәзһәбе шафигый үзә улдыгыны равилар күбдүр. Әрбабед-дәүләт хезмәтендә улдыгы шәкерт вә галим кемсәнәләр әйтәләр.

«Тәнбиһел-гафилин» китабында Әбүлләйс әс-Сәмәрканди йазмыш пәйгамбәремез саллаллаһу Тәгалә галәйһи вә алиһи вәссәлләм бойурмыш: [*гарәп телендәге өземтәнең кыскача мәгънәсе: «йөз илле кавем яәҗүҗ-мәәҗүҗләр тәмугда янар. Илле төрле халык: румнар, хәзәрләр, сәкъләбләр ... Һиндстан, хәбәш, мәгърибләр, көнчыгышта алты халык: төрки, хакан, гуз, тогр, кимәк, йемәкләр җәһәннәмнән имин булыр»*].

Бу сүзнең бәйаны, инша Аллаһы Тәгалә, бу мәнвәл үзәдер – төрк күп таифәләрә моксыйм улсалар да, хакыйкатьләре мәшһүрдүр. «Хакан» дидүкләре – Кукан халкыдыр (мәшһүр вә мәгъруф сүз). «Вә гуз вә тогр» дидекләре – кыргыз халкы булса кирәк. Вә башка өч таифә татар нәүгълары улуб, чуаш вә чирмеш вә мукшы кеби, монларның башлычасы мәзкүр төрк улдыгындан төрк вә татар бер шөгъбә вә бер нәсел улдыгы әзһәре минәш-шәмсдер. Мәзкүр хәдисе шәрифтә «сакъләб» маддәсене Румга гатыфындан «сәкъләб» халкы румийанга башка[100] // *(33б кәгазь)* бер таифә улса да, «Укйанус» китабында (вәрәкъ 6) «әс-сәкъләб», «сәгъләб» вәзенендә, румийанның бер фиркасе улдыгы мәшрухдур ки, бер рәҗүл исемедүр вә насдан бер женес таифәдер. «Төрки» вә «гарәби» кеби нисбәттә «сәкъләби» дийенүр. Җәмгы «сәкалибә» кәлүр, буның мәшһүре «сәкалибә»дүр ки, сад мөһмәлә иләдүр ки, «рус» илә мөтәрҗим мәгънәләрдүр ки, «сакъләб» маддәсендә мәрсүмдүр. «Укйанус» (вәрәкъ 8): «Әс-сакъләб» – садның фәтхилә бер кавем махсус адыдыр, дийарләре Болгар мәмләкәте илә Кастантинийә бәйнендә, биладе Хәзәр илә һәмнәварләрдүр».

Көтебе жуграфийәдә «сакалибә» – ләһ, поляк, чеһ, нимеч,

[100] Кулъязмада «румийанга башка» гыйбарәсе ике мәртәбә – 33а кәгазьнең ахырында һәм 33б кәгазьнең башында кабатлап язылган.

венгрус биладилә мөбәйәндүр. Ки халән әфляк вә бугдан вә дәхи ул өлкә дахиленд[әд]үр. Вә бәгъзе көтебе җуграфийәдә «болгар» таифәсе улмак үзә мөбәййан вә сәгалийййәи йунани мәгъриби улдыгы мәшрухдур. «Рәддел-мөхтар» китабында[101] «вәфакыйду вакътиһима кәл-болгар» димеш вә «Болгар – бәлдәтүн фи җанибиш-шимали шәдидәтү әл-бәрди бәнәтһа әс-сакалибәти» димеш.

Йукарыда мәзкүр вәҗеһ үзә, сакъләб мөтәгаддид улуб, татарлар нәүгысендән бер кемсәнә исеме улуб, кадим заманда хөкүмәт ийәсе булдугындан Болгарны бина итсә – нә гаҗәбдүр.

Ләкин безләр – татарлар таифәсейез, бик хуш белүрмез ки, Болгар шәрифне татарлар бина итдекене.

Кадим заманда Болгарның хөкүмәте Кафказ тарафларындин алуб, Русийәнең Нижни каласына кадәр булуб, бәлки Русийә вә Мускау бер заман татарларның зире идарәсендә улдыгы Русийә халкының тәварих китабларында мәзкүрдүр. Нитәкки «Нисабел-интисар» китабында мәзкүрдүр: [*гарәп телендәге өземтәнең тәрҗемәсе: «Хәзәр иленең җире Җәбәлел-фәтех икълимендә. Ул җир киң, анда хисапсыз төрле төрки халыклар яши һәм патшалыклары да төркинеке, Искәндәр төзегән диварга чиктәш. Аллаһы Тәгалә Коръәннең «әл-Кәһф» сүрәсендә хәбәр иткәнчә, дивар яәҗүҗ-мәәҗүҗдән саклау өчен төзелгән. Иң имин кабиләләр: хәрхәр, кимак, җәҗҗән, эктәш, әтрәкс, болгар һәм башкалар. Сәедбаттал Газый «Төхфәтел-ләбаб» китабында болай дигән – Болгарда гъад кавеменең кешесен күрдем, ул 27 зирагтан (терсәктән) озынрак. Шул кеше атны, кечкенә сабыйны алган кебек кенә, култыгы астына кыстыра. Болгарның Башкорт дигән җирендә хәзер дә гъад халкы калдыклары бар. Болгар җирендә мөселман төркиләр яши, алар габбаси хәлифәләреннән әл-Мәэмүн һәм әл-Васикъ Билләһи заманында*

[101] *«Рәддел-мохтар»* – ислам диненең мәшһүр галимнәреннән Ибне Габидин (1784–1836) тарафыннан язылган «Рәддел-мохтар галәд-Дөррел-мохтар, шәрхи Тәнвирел-әбсар» исемле күптомлы хезмәт. Бу әсәр – хәнәфи мәзһәбенең фикъһ буенча иң ышанычлы хезмәте.

*ислам динен кабул иткәннәр һәм әл-Каим Би-әмриллаһ вакытында яңартканнар 30 мең сыркәү төрки кабиләләр. Сыркәү – төрки телендә ир-ат җәмәгатеннән кардәше, агасы, балалары – барлыгы 100-дән 1000-гә хәтле. Солтан Сәбектәгин вакытында ислам динен кабул иткәннәренең хисабы юк (бик күп). Төркиләрдән ислам динен кабул итмәгән имансыз-кяферләрен үтергән. Кайбер хәкимнәр «Җәбәлел-фәтех»нең зурлыгы 12 мең фәрсәх дигәннәр. Аның шәһәрләреннән Сәмәндәр каласы руслар тарафыннан җимерелгән. Һәм андагы Болгар шәһәре һәм җире «Җәбәлел-фәтех» мәмләкәтеннән ике тапкыр киңрәк. Кыш вакытында болгарларда һәм русларда көннәр өч мәртәбә кыскарак була. Имам әл-Хәүкәли Болгардагы кыска төннәрнең намаз вакытына тәэсире турында искәрткән»*].

// (*34а кәгазь*) Әсхабе җугърафийун вә тәварих әрбабе Болгар халкына «хәзәзийан» диб әйтәләр. Хәзәзийан таифәсе хакында Табарри китабында йазмыш: әмирел-мөэминин хәзрәти Гомәр заманында хәзрәти Могавийә[102] Шамда вали булуб Габдеррахман сахабә берничә гарәб гаскәре берлә Кафказ тарафына йибәрмеш. Анлар галәбә идәрәк, олуг сәддләрне кичүб, Дәрбәндләрдән чыкуб, хәзәзийан таифәсе илән сугышкә хәзрәти Могавийә изен вә фатиха алуб, хәзәзийан таифәсе илә ничә кәррә җәң идүб вә галәбә идәрәк, Турхан падишаһның колакына дөшмеш[103] (мәзкүр Турхан хәзазийан таифәсенең олуг баш вә падишаһлары иде. Мәҗүси иде, дуңгыз вә кәлб йийәр иде, вә гараку вә буза эчәр иде). Хәзрәти Могавийә әмере берлә Габдеррахман сахабә Турханга галиб улуб, әһлене вә каумене ислам вә өммәте Мөхәммәд әйләмеш.

Турхан ни мәүзыйгда булганун без хәзер белдүк – Казан мәхкүматындин вә Чабаксар дидеге кальга зире идарәсендә улан Тау йагының чуаш таифәсенең Төрләмәс дигән көй вә карйә

---

[102] *Могавийә* – 661–680 елларда өмәвиләр хәлифе булган Габдрахман Могавия ибне Әбү Суфиян әл-Өмәви әл-Кораеши (680 елда вафат).

[103] *колакына дөшмеш* – бу гыйбарәнең төгәл мәгънәсен ачыклап булмады. Һәрхәлдә, ул «башына җиткән» дигән мәгънәгә туры килә дип чамаладык. Ихтимал, шундый фразеологик әйтем булгандыр.

вә бәләднең басуында Турханның мәүзыйгы бардыр, чуашлар «Турхан пасуы» дип әйтә. Анда сугыш булган дип әйтәләр[104].

Бу сүздән беленде, мәгълүм булды – кадим заманда чуашлар таифәсе мөселман булганнар да, мөрүрез-заман берлә йәнә мәҗүслеккә кайтуб, йалгыз бер таифәи махсусый күренәләр. Йукса, Казан татарларының бик иске телләрендин вә Тау йагы татарлар[ы]ның лисан вә лөгатьләрендин бу заманда булган чуашларның лөгате, кә-әннәһү, бер фәм мәсабәсендәдүр.

Казан татарлары лисан вә лөгатьләре Асийаи вөста вә госманлы лисанына мәйл иткән. Анлар качуб вә посуб мөселман булып калдукларындин, чуаш таифәсе мәҗүс булып калуб, берничә урус лөгать үзә мәйл иткән. Нитәк бу заман татарларның гавамен-наслары ныйсьф лисаннары русидыр, урыс йарты теле татарчадыр. «Айда базар» дип әйтә урыслар, урысча кирәк «пойдём рынок». Мәсәлән, татар берлә мишәр – мөҗанис, вә мишәр берлә төмән – мөҗанис, вә төмән берлә типтәр – мөҗанис, вә типтәр берлә башкорт – мөҗанис, вә башкорд берлә кыргыз – мөҗанис, вә кыргыз берлә чуаш – мөҗанис, вә чуаш берлә чирмеш – мөҗанис, вә чирмеш берлә мукшы – мөҗанис, вә мурдуба берлә ар – мөҗанис. Монлар һәммәсе әтраке мөхтәлифә вә әкраде мөхтәлифә вә гъад кавеме нәүгысе улдуклары татарлар арасында иске сүз бар – «алыблар заманы» вә «хан заманы». Бәгъзе чыкуб торган җирләрне әйтәләр: «алыб чабата каккан җир» диб вә һәм җирләрдән бик зур хайван сөйәге дә булмас, шулкадәр зур бот сөйәкләре чыка. Алыбны татарча «гыж» диб әйтәләр вә «алпан-тилпән» диб әйтәләр. Болгар вилайәтләрендә хәзрәти Адәм заманындук кешеләр барлыгы беленәдүр. Болгар – бик иске бәләддүр[105].

Күгешнең Биктимер угылы Камаледдин әйткән: «Бер адәм сөйәге күрдек, җелек йулындан чыкуб китдүк» диб. Әлмән кы-

[104] Кулъязмада текстның бу өлешенең сул як читендә карандаш белән болай дип язылган: «Салам-торхан дигән сүз».

[105] Кулъязмада соңгы ике җөмләнең асларына гади карандаш белән сызылган.

рында Ышналы чокырында табылмыш бер сөйәк – сыйракның йартысыдур, йугары башы булурга кирәк. Үлчәү хисабы йарты пот. Буйы – өч карыш. Бөтен булса, йите карыш була. Әмма тезултурган йиренең аркылысы – алты виршук йарым. Әмма бу кеше исән чак йегерем аршундыр[106].

// (*34б кәгазь)* Алыблар заманы Нух галәйhиссәламдән мөкаддәм булгандыр. Алыб Гуҗ бине Ганык [бинте] Адәм галәйhиссәлам[107]. Ганык – Адәм кызыдур. Ганык угылыдан озын иде – «кә-әннәhа җәбәли газыйм» иде. Әмма Гуҗ кадд-камәте өч мең өч йөз сөлс аршун иде. Ул зираг[108] бу заман зирагындин бер кабза артук иде. Гуҗның гомере өч мең алты йөз йыл иде. Муса пәйгамбәр кулындин hәлак булды. Потпәрәст, мәҗүс, кяфер иде.

Анлар җөмләсендин гъад кауме – гъад Гаус бине Әрәм бине Сам әүлядедүр, йөз йегерме аршун кадд-камәтләре. (Бу бәйан «Алты бармак» китабындадур).

***

Болгар шәhәре ислама Ибраhим галәйhиссәлам килдүке заманы, Нух галәйhиссәламдән соңдур, әүвәл кәррә Салих пәйгамбәр дәгъвәте илә мөэмин булуб иделәр.

Вә дәхи Искәндәр Руми заманында Ибраhим галәйhиссәлам дине үзә булдылар. Вә дәхи рәсүлуллаh дәгъвәте илә мөэмин вә мөселман улдуклары «Алты бармак» китабында мәзкүр хикәйәттән мәгълүм улынадур.

«Ривайәт улынур ки, хәзрәти рәсүлулла саллаллаhу Тәгалә галәйhи вә алиhи вәссәлләм бойурды ки – Җәбраил галәйhиссәлам бәне йәэҗүҗә вә мәэҗүҗә илтде. Анлары имана

---

[106] *Пот* – авырлык үлчәү берәмлеге, 16,3 кг чамасы; *карыш* – озынлык үлчәү берәмлеге, якынча чирек аршинга тиң; *виршук* – вершок, озынлык үлчәү берәмлеге, якынча 4,4 см; *аршун* – аршын, озынлык үлчәү берәмлеге, 71 см-га тиң.

[107] «Кыйсасы Рабгузи» китабында (Казан, 1859, 54–56 битләр) алып «Гуҗ ибне Ганык хикәяте» бар. Мөхәммәд Чокрыкчызадәнең «Алты бармак» (Казан, 1865, 92–94 битләр) китабында да гъад кавеме турында язылган.

[108] *зираг* – терсәк буе озынлык үлчәве (58 см).

вә Аллаһы Тәгаләйә гыйбадәт дәгъвәт итдем, кабул итмәделәр вә ислама килмәделәр – җөмләсе җәһәннәм әһеледүр. Андан бәне ике шәһәрә илтделәр: бере мәшрикъдә вә бере мәгърибтә, һәрберенең ике бең дәрвазәсе вар иде. Бер дәрвазәдән ул бер дәрвазәйә бер фәрсәх ирде. Ул мәшрикъда улан шәһәрнең халкы гъад кавеменең мөэминләрендин ирде, йәгъни нәселләрендин иде. Салих галәйһиссәламә иман китүрмешләр иде. «Сөрйани дилендә Бәркайна дийәрләр вә гыйбрани дилендә Җабәлкаһ дийәрләр – анлары динә дәгъвәт итдем, гыйбадәт тәгълим итдем – кабул итделәр».

Гөман вар ки, Болгар вилайәте[109] сәддел-әкбәргәчә мөкаддимәсе улдыгындин йәэҗүҗ вә мәэҗүҗгә сийәр вә зикерендин, шайәд, бу тарафлардур. «Җабәлкаһ»ны «Тибйан нафигъ» тәрҗемәсендә галәме мисал илән галәме җисмани илә рухани бәйнләрендә бер галәме нурани дисә дә, безләр дийәрез: «мәбхәсемез бүгүн вә фәсад вә дар тәклифдәндүр, Җабәлкаһ мөтәгаддид» дийәрез.

Вә дәхи «Тәварихы дәваир» китабында өч сахабә Болгара килүб гыйбадәткә вә дин үгрәдүб китмешләр тукызынчы һиҗрәтдә[110].

Вә дәхи хәзрәти Гомәр заманында (Могавийәнең хәйаты заманында), Габдеррахман сахабаның Турхан халкы хәзәзийан берлә җәң идүб, Болгар әтрафында ислама куәт вирүб китдүге Табарри китабында мәзкүрдүр. Та Русийәгәчә Бәләнҗәр вә Аландур.

---

[109] Кулъязмада: вилайәтеләр.

[110] «Тәварихы дәваир» исемле китапка нисбәт ителгән бу вакыйга Таҗетдин Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» исемле әсәрендә язылган. «Тәварихы дәваир» исемендәге китапның булганлыгы-юклыгы турында каршылыклы фикерләр галимнәр арасында XIX гасырдан бирле дәвам итә. Кулъязмада шушы китап исеменнән алып башка берәү гади карандаш белән сызып, русча «отсюда» (моннан) дип язган һәм ахыры 35а кәгазьдә билгеләнгән. Язу рәвешенә караганда, бу искәрмә сүзләре XX гасыр башына кадәрге чорга нисбәтле. Күрәсең, Минһаҗетдин Җәбәлинең кулъязмасы белән татар телен белгән рус укымышлыларының берсе танышкан һәм кызыксыну белдереп, күчерергә (бәлки, рус теленә тәрҗемә итәргә) ниятләгән булган.

Андин соңра холәфаи габбасийан Мәэмүн хәлифә заманында Болгар халкы мәфтух булгандыр.

Вә дәхи Васикъ Билләһи заманында фәтех ителгән вә һәм Каим Билләһи заманында утыз мең сыркәү фәтех ителгәндүр. Сыркәү – төрки лөгатенчә ир әһеле бәйте әгъмамындан вә барча карендәшләрендин йөздән меңгәчә.

Дәхи дә Болгар халкы иман китүрмешләр солтан Мәхмүд Сәбектәгин заманында бихисаб.

Әмма мәзкүр Болгар кальгасе бик олуг кальга булган. Шәһәр үзе йөз чакрымга кариб булган, унике пулад булган, хәддин мәдрәсәләр булган. Әсхабел-халят вәл-калят булган. Хөкүмәте Кафказ тарафларындин Мәскәүгәчә. Вә Мәскәү һәм бер заманны зире идарәсендә улдыкы русийәлүләрнең көтебе тәварихларында мәзкүрдүр. Болгар әтрафында әнваг халык вә әнваг лөгать тәбдилят вә тәхвилят була килгәндүр.

Бу урынга «Болгар бәйете» йазылачакдур[111].

***

// (*35а кәгазь*) Болгар халкы күбәйүб җиткәч, кәмаль галәмәте зәваль булмак үзә, Батый хан чыкуб Хытайдан күб гаскәр берлә (Чынгиз дийәрләр) Болгарны алуб, нәрсәгә тамга салдурмак гадәт идүб киткән. Андин соңра сигезенче йөз фетнәсе улан але Чыңыз – Аксак Тимер Болгарны, үзбәк шәһәре никадәр булган – һәммәсүн хәраб итмеш, кә-әлгадәм бәлки әлгадәм кыйлмыш. Тимүр бинур урусны җиңәлмәгәч[112], кайтуб, качуб киткән.

Аксак Тимер мактаулы кеше түгел, кызылбашлар

---

[111] Кулъязмада шушы искәрмә генә бар, бәетнең тексты теркәлмәгән. Кызганыч ки, китап авторының Болгарга багышланган нинди бәетне күздә тотканлыгы билгесез. Татар халкының Болгар шәһәре турындагы бәетләре күптөрле (*мәсәлән: Татар халык иҗаты. Бәетләр / төз. Ф.Әхмәтова, И.Надиров, К.Җамалетдинова. – Казан: Татар. китап нәшр., 1983. – Б. 24; «Гәүһәр Болгарга килдем...»: тарихи бәетләр..., 2013. – Б. 49–66*).

[112] Кулъязмада «җиңләмәгач» дип, хаталы язылган.

берлә, хөруфи[113] дидек кемсәнәләр берлә сәйәхәт итмеш вә мөэминләрнең канын вә йәшүн дүгүб, хозур вә хәляват тапкан адәмдүр. Йукса, шунча кадәр йахшы мөселман шәһәрене ватуб бетермәс иде.

Шул заманда Болгар татарлары бик аз гына калуб, качуб-посуп җөрүб, Казан суы буйына кальга йасайуб, йөз йылдан артук анда торуб, ул җирне йаратмайын, Казан суы Кара Иделгә[114] койган җиргә Казан кальгасен йасуб. Һәнүз Казанда хандин калмыш манара[115] бардур.

Андин Мәскау русийә халкы бик куәтләнүб, йөз илле мең кеше илән сар Ибан Бачилич йите йыл сугышуб, һиҗрәт 961 нче йылда, тычкан йылыда, бөрҗе гакърәб 2 нче көнендә[116] («Чыңыз хан китабы»нда мәзкүрдүр) күб адәмләр һәлак булуб, татарларның күб нәсел вә шөгъбәләре бетмешдүр. Ул заман Казанда мөселман гаскәре утуз мең иде.

«Казан бәйете», иске бәйетдүр:

Фар-фура фил-җөмлә уйнамаз улды,
Каһвәханәләрдә каһвәләр кайнамаз улды.

Казан шәһәре һәм бер мәшһүр бәләде газыйм улуб, башка билядлар шикелле, әһле ислам күб булгандур.

Шимдики заман Казан әтрафында җәһаләт вә фитрәтдә калдык кемсәнәләр чукдур. Мәзһәб нә идүген белмәйән мөхтәзар кеби, «Лә иләһә иллә Аллаһу Мөхәммәд рәсүл»не белүрләр, башка әгъмале җәварихдан вә башка фәнләрдән һич хәбәрләре йукдур.

---

[113] *кызылбашлар* – Иранда XVI–XVIII гасырларда хакимлек иткән сәфәвиләр династиясенең төп көчен тәшкил иткән Кече Азияле төрекләр. Башларына кигән кызыл тасмалы бүрекләренә бәйле рәвештә «кызылбашлар» дип йөртелгәннәр. *Хөруфи* – шигый мәзһәбендәге суфиларның XIV гасырда Иранда оешкан дини-фәлсәфи агымы.

[114] *Кара Идел* – Идел елгасы.

[115] Сөембикә манарасы күздә тотылган.

[116] Һиҗри 961 елның 2 нче гакърәб (чаян ае) милади белән 1554 елның 23 октябренә туры килә. Дөресе – 1552 елга туры килә торган һиҗри 959 ел булырга тиеш.

***

Үземезнең иске хикәйәтемезгә киләлек. Безнең Тау йагы халкы күб нәрсәне беләләр, бик иске нәрсәләрүн, хәлләрүн вә хикәйәтләрүн беләләр.

Алыблар иске заманда күб булгандур. Бер заман алыб дигән озун халык сука сукалаган кешеләрне җир өстендә сука сукалаб җөргән чагында, «Бу чебен ни эшләп җир җыртыб җөри?» диб алыб, кесәсенә[117] тыгуб кайткандур. Әйтәләр – имәнләрне әрем диб утаб ташлаганлар, диб. Бу сүзләрдән беленә – алыб бу җир[дә] элгәредән бар икән диб. Кечкенә халыклар соңындин җырак җирдән җыйылуб чыккач, анларга карап торасы бик шәүт(?) булган.

Бу дөнйаның әүвәлен белгән кеше җукдур. Түнтәрнең хәзрәти ишандин ишеткән идүк – бу дөнйада күб адәм исемендә адәм булуб үткәндүр, бу дөнйа ничә миллион сәнәләр дәвер иткәндүр диб хөдүсе мөсбәтдүр, әмма замане вөҗүде вә тарихы җукдур[118].

// (*35б кәгазь*) Бинаән галәйһи хәзрәти Адәмдән пәйгамбәремез саллаллаһу Тәгалә галәйһи вәссәлләм киләнчә тарихда улан асыл Адәм галәйһиссәлам зөррийәте ушандак адәмләр ул заманда Асийадә булуб, әтрафы галәмә мөнтәшир була килгәнләр. Аурупа вә Африкайа вә Америкайа вә Һинде җәнүби улан Абстралийага һаман адәмләрнең сонгы вә фигыле бөйләдүр.

Җуграфийун кауленчә, дөнйа туп күк җомрыдур вә биш икълим үзә тәкъсим идәләр: Асийа вә Африка вә Америка вә Аурупа вә Һинде җәнүби Австралийа вә башка җәзаир күбдүр.

Бу заман мәшһүр вә мәгърүф улан дөнйаның Аурупа кыйт-

---

[117] Кулъязмада «ксиләсенә» дип, хаталы язылган.

[118] 34б кәгазьдән карандаш белән сызып билгеләнгән текст өлеше шушы урында чикләнгән һәм русча «до сюда» (монда кадәр) дип язылган. Кулъязмада текстның бу урыныннан башланып, 35б кәгазьнең башына кадәр Ибраһим Хаккыйның «Мәгърифәтнамә» китабыннан күчерелеп, һинд браһманының сүзләре рәвешендә, кояш әйләнешенең 80 мең еллык хәрәкәтенә бәйле табигать үзгәрешләре турында язылган.

гасыдур. Мәдәнийәт вә башка һөнәр вә гыйлемләр күбдүр. Халкының ныйсфенә кариб әһле исламлардур. Төрек вә татар нәүгъларыдур. Бер парә Андалусийә тарафларында гарәбләр һәм бардур. Вә башка таифәдән мөселманлар күбдүр.

Аурупадагы адәмләрнең нәүглары әүвәл төрк вә татар нәселедүр, икенче – ыслувин нәселедүр. Ул нәселдән тармакланур ошбу нәселләргә: урус, пуляк, сербы, богем. Өченче нәсел нимеч нәселедүр, тармакланур: датчин, шувбит, гулансы, инглиз, франсус. Дүртенче – латыйн нәселедин чыкар: испанийәлү, португаллулар, италйанлулар. Бишенче – венгрийә нәселедүр. Алтынчы – грек вә крид нәселедүр. Йитенче – мавр нәселедүр, Испанийә мәмләкәтләрендә, Ак диңез җәзирәләрендә тору[р]лар. Сикезенче нәсел – чыганлар вә җәһүдләр мәмләкәтедүр.

## [III вариант]

// (*22а кәгазь*)

Тәварихел-Болгарийә вәл-хаканийә

Болгар вә хакан татарларының
замане сәгадәтдә ислам дине
берлә мөшәррәф булдыкларун игълам
идән мәдлүл ләүхел-кадим
рисаләседүр

Болгар вә Казанда хакан татарларының
замане сәгадәтдә ислам дине берлә мөшәррәф
булдыкларун игълам идән мәдлүл ләүхел-кадим
фи арзыйль-Болгар әл-кадим
рисаләседүр

Болгар вә Казанда улан татарлар мөтәнәүвигъ
вә җөмләсе әтракь вә хакан улуб,
барчасы замане сәгадәтдә дине ислам берлә мөшәррәф

улдыкларун игълам әйләгән мәдлүл ләүхел-мәзар
фи арзыйль-Хәзәр (ләфзыль-мәзар фил-хәзәр вәл-болгар)
хакыйкатән әл-хакан вәт-татар рисаләседүр

// (*22б кәгазь*)

**Тәварихы Болгарийә вә татарийә**

Болгар вә Казан әтрафында сакин улан әтракел-мөхтәлифәләр җөмләсендән мәгъдүд улан таифәләрнең исемләре – кадим хан заманында вә хөкүмәтендә улуб, таифәләренең нәүгъ вә җенесе чирмеш вә чуаш вә мукшы вә ар вә татар – җөмләсе Болгарийә халкыдур.

Вә дәхи башкорд вә мишәр, вә төмән вә кыргыз, вә Төркестан дәхи бер заман Болгар хөкүмәтендә улуб, Болгар, дәхи Төркестан вә Хәзәр вә Хәзәз, фәгъфуре Чин исемендә булуб, җөмлә әһле мәган иттифакы берлә Болгар арзы вә мәмләкәте бер васыйг мәмләкәт улуб, Дәрбәнд вә Дәмур нам Кафказ тарафындан Боз диңгезенә вә Сибирийә тарафларына кадәрдүр – җөмләсенә Хәзәр вилайәте дийәрләр. Эчендә әтракел-мөхтәлифәләр вә әүладе Йәфәс берлә мәмлүдүр.

Болгарның кадим заманда баш шәһәрләре исемләре Сарай (Дарел-мөлкет татар) вә һәм Сәмәндәр вә һәм Хәзәр, Казан вә башка исемләр берлә булган күб шәһәрләре улуб, хәзер заманда бихисаб биляд вә шәһәр урунлары Болгар арзында булмакдадур. Ләкин исемләрене күб кемсәнәләр белмәдекләрендән, исемләрүн йазмадүк. Шулкадәр вар – Болгарның баш шәһәре Сәмәндәрнең тәхете йегерме сәнә сәнгать идүлүб, алтун вә көмүш вә җәваһир илә морәссаг гаҗәйебеш-шәкел иде, хәзерендә урыс кулында дәйү әйтәләр вә китабларда күренәдүр.

Болгар нам шәһре кадим Салих пәйгамбәр өммәте булуб, соңра хәзрәти рәсүлгә иман килтүрүб, бер заман Искәндәр Руми тәхте тәсаррыфында булуб, нәчә йыллар мөэмин булуб әүкате гөзар итмешләрдүр.

Болгар вә Казан хәляикы әтракь җөмләсендән улуб, хәзәр вә хәзәзийан халкы дийәрләр. Барчасы әтракь вә татарлардур. Болгарга табигъ улан әтракләр чуаш вә чирмеш вә мукшы вә ар хәляикы хан заманында Мөхәммәд пәйгамбәр заманын-

дин бирле мөэмин, өммәте Мөхәммәд улуб, мөрүрез-заман берлә мөтәфәррикъ улдукларун игълам кыйла торган йазулы кабер ташлары әйтәдүр. Болгарда вә һәм Болгарның әтрафе бәгыйдәләрендә һәр таифәнең мазарларында күрендеке ташларда Болгарның соң мәртәбә ислам берлә куәт тапмаклары солтан Мәхмүт Сәбектәгин заманында булуб, алты-йите мәртәбә тәҗдиде ислам ителгәндүр: әүвәл – Салих пәйгамбәр заманында вә дәхи – Искәндәр Руми заманында.

// (*23а кәгазь*) Хосусан, Болгар вилайәте хәзрәти Габдеррахман сахабә кулындин күбесе мөселман булганнардур. Ул заманда Болгар халкының хан исемендә булган кемсәнәсе хакан-һәзар дийәрләр, татарларның ...[119] падишаһыдур.

Әмма татарларның чуаш таифәсе урысның Казанга истилясы заманындан илле-алтмыш сәнә җәһаләт калуб, мәҗүси вә әтракнең кадимдә булган гадәте шәнигаларун ихдас идәрәк, мәҗүси улуб калмышларына әл-йәүм дүрт йөз сәнәдүр ки.

Урыс йөз утуз мең гаскәр берлә чуаш халкы өстендә басуб йатмышдур. Анларны ислам гамәлләрүн кыйлурга498 издихам идүб вә һәм тәнассыр кыйлурга вакыт булмай, мәҗүси кыйлуб китүб, шимдики заман анларны тәнассыр кыйлу нийәте бик мөшәддәд улуб, тәфтиш идәләр. Чуашларның хане кадим заманында мөселман булдыкларына дәлил кәндү җенесләрендән вә гөй ...[120] улан мөәххидләрнең исемләредүр – Габдеш вә Заид вә Шәфи кеби, кызларында Гөлбостан, [Шәрбо]стан кеби исемләр.

Ушандак ар хәляикы вә чирмеш хәляикы вә мукшылар кыз биргәндә мәһәр тәгайен кыйлалар вә тәгамне ифтитах кылганда «бисмиллә» дийәрләр.

Вә көй вә карйәләренең корбендә улан пыракмыш вә тәрк иделмеш олуг мазарларында йазулы ташларында замане тарих һиҗрийәдән тукуз йөздүр. Вә дәхи ташларында айате

---

[119] Кулъязманың кәгазь чите таушалып ертылган булуы сәбәпле, бу урындагы бер сүз укылмый. Аның ахыргы хәрефе «с» (син) яки «ш» (шин) генә күренә.

[120] Кулъязмада кәгазьнең чите ертылган булуы сәбәпле, бер сүз танылмый.

Корънийә вә хәдисе рәсүл йазылуб, күбесе урыс мөхарәбә идеб мәгърәкәдә шәһид улмыш хан вә би улмыш чуашлардур ки. Чуаш таифәсе төркийе сарыф (хәзәр вә хәзәзийан, фәгъфур халкы) вә мәшрикыйдур. Кайу ташларында «әл-хаж Чәләби» дәйү йазылмыш вә кайусында «би» дәйү йазылмыш, вә кайусында «әфәнде» дәйү йазылмыш вә кайусында «хуҗа» дәйү йазылмыш. Әксәрийән тарихе һиҗри берлә «тукуз [йөз] сәнә» йазылмышдур. Әкальлел-калил вардур һиҗрәт тарихы йазылган ташларда йә ...[121] «... йөз кырык», бәгъзесендә «сикез йөз» тарихе һиҗрәт йазылмышлары һәм вардур.

Гомумән, җомга көнне әгзаз вә гайде мәсәррәт кыйлалар.

Вә һәм кадим заманда булган Болгар шәһәренең мазарында һәм ташларда чуаш лөгате берлә йазылган ташлар күбдүр диб хикәйәт идәләр.

Безнең Бәчек бинең [та]шында йазылмыш айәте Коръәнийә: «Көллү мән галәйһа фанин вә йәбка вәҗһи Раббикә зөл-Җәлали вәл-икрам тарих тукуз йөз йитедә [ва]кыт Шәгъбан бине Әсәд бине Әмурхан бине Әбамган бине Шыгал хан бине Төнихуҗа Бәчүкә угылы кяфер кулындин шәһид булды».

// (*23б кәгазь*) Әл-йаүм 1295 һиҗрийә Казан губернасы Зөйә мәхкүматендә улан Бүә суының буйында улан Бәчек авылының мазарында улан каберстанда бер олуг ташның сурәтедүр.

[Бу] ташта мәдфүн [кем]сәнә Шәгъбан бине [Ә]сәд бине Әмурхан бине Әбамган бине Шыгал хан бине Төнихуҗа угылы Бәчүкә угылы тарих тукуз йөз йитедә вакыт кяфер кулындин шәһид булган.

*[кабер ташы рәсеменең алгы ягындагы язуы]*:

1) калә Аллаһу Тәбарәкә вә Тәгалә

2) көллү мән галәйһа фанин вә йәбка вәҗһү Раббикә

[121] Кульязмада кәгазьнең чите ертылган булуы сәбәпле, берничә сүз танылмый.



*Бәчек авылы зиратындагы тарихи кабер ташының Минһаҗетдин Җәбәли ясаган рәсеме. 23б кәгазь*

3) зөл-Җәлали вәл-Икрами[122]
4) тарих тукуз йөз йитедә вакытка
5) Шәгъбан бине Әсәд бине Әмурхан бине Әбамган бине
6) Шыгал хан бине Төнихуҗа угылы Бәчүкә
7) кяфер кулындин шәһид булды

[*кабер ташы рәсеменең арткы ягындагы язуы*]
1) бу ләүхне гамәл пи
2) ..ис бина кыйлды

[*Уң ягында:*] калә ән-нәби галәйһиссәлам әд-дөнйа мәзрагатүл-ахирәти.

[*Сул ягында:*] калә ән-нәби галәйһиссәлам әд-дөнйа сагать фәҗгальһа тагать.

Бу таш белдерәдүр – Бәчек авылы йите йөз йылдан бирле авыл салынуб, шушы урында көн итүб, дәхи күб заманларда мөселман булуб тордыкларун. Бәчек авылы Болгар хәраб булмасдан мөкаддәм булуб, ханның бер күркәм бийе улдыгындан «Бичегем» дәйү әйтдүкендән Бәчек ...[123] ...лар ... булган ... күб ... калуб, чуаш улмышлар, ... авылны өчкә ... Бичек би, Күз би, Мулла бабай, Дүскә(?) бабай «Иске йорт»да ултурганлар, имәннек чатында. Йәгъни, тау башында – имәннек урманында.

Әлмән, Кармыш, Бәчек – һәр өчүсе ханның биләрендән мәхсүб. Әл-йаум мөтәфәррикъ улуб, өч авыл булуб, нә өчүн ...[124]

[122] *көллү мән галәйһа фанин вә йәбка вәҗһү Раббикә зөл-Җәлали вәл-Икрами* – Корьәннең «Рахман» сүрәсендәге 26–27 нче аятьләрдән алынган, мәгънәсе – җирдә булган һәр нәрсә һәлак булачак, фәкать олуглык һәм хөрмәт иясе булган Раббыңның заты мәңгелек.

[123] Кульязма кәгазенең түбәнге юлы таушалган, аерым сүз өлешләре генә күренә. Аннан соң текст кәгазьнең читенә язылып дәвам иткән. Ул читләре дә таушалган, язулары җуелган. Танылган аерым сүзләрне һәм сүз өлешләрен күрсәттек.

[124] Кульязма җыентыкта текстның шуннан соңгы дәвамы юк.

# БОЛГАР ҺӘМ ТАТАР ТАРИХЫ

## (хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе)

# [II вариант]

Таш белән куылган шайтаннан качып, Аллага сыгынам.

Миһербанлы һәм рәхимле Алла исеме белән.

Ике дөньяның хуҗасы Аллаһы Тәгаләгә шөкерләр булсын. Һәм тәкъва бәндәләргә хәерле ахырлар сорыйбыз. Сәетебез Мөхәммәткә һәм барлык нәсәбенә, барлык сәхабәләренә, барча пәйгамбәрләргә, рәсүлләргә, фәрештәләргә һәм якыннарына, шулай ук күктәге һәм җирдәге барлык иман әһелләренә дога һәм сәламнәр булсын.

Шуннан соң, ислам динендә Мөхәммәтнең[1] нурлы шәригатендә сайланган сөнни милләттә, котылучы сөнни фиркадә булган сөнниләр һәм җәмәгать төркемендә Әбелмансур әл-Матуриди мәзһәбенчә инанып һәм ачык гамәлдә имам әгъзам Әбү Хәнифә Куфи[2] (аңа Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте булсын) мәзһәбендә һәм аның өйрәтүенчә гамәл итеп, һәм дә шәкертләре –имам Мөхәммәт, имам Әбү Йосыф, Хәсән бине Зияд һәм Зөфәр[3] әйткәнчә тырышып, заман фәтвасы белән гамәл кылып, пәйгамбәребездән (аңа Аллаһы Тәгаләнең салаватлары һәм нәселенә сәламнәре булсын) Әбүбәкер әс-сиддыйкка[4] (Аллаһы Тәгалә аннан риза булсын) рөхсәт ителгән һәм боерыл-

---

[1] *Мөхәммәт* – мөселман пәйгамбәре, ислам динен нигезләгән, дини, иҗтимагый һәм сәяси юлбашчы, Гарәбстанда беренче ислам дәүләтен оештырган Мөхәммәт ибне Габдулла ибне Габделмоталлиб ибне Һашим (570–632).

[2] *Әбү Хәнифә Куфи* – ислам диненең мәшһүр галиме, мөхәддис, хәнәфи мәзһәбен нигезләүче Әбү Хәнифә эн-Ногман бине Сабит (699–767).

[3] Әбү Хәнифәнең монда әйтелгән дүрт шәкерте – иң бөек һәм мәшһүрләреннән. *Имам Мөхәммәт* – Мөхәммәт ибне Хәсән ибне Фиркад әш-Шәйбани (752–835); *Имам Әбү Йосыф* – исламдагы беренче казый, фәкыйһ Әбү Йосыф Ягъкуб ибне Ибраһим әл-Куфи (731–804); *Имам Хәсән бине Зияд* – мәшһүр фәкыйһ; *Имам Зөфәр* – мәшһүр ислам галиме Зөфәр ибне әл-Һөзәйл ибне Кайс ибне Сәлим әл-Ганбәри әт-Тәмими (728–775).

[4] *Әбүбәкер әс-сиддыйк* – Мөхәммәт пәйгамбәрнең якын кешесе һәм вафат

ган бөек суфичылык силсиләсеннән рөхсәтнамә бирелгән, хак юлны күрсәтү белән суфилар шәҗәрәсе итеп барлыкка килгән Габделхаликъ әл-Гыйҗдувани[5] силсиләсендә Нәкышбәндия хөҗагян[6] хәзрәтләренең яшерен, серле тарикатендәге мәшһүр бөек затларны зиннәтләү нияте белән, иң әүвәле Алла дип, мин – Минһаҗетдин Сәйфулла улы Бәчектә имам (төп ватаннан күчүчеләрдән булып, Мамадыш авылыннан бабайлар унике кеше имам булып үткәннәр), бер китапчык төзедем. Үз нәселләребез һәм кардәшләребезне аңлатып һәм ачыклап бирү нияте белән, бу китапка «Болгар һәм татар җирендәге төрле көрдләр һәм төркиләрнең хәлләреннән сайланма» дип исем биреп, борынгы тарихтан иске зиратларда булган ташлар белдерүе буенча, иске сүзләр һәм тел буенча, татарларның сөйләшкәндә кулланган гыйбарәләреннән һәм сүзләреннән алып, фикерләп, тарих китапларыннан һәм сүзлекләрдән, кайбер төрекчә тәрҗемәләрдән алып, төшенеп, җыеп яздым. Гарәпчә «Нисабелинтисар» китабы һәм «Камус» тәрҗемәсе булган «Укъянус»[7] китабы, «Борһане катыйг» тәрҗемәсе булган «Тибъян нафигъ»[8]

---

булганда үзе урынына калдырган беренче хәлиф Әбүбәкер Габдулла ибне Госман (якынча 572–634). *Сиддыйк* – «тугры» мәгънәсендәге, хөрмәтләү һәм олылау сүзе.

[5] *Габделхаликъ Гыйҗдувани* – Урта Азиядә мөстәкыйль суфичылык мәктәбен нигезләгән Габделхаликъ бине Габделҗәмил әл-Гыйҗдувани (1180 яки 1220 елда вафат булган). Аның тәгълиматын Нәкышбәнди суфичылык тармагы тулаем кабул итеп, камилләштергән.

[6] *Тарикаи Нәкышбәндийә хөҗагян* – XIV гасырда оешкан суфичылык тарикате. Габделхаликъ Гыйҗдувани тәгълиматын һәм Әхмәт Ясәви суфичылык мәктәбен тулыландыру нигезендә барлыкка килгән. Оештыручысы хуҗа Баһаветдин Мөхәммәд Нәкышбәнд (1318–1389) исеменә нисбәт ителеп, «Нәкышбәндия» дип аталган.

[7] «*Укъянус»* – госманлы галиме Мөтәрҗим Гасыйм әфәнде тарафыннан 1814 елда тәмамланып, госманлы солтаны Икенче Мәхмүдкә тәкъдим ителгән гарәпчә-төрекчә «Әл-Укъянусел-бәсыйт фи тәрҗәмәтил Камусил-мохит» сүзлеге. Бу китап – гарәп теленең филолог галим Фирузабади (1415 елда вафат) төзегән аңлатмалы сүзлегенең тәрҗемәсе. XIX гасырда өч һәм дүрт томлыклар рәвешендә Истанбулда, Каһирәдә берничә мәртәбә басылган.

[8] *«Тибъян нафигъ»* – XIII гасырда яшәгән Мөхәммәд әт-Тибризи әсәре.

һәм «Мәгърифәтнамә»[9] китаплары, Табарри тарихы булган «Тәварихы Табаррийә»не[10] кулландым.

Үзебез Түнтәр Галимөхәммәт[11] Сәйфулла улы мәдрәсәсендә белем алып, сарыф һәм нәхү, мантыйк һәм фәлсәфә, кәлям һәм ысул, «Тәүзыйх» китабы һәм башка дини әсәрләрне бераз тыңлап, «Тәлхыйс» һәм «Мотаувәл»[12] дәресләрен дә укыптыңлап, фәнни мәсьәләләрдән «Һидая», «Шәрхе викая» һәм «Мөхтәсар»[13], хәдистән «Мишкяте мәсабих»[14] дәресен тыңлап, тәсаувыф фәненнән «Тарикаи Мөхәммәдия», «Хадими», «Мо-

---

Тулы исеме «Тибъян нафигъ тәрҗемәти Борһане катыйг. Әл-хәййа әл-гаммә ли-дирасәтел-көтебе каумийә».

[9] Госманлы төрек галиме, энциклопедист, суфи шагыйрь Ибраһим Хаккыйның (1703–1780) «Мәгърифәтнамә» әсәре гакыйдә мәсьәләләренә, шул исәптән суфичылык (Нәкышбәндия тарикате) тарихына багышланган. Бу әсәр үзенчәлекле энциклопедия сыйфатында. Анда суфичылык белән бергә, төрле фәннәр (астрономия, математика, анатомия, психология, философия) буенча да мәгълүматлар тупланган. И.Хаккый ислам дине белән төрле фәннәрне үзара килештерүгә зур әһәмият биргән. Автор үзе белдергәнчә, бу әсәрен язар өчен 400 чыганакны файдаланган. Бу китапта беренче мәртәбә Кояш системасының фәнни тасвиры язылган. Хаккыйның шулай ук медицина, анатомия, физиология, арифметика, философия, әхлакка багышланган, төрек, фарсы һәм гарәп телләрендәге 15 китабы һәм трактатлары бар.


[10] Фарсы тарихчысы һәм дин галиме Әбү Җәгъфәр Мөхәммәд ибне Җәрир ибне Йәзид әт-Табарриның (839–923) «Тарихер-рөсул вәл-мөлек» хезмәте – пәйгамбәрләр һәм патшалар тарихы. Аны «Тарихе Табарри» дип йөрткәннәр. Бу хезмәттә Коръән иңгәннән алып, 915 елга кадәрге мөселманнар тарихы тәфсилле тасвирланган (625–915 еллар арасындагы елъязма рәвешендә) һәм әлеге китап тарихчылар өчен беренчел чыганаклардан исәпләнә.

[11] *Галимөхәммәт* – автор үз остазының исемен шушы рәвештә язган. Башка чыганакларда: Мөхәммәтгали.

[12] *«Мотаувәл»* – күркәм сөйләм (бәлягат) буенча дәреслек итеп кулланылган китап.

[13] *«Һидайә»* – Борһанеддин әл-Мәргыйнәнинең (1197 елда вафат булган) фикъһ буенча гарәп телендәге хезмәте; *«Шәрхе викайә»* – Гобәйдулла бине Мәсгуд Таҗешшәрига (1346 елда вафат булган) тарафыннан язылган фикъһ китабы; *«Мөхтәсар»* – Гобәйдулла бине Мәсгуд бине Таҗешшәриганың «Мөхтәсарел-викайәт фи мәсаилел-һидайә» исемле, фикъһ буенча гарәп телендәге әсәре.

[14] *«Мишкяте мәсабих»* – XIV гасыр галиме Вәлиэтдин Мөхәммәт ибне Габдулла әл-Хатыйб әл-Гомәри әт-Тәбризинең «Мишкятел-мәсабих» исемле, хәдисләргә аңлатмалар җыентыгы.



*II вариант текстының башы,*
*38б кәгазь*

радел-гарифин», «Мәсләкел-мөттәкыйн»[15] китапларыннан дәрес алып, Аллага шөкер, әйтелгән ишан хәзрәт исән вакытында аның рөхсәте белән Тау ягына – Бәчек (дөреслектә – Бичек) авылына имам булып, хәерле истәлек һәм дәвамлы сәдака[16] булса иде дип яздым.

Әйтеп үтелгән ишан хәзрәт утыз ел дәвамында заһир һәм батыйн[17] гыйлем алган Һиндстан мәмләкәтендә һәм Бохараи шәрифтә. Казан мәмләкәтенә кайтып, кырык-илле ел буе заһир һәм батыйн гыйлемнәрдән дәрес әйткән. Үзе шул гыйлемнәр өчен рөхсәтнамә алган кеше. Туксан ел яшәп, рәҗәпнең унбишендә, җомга көн вафат һәм Түнтәр авылында җирләнде. Аңа Алланың киң рәхмәтләре ирешсен.

Моннан соң ишан хәзрәт мәдхиясе язылыр[18].

***

Югарыда әйтелгән һәм язылган гарәпчә әсәрләр белдерә ки, «Хәзәр» һәм «Биляде җәбәлел-фәтех» җире бер киң-иркен җир булып, андагы ишле өммәтләр төрле төркиләрдән булып, шәһәр-калаларының чиге яэҗүҗ-мәэҗүҗ диварына[19] кадәрле җирдә урнашкан.

---

[15] *«Тарикаи Мөхәммәдия»* – Мөхәммәт Биркәви әсәре, татар мәдрәсәләрендә ислам әхлагы буенча дәреслек итеп кулланылган. *«Морадел-гарифин», «Мәсләкел-мөттәкыйн»* – төрки шагыйре Аллаһыяр Суфиның (Әбү Мөхәммәт Аллаһыяр бине Аллаһколый, 1616–1713) фарсы телендәге әсәрләре.

[16] *дәвамлы сәдака* – дәвамлы файдасы булырдай игелек; бу очракта автор Мөхәммәт пәйгамбәрнең «Әгәр бер кеше вафат булса, өч нәрсәдән кала, аның гамәле киселер: дәвамлы сәдака, файдалана торган гыйлем һәм дога кылучы изге бала» дигән хәдисен күздә тоткан.

[17] *заһир һәм батыйн* – суфичылыкта: Коръәннең һәм хәдисләрнең тышкы (ачык) һәм эчке (яшерен) мәгънәләре.

[18] Кульязмада шушы искәрмә генә теркәлгән, шигъри тексты юк.

[19] *яэҗүҗ-мәэҗүҗ дивары* – дини риваятьләрдә тасвирланган имансыз кыргыйлар. Искәндәр Зөлкарнәйн зур дивар төзетеп, аларны башка халыклардан аерып куйган. Коръәндә «Әл-Кәһф» сүрәсенең 82–102 нче аятьләрендә бу вакыйга тасвирланган. Дини риваятьләрдә диварларның икәү булганлыгы һәм аларның берсе – Кавказ яки Урал таулары, Бөек Кытай стенасы белән дә тиңләштерелгән. (Чынлыкта, Кытай стенасы Александр Македонскийдан

«Хәзәр» һәм «Җәбәлел-фәтех»нең мәшһүр кала һәм шәһәрләре Сәмәндәр шәһәре, ул бер зур, тәхетле кала булган, аны гарәпчә «Сәрир»[20] дигәннәр. Егерме ел дәвамында көмештән һәм алтыннан тукып ябылган. Әмма ул Сәмәндәр шәһәрен рус халкы җимергән һәм тар-мар иткән. Ул Сәрир һаман бар.

Һәм тагын «Җәбәлел-фәтех»нең мәшһүр шәһәре һәм каласы Болгар шәһәре.

Нух пәйгамбәрнең улы булган Самнан тармакланган фарсы халкы «гъад» кавеменнән булып, алар – көрдләр һәм башкортлар, шулай ук башка төркиләр ки, хәзәр (хәзәз) халкы, чуваш һәм чирмеш, мукшы, ар (вотяк), башка таифәләр – болгарлар.

Болгар мәмләкәте һәм җире – төньяк һәм көнбатыш Русия белән тигезлектәге күрше мәмләкәт ки, үзе өч сәгать ярым җирдә рус белән чикләнеп, Болгар җире диләр, Кавказ тарафларыннан кар яуган җирләргә кадәр. Янә Болгар (Хәзәр һәм Хәзәзийан) җире йегерме ике мең фәрсәх[21].

Болгарның ныгытмасы йөз чакрым җиргә җәелеб яткан, дивары – кирпечтән, тугыз чакрым булган. Хәзер Болгар шәһәре урыны дип әйтелгән шәһәр дивары һәм ныгытылган урынны зиярәт кылсалар, Искәндәр Руми бу Болгар каласын иң зур акыл ияләренчә ныгытма итеп корып, халкын саф мөэмин итеп киткәнлеген китапның башында бәян иткән идек. Искәндәр Болгарны төзегәнгә ике мең елдан артыграк.

---

соңгы чорда төзелгән). Рабгузи китабында Искәндәр дивары турында 430–432 битләрдә язылган. Урта гасырлардагы географлар күзаллавынча, яҗүҗ-мәэҗүҗләр хәзәр җирләреннән көнчыгыш тарафта булганнар.

[20] *Сәмәндәр* – Хәзәр каһанлыгы чоры шәһәре һәм бераз вакыт башкаласы булып торган. Каспий (Хәзәр) диңгезенең көнбатыш ярында. Хәзерге Дагстанның шәһәр тибындагы посёлогы. *Сәрир* – Дагстан территориясендә VI–XVI гасырларда булган дәүләт исеме. М.Җәбәли VII гасырдагы Иран патшасының Сәриргә җибәрелгән алтын тәхете турындагы риваятьне күздә тоткан.

[21] *фәрсәх* – ераклык үлчәве, җайдак тарафыннан 1 сәгатьтә үтелгән юл озынлыгына (якынча 6–7 километрга) тиң, ә кайбер очракларда 10 чакрым чамасы дип исәпләнә.

Һәм ул Болгар исемен куеп киткән. Юкса, борынгы заманда «Җабәлкаһ» дигәннәр.[22]

«Алты бармак» китабында[23] әйтелгән мигъраҗ хикәясеннән аңлашыла ки, пәйгамбәребез Мөхәммәт мостафа хәзрәтләренең (Аллаһы Тәгаләнең аңа салаватлары һәм нәселенә сәламнәре булсын) бәхетле заманнарында булган Болгар шәһәренә Булга (Бүлге, Кара Идел) янында Болгар вилаятьләренә нисбәтле төрле көрдләр һәм төркиләр булганлыгын, Мөхәммәт пәйгамбәр заманында ислам дине белән хөрмәтләнгәнен фәнни тарих әсәре «Нисабел-интисар» һәм башка китаплардан күчереп, төрки һәм көрд сүзләреннән алып бәян итәбез ки, алар – Болгар халкы – барча нәсел-ырулары белән төрки һәм көрд халыклары-нәселләре.

Көрд кавемнәре нигездә башкорт халкы, әйтелеше һәм мәгънәсе буенча «баш көрд». Алар борынгы заманда «гъад» исемендә булып, Салих пәйгамбәр дәгъвәте белән мөэмин булган Көрдстан халкы.

Башкорт (башкөрд) халкы бик төрле булсалар да, күпчелеге «си» башкорты, ...[24] сүзләрнең «фарсыча җим» хәрефе белән «ча» кулланылырга тиешле хәреф «син» һәм «гарәп телендәге си»[25] хәрефе белән әйтәләр. Мәсәлән, «сәй эстем» вә «сәй истем»[26] диләр ки, Казан татарларынча «чәй эчтем» дигән сүз

---

[22] Кулъязманың бу урынында «Гъад кавеме Салих пәйгамбәр өммәтләре» дип башланып, яэҗүҗ-мәэҗүҗләр телгә алынып, «көнчыгышта һәм көнбатышта булган «Җабәлкаһ» вә «Җабәлсаһ» шәһәрләренең халкы» дигәннән соңгы дәвамы кәгазь читенә язылган һәм таушалып, танылмаслык дәрәҗәгә килгән. Андагы 1–2 җөмлә укылмый.

[23] «*Алты бармак» китабы* – дини-әхлакый әсәр, авторы – госманлы галиме Мөхәммәт ибне Мөхәммәт Чокрыкчызадә (1623 елда вафат). Бу әсәр Мөхәммәт пәйгамбәргә багышланган, анда шулай ук тарихи, тәрбияви һ.б. мәгълүматлар да тупланган. Башта кулъязма күчермәләрдә күп таралган. Казанда беренче мәртәбә 1861 елда басылган.

[24] Кулъязманың бу урынында кәгазьнең иң өстәге читендә язылган берничә сүз танылмый.

[25] Өстендә өч ноктालы «с» хәрефе.

[26] Бу гыйбарәләрнең беренчесендәге сүзләр «си» хәрефе белән, икенчесендәгеләре «син» белән язылган.

була. Бозаулык буе башкортлары «ч» хәрефен әйтәләр.

Һәм тагын «кый» башкорты дияргә мөмкин ки, тәмам булган сүзләренең ахырында «кый» гыйбарәсен кушып сүзне тәмамлап сөйләшәләр. Мәсәлән «чәй эчтем кый» һәм «китап укыдым кый» диләр. Пермь губернасында күбесенчә шундый сөйләм.

Һәм тагын «һи» башкорты дияргә мөмкин, гарәпчә «син» авазы белән әйтелергә тиешле урында «һи» авазын кулланалар. Мәсәлән, «һин кем булаһың?» диләр. Уфа вилаятьләрендә булган башкортлар, аларның «син» авазы юк. «Үзеңне шиккә төшерә торган нәрсәдән аерылып, икеләнү тудырмый торганга мөрәҗәгать ит!» (хәдис).

Төрле төрки кавемнәрнең күбрәге чуваш (суас, сүәс, сүс) халкы ки, төрки кабиләсеннән Уз тарафларындагы Сивас каласы халкы кебек. Тел һәм кафтан (калпак, тәкыя) сугып ясаган әйберләр исбат итә, гүяки, алар төрекләр. Мәсәлән, ел башы ае – мартны чувашлар «нәүрүз» диләр, төрекләр дә «нәүрүз» диләр. Җомга көнне «эрне кун» диләр, төрекчә «әзинә көн». «Пәйгамбәр куляне» – «пәйгамбәр колынды», «күсрә перлә кайе» – «кырык берлә кит», «җумартачы» – «йомартайы», «ман хурланмизыр» – «мән хурланмийур», «каймизыр» – «гәлмийүр», «бармазыр» – «бармайур», «бахыт пулать» – «бәхет булыр», «теләй пулать» – «теләй булыр», «талига» (талиха) пулать» – «талига булыр», «асыл пулать» – «асыл булыр», «бәрәкә пулать» – «бәрәкәт булыр», «савап пулать» – «савап булыр». «Тур» диләр – «тары» димәк булыр ки, Ходай исеме. «Ине» диләр – төрекчә «инәҗәк». «Пырак юлдаш» – «парах юлдаш», «лайах пулать» – «ляих булыр», «чух» – «йух»[27]. Һәм күп сүзләре яртысыннан артыгы гарәпчә һәм төркичә. Әмма русларга күрше булып, бу заманда кайбер сүзләре русча. «Фа» авазы юк, «ха» хәрефе белән белдерәләр. Мәсәлән, «франсус» дигән сүзне «хрансус» диләр. Уен кораллары исемнәре: «зурнай» – төрекчә «зорнай».

---

[27] Хәзерге чуваш телендәге кайбер сүзләрнең язылышлары башкачарак. Чуваш алфавитындагы махсус хәрефләрдән тыш, автор кульязмасында «пулад» дип теркәлгән сүз хәзер «пулать» дип белдерелә һ.б. *Куляне* – хәтере калыр,

Шулай ук чирмеш халкы җөббә (тухия) кияләр. «Җөббә» дигән сүз «сөббә», гарәпчәдән, сәүб (өс киеме). «Тухия» – «тукыя», ягъни тукып эшләнгән. Һәм башка шундыйлар чирмеш халкы сөйләмендә төрки һәм гарәби сүзләр күп. Чирмеш чувашны «кирек мари» дигәненнән алар бер ыру икәнлеген үзләре һәм телләре исбат итә. Ягъни, «тау чирмеше» дигәнне белдерә. Әмма чирмешләр татарларны «суас» диләр, удмуртлар татарны «бигер» диләр.

Һәм шулай ук мукшы халкы һәм мордва халкы болар кебек үк төрки кавемнәр. Әмма болар барчасы борынгы заманда «гъад» кавеменнән саналып, Азәрбәйҗанга күрше мәмләкәт булып, бер заман Әфридун[28] хөкүмәтендә калып, утка табынучы һәм башка мәҗүси гамәлләрендә күренәләр. Юкса, Болгар барча буйсынган халкы белән егерме ике мең фәрсәх җир кадәр төрле төркиләр һәм көрдләр булып, ислам динендә булганлыклары бәян ителә.

Бу заманда Госманлы дәүләтенең вилаяте булган Македония җирендә Иянҗә[29] каласында Искәндәр туып, бөтен фәннәрне белгән Искәндәр хәким румлылар һәм сакъләбләргә лях[30], поляк һәм чех, немец, венгр, Валахия һәм Молдавия халкы белән килеб, Болгар каласын хикмәт ияләренчә төзеп, халкын Ибраһим динендә кылып, үзе дивар (яэҗүҗ-мәэҗүҗ чиге) тарафына киткән.

Болгар җиренә «Арзыль-Хәзәр», «Дәшти Кыпчак» һәм «Хәзәр» дибез ки, «Нисабел-интисар» китабында: [*гарәп*

---

*мән хурланмийур* – борчылмыйм, *гәлмийүр* – килми, *бармайур* – бармый, *талига* – бәхет, *инәҗәк* – төшәчәк, *пырак* – ташла, *ляих* – яхшы, *йух* – юк.

[28] *Әфридун (Фәридун)* – 1066 елда Дәрбәнт хакиме итеп билгеләнгән шәхес.

[29] *Иянҗә* – Искәндәр Зөлкарнәйн (Александр Македонский) – рәсми мәгълүмат буенча Пелла шәһәрендә безнең эрага кадәр туган шәхес. Антик чордагы Пелла каласы булган урын янында «Яница» исемле күл мәгълүм, Иянҗә дигән атама шуны белдерә torгандыр.

[30] *сакъләби* – сәкъләб (сәкалибә) этнонимы, соңгы дәвер галимнәре билгеләвенчә, Көнчыгыш Европаның урманлы җирләрендә яшәгән бөтен халыкларга карата кулланылган, аны аерым бер халыкка гына нисбәт итү дөрес түгел һәм тарихи текстларда тәрҗемәсез генә язу кулай. *Лях* (ләһ) – чехларның берничә этнографик төркеменең гомуми атамасы.

*телендәге өземтәнең мәгънәсе: «Хәзәр иленең һәм Җәбәлелфәтехнең җире киң, анда хисапсыз төрле төрки халыклар яши һәм патшалыклары да төркинеке, Искәндәр төзегән диварга чиктәш»*].

Болгарны Искәндәр төзетүе «Тәварихе дәваир» китабында[31] да телгә алынган.

Әмма Болгар шәһәре төрки һәм хәзәр дәүләте ки, аның Искәндәр төзеткәннән әүвәл булганлыгы «Алты бармак» китабыннан мәгълүм: «Риваять кылына ки: Рәсүлулла (аңа һәм нәселенә Аллаһы Тәгаләнең сәламнәре булсын) белдерде – Җәбраил фәрештә мине яэҗүҗ-мәэҗүҗгә илтте. Аларны иманга һәм Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәткә дәгъвәт иттем – кабул итмәделәр һәм исламга килмәделәр – һәммәсе җәһәннәм әһеле. Аннан мине ике шәһәргә илттеләр – берсе көнчыгышта һәм берсе көнбатышта, һәрберсенең ике мең капкасы бар иде. Бер капкадан икенче капкага бер фәрсәх иде. Ул көнчыгышта булган шәһәрнең халкы «гъад» кавеменең мөэминнәреннән, ягъни нәселләреннән иде, Салих галәйһиссәламгә иман китергәннәр иде, сөрьяни телендә «Бәркайна» диләр иде һәм гыйбрани телендә «Җабәлкаһ»[32] диләр иде. Дингә дәгъвәт иттем һәм гыйбадәт өйрәттем – кабул иттеләр».

Алла теләсә, көнчыгышта булган мөэмин шәһәр һәм «гъад» кавеме – Болгар каласыдыр ки, «Болгар җире» – диварның (яэҗүҗ-мәэҗүҗ чиге) күрше мәмләкәте һәм башланган урыны. Тагын да дивар тарафына чыгып китүчеләр һәм баручылар Болгар аркылы йөргәннәр. Искәндәр Руми йөргән кебек.

Әмма «Тибъян нафигъ» тәрҗемәсендә әйтелгән ки: «Җабәлкаһ галәме мисал (образлар дөньясы) белән матди һәм

---

[31] «Тәварихы дәваир» исемендәге китапның булганлыгы-юклыгы турында каршылыклы фикерләр галимнәр арасында XIX гасырдан бирле дәвам итә.

[32] *Җабәлкаһ* – борынгы китапларда (мәсәлән, X гасыр тарихчысы Табарри хезмәтендә, XIII гасыр галиме Зәкәрия әл-Казвининең «Гаҗаибел-мәхлукат» китабында) Җабәлкаһ (Җабәлка) һәм Җабәлсаһ (Җабәлса) исемнәрендәге калалар турындагы риваятьләр теркәлгән. Мәсәлән, Рабгузиның «Кыйсаселәнбийа» китабында (Казан, 1859, 525 бит) Мөхәммәт пәйгамбәрнең Җабәлка шәһәренә бәйле вакыйгалары тасвирланган. Әлеге легендар шәһәрләр,

рухани галәм арасында бер нурани галәм материясе» дигән.

Без әйтәбез ки, рәсүлулла бу галәмдә пәйгамбәрлек ирештереп, бигрәк тә боеру – бу дөньяда, гъад кавеме – бу дөньяда, шулай ук яэҗүҗ-мәэҗүҗ шәһәре – бу дөньяда, көнчыгыш тарафы – бу дөньяда. Нурани дөньяда көнчыгыш та, көнбатыш та юк, анда – тигезлек. Яки Җабәлкаһ берничә булсын, безнең дә күңелемезгә килә ки, гүя, Җабәлкаһ шәһәре – изге Болгар дип.

***

Һәм «Нисабел-интисар» каитабында болай язылган: [г*арәп телендәге өземтәнең тәрҗемәсе: «Сәедбаттал Газый «Төхфәтел-ләбаб» китабында болай дигән – Болгарда гъад кавеменең кешесен күрдем, ул 27 зирагтан (терсәктән) озынрак. Шул кеше атны, кечкенә сабыйны алган кебек кенә, култыгы астына кыстыра. Болгарның Башкорт дигән җирендә хәзер дә гъад халкы калдыклары бар. Болгар җирендә мөселман төркиләр яши, алар габбаси хәлифәләреннән әл-Мәэмүн һәм әл-Васикъ*[33] *Билләһи*

---

имеш, зөбәрҗәттән төзелгән һәм алар Каф тавы артында урнашкан дигән хәбәрләр дә бар. Ул калалар гъад кавемнәренеке дигән сүзләр очрый. Төзелешләре буенча һәр тарафы унике мең фәрсәх озынлыгындагы, камиллекне символлаштырган квадрат шәкелендә, аларның 12 мең капкалары булып, кыямәт көненә хәтле 12 мең кеше саклый. Кайбер чыганакларда ул шәһәрләр җисмани түгел, ә образлар дөньясында («галәмел-мисал»), башкаларында, имеш, ике дөнья арасында урнашканнар дип аңлатылган. Суфичылыкта бу шәһәрләр чынбарлыктагы дип тасвирланган. Гомумән, әлеге ике серле кала суфичылыкта киң яктыртылган. Аларны Әфганстандагы Бәлх һәм Һерат шәһәрләре белән тәңгәлләштерү омтылышлары да булган.

[33] *әл-Мәэмүн* – 813–833 елларда габбасилар хәлифәсе булган Әбелгаббас Габдулла ибне Һарун әл-Мәэмүн (786–833). Әл-Васикъ Билләһи – 842–847 елларда идарә иткән габбаси хәлифәсе. Шушындый ук мәгълүматны Ш.Мәрҗани «Рисаләтел-интисаб» китабыннан күчергән: «Болгар җире – мөселман төрекләре иле. Алар Габбасилар хөкем сөргән заманда Мәэмүн һәм Васикъ биллаһ хәлифәлеге вакытында мөселман булдылар; икенче мәртәбә әл-Каим Би-әмриллаһ хәлифәлегендә утыз мең йорт мөселман булды» (*Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар..., 1989. – Б. 54, 134*).

*заманында ислам динен кабул иткәннәр һәм әл-Каим Би-әмриллаһ*[34] *вакытында яңартканнар 30 мең сыркәү төрки кабиләләр.*

*Сыркәү – төрки телендә ир-ат җәмәгатеннән кардәше, агасы, балалары – барлыгы 100-дән 1000-гә хәтле. Солтан Сәбектәгин вакытында ислам динен кабул иткәннәренең хисабы юк (бик күп). Төркиләрдән ислам динен кабул итмәгән имансыз-кяферләрен үтергән»*].

***

Гъад бине Гауз бине Сам бине Нух пәйгамбәрнең буй озынлыклары йөз егерме аршын («Алты бармак»).

Татарча гъадне «арагыт», «гуҗ» вә «гыҗ» дип әйтәләр, «алыплар» дип тә әйтәләр.

Болгар һәм Казан халкы барча төрки, көрд кавемнәре белән Салих пәйгамбәр кулыннан һәм теленнән мөэмин булганнар. Ул заманга өч мең ел кичкән инде, хәзерге заман – һиҗри 1295 (милади 1878) ел.

Һәм тагын Болгар халкы Искәндәр Руми заманында мөэмин булганнар. Болгарның Искәндәр теленнән иманга килгән заманына ике меңдә ике йөз унбиш ел. Хәзер һиҗри 1295 (милади 1878) ел.

Янә дә Болгар халкы Җабәлкаһ исемендә булып һәм гъад кавеменнән булып, Мөхәммәт пәйгамбәр мигъраҗдан кайтканда үзе дәгъвәт итеп, алар кабул иткәннәр ки, меңдә өч йөздә биш ел үткән[35], хәзер һиҗри 1295 (милади 1878) ел.

Һәм тагын тугызынчы һиҗри (милади 630) елда өч сәхабә килгәннәр. Мәдинәи мөнәүвәрәдән килгән сәхабәләрнең исемнәре: Габдрахман бине Зәбир, Ханзали бине Рәбигъ, Зәбир бине Җөгъдә. Кара савытын – Зәбиргә, таякны –

[34] *Әл-Каим Би-әмриллаһ* – фатимыйлар хәлифәлегенең икенче хәлифәсе Әбелкасыйм Мөхәммәд ибне әл-Мәһди әл-Каим Би-әмриллаһ (893–946).

[35] 1305 һиҗри елны 1295 (1878) елдан киметкәндә 612 ел туры килә. Мөхәммәт пәйгамбәрнең мигъраҗ (җисмани һәм рухани күккә ашу) вакыйгасының төгәл елы билгесез, аны якынча 621 елда булган дип язалар.

Ханзалигә, чалманы – Габдрахманга биреп, өчесе ярдәм сорап – могҗиза булып, мөселман кылып киткәннәр[36].

Тагын хәзрәти Гомәр (Аллаһы Тәгалә аннан риза булсын) заманында һәм хәлифәлеге заманында Габдрахман сәхабә хәзәзийаннар белән бик сугышып, Дәрбәндтән чыгып, диваргача (яэҗүҗ-мәэҗүҗ чигенә хәтле) булган Бәләнҗәрне[37], Русь һәм Аланны – ике йөз юл кадәр фәрсәх җирне мөселман кылып киткән. Янә Мәсләмә исемле гарәп, Габделмалик бине Мәсләмә[38] Сәгыйдь әмере белән, гаскәр башлыгы (субашы) Турхан – Хәзәзийан (Хәзәр) халкы белән сугышып, мөселман итеп киткән.

Турхан сугышының урыны безнең күрше авыл – чуваш авылының Төрләмәс басуында «Турхан басуы»[39] диб әйтәләр – шунда булган. Төрләмәс авылы борынгы Зәршәр шәһәре кырында, Шуршу янында – Кызылъярда кала – Хәзәр шәһәре булган. Чувашча Зәршәр диләр. (Чувашлар

---

[36] Бу исемнәр һәм аларга бәйле вакыйга Мөслиминең «Тәварихы Болгарийә»сендә һәм Таҗетдин Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» әсәрендә телгә алынган. Соңгысының төрле күчермәләрендә Ханзали исеме Хантал дип тә язылган. Тугызынчы һиҗри елга нисбәт ителгән әлеге вакыйганы Минһаҗетдин Җәбәли нәкъ менә ул китаплардан алгандыр дип әйтеп булмый. Ихтимал, авторлар әүвәлгерәк, башка бер үк язма чыганактан файдаланганнардыр.

[37] *Дәрбәнд* – Каспий диңгезе буендагы борынгы мәшһүр кала, урта гасырларда «Бабел-әбваб» исеме белән дә аталган. VIII гасыр башыннан гарәп хәлифәлегенең Кавказдагы дини, хәрби һәм сәяси төп үзәге булган. Хәзерге Дагстандагы шәһәр. Бәләнҗәр – урта гасырлар чоры шәһәре. VII–IX гасырларда Хәзәр каһанлыгының эре үзәге, кайбер мәгълүматлар буенча – беренче башкаласы. Хәзерге Дагстан территориясендә.

[38] *Габделмәлик бине Мәсләмә* – дөресе: Мәсләмә бине Габделмәлик (739 елда вафат булган), өммәви хәлифе Габделмәлик ибне Мәрванның (646–705) улы, мәшһүр гаскәри җитәкче, 732 елда Дәрбәндне яулап, анда гарәпләрне урнаштырган.

[39] *Төрләмәс* – хәзерге Чувашстан Республикасының Козловка районындагы Төрләмә авылы. *Турхан* – тархан, аксөяк. Бу атама чувашларда «князь, би» мәгънәсендә кулланылган. Алар халык тарафыннан юлбашчы, хөкемдар һәм хаким итеп сайлап куелган зирәк акыллы, гадел һәм хөрмәт казанган кешеләр. «Турхан» атамасы белән бәйле урыннар чувашларда күп.

төрки халык булганга күрә, сүзләрендә авазларны төшереп калдыру күп, акыл ияләренә билгеле).

Чыннан да, гарәп гаскәренең урыны безнең Бәчек басуында бар – «Тугыз түбә» диләр. Өч йөз кадәр түбә урыны ки, гаскәриләрнең киез өйләренең урыны – «чатыр» диләр.

Тагын да Болгарны бер заман Кытайдан Чыңгыз хан чыгып яулап алып, күп халыкларны харап итеп киткән. Тамга салу аннан калган.

Бер заман Әфридун улы Тур хөкүмәтендә калган ки, «түрә» сүзеннән беленә, нәүрүз һәм чимек[40] үләне җыюдан беленә.

Тагын да Габбаси хәлифәләрдән Мәхмүт Сәбектәгин[41].

Һәм тагын Чыңгыз хан чыгып Болгарны, Мәскәүне басып алып, тамга салу гадәтен кертеп киткән.

Янә һиҗри сигезенче (милади XIV) гасырда фетнәсе булып, Аксак Тимер[42] үзбәк шәһәрләрен җимергән, юк иткән. Шул заманда беткән мөселманнарның хисабын Аллаһы Тәгалә үзе генә белә. Болгарның ничә мең шәһәрләрен һәм авылларын һәлак итеп киткән.

Шуннан качып һәм посып калган мөселманнары Казан шәһәрен төзеп, йөз ун ел яшәп, ул урынны яратмыйча, Казан

---

[40] *чимек* – «Семык» бәйрәме. Бу хакта тарихчы Г.Әхмәрев болай язган: «Рус халкының «Троица» бәйрәме вакытында «Симек» җыены була, татарча «Чимек» диләр. Славян халкының шул вакытта «Симек» бәйрәме булган, пасхаларыннан җиде атнадан соң булганга күрә, исемен дә «Симек» (семык) дип атаганнар». Әхмәрев әлеге – мәрхүмнәрне искә алу йоласының төрле халыкларда ничек үткәрелгәнен дә кыскача тасвирлаган (*Гайнетдин Әхмәрев: тарихи-документаль җыентык..., 2000. – Б. 39, 75*).

[41] *Мәхмүд Сәбектәгин* – газнәвиләр империясен нигезләгән солтан Яминеддәүлә Габделкасыйм Мәхмүд ибне Сәбектәгин (971–1030).

[42] *Аксак Тимер* – Урта Азия һәм Кавказ тарихында яулап алу сугышлары белән танылган Әмир Тимер, Тимерләң (1336–1405). Алтын Урданы тар-мар иткән, Иранга, Кавказ аръягына, Һиндстанга, Кече Азиягә һ.б. яу чапкан. Татар дастаннарында һәм риваятьләрендә Болгар шәһәрен җимерүче итеп тасвирланса да, анысы чынбарлыкка туры килми. Идел буена 1391 һәм 1395 елларда басып кергән, әмма Болгарны алганлыгы турындагы хәбәрләр чыганаклар белән расланмый.

елгасы тамагында Казан каласын салып, күчеп киткәннәр. Йөз елдан артыграк торганнар.

Һиҗри тугыз йөз алтмыш бердә чаян аенда (октябрьдә) 2 нче көн[43], якшәмбе көн, Казанны Мәскәү руслары алган. Казанда утыз мең мөселманнар гаскәре булган. Әмма руслар йөз утыз мең гаскәре белән килгән. Җиде ел сугышканнар.

Фар-фүрләр бөтенләй уйнамас булды,
Каһвәханәләрдә каһвәләр кайнамас булды.
Боҗырга дип тозак салдым,
Боҗырга дип тозак салдым.
Суер боты өзелде,
Суер боты өзелде.

Болгар һәм Казан тарафларында яшәгән төрле төрки һәм көрд кавемнәре (татарлар, чувашлар, чирмешләр, мукшылар, мордвалар, удмуртлар, мишәрләр, төмәннәр, башкортлар, нугайлар) белән [руслар арасында] өч мәртәбә бик зур сугыш булып, халыклары аз калып һәм шәһәрләре юкка чыгып, исемнәре беткән ки, аларның җирләрен «үле җир булган» дип әйтәләр борынгы заманда.

Хакыйкатьтә, Болгар өч мең елга якын заманнан бирле бар шәһәр ки, күпчелек калалары үзбәк шәһәре диләр. Чынлыкта да, Болгар тарафында кала, шәһәр, ныгытма урыны чиксез күп ки, шулар җөмләсеннән мәшһүрләре: Бүләр, Кече Болгар, Сәмәндәр, Бараҗ шәһәре һәм Казан шәһәре.

Безнең Тау ягында Зөя буенда дүрт кала бар: берсе – Кири авылы янында Кошман шәһәре, янә берсе – Өтәк авылы янында Казан шәһәре, тагын берсе – Борындык янында Белыйби каласы, янә берсе – чуваш авылы янында Зәршәр авылының басуында – Хәзәр шәһәре. Мөселман зиратлары күп.

Болгар шәһәренең һәлак булуы – Чыңгыз хан белән сугышып бик күп беткән һәм Аксак Тимер бөтенләй җимергән. Һәм тагын рус шулай ук харап иткән. Хәзер Болгар халкы бик аз

[43] Һиҗри 961 елның 2 нче гакъраб (чаян ае) милади белән 1554 елның 23 октябренә туры килә. Елның дөресе – 1552 елга туры килә торган һиҗри 959 ел булырга тиеш.

калган. Әмма Болгар тарафында төрле халыклар да бар, хәзер татарлар эченә кушылган.

«Татар» дигән сүз татарча «татар», әмма гарәпчә «тәтар» диләр.

«Татар мәмләкәте мәшһүр, аннан бик хуш исле матдә килә һәм ул мәмләкәттә яшәгән төркиләр дә «татар» дип атала» («Тибъян нафигъ»).

Иске тарих китапларында Болгар халкын Дәште Кыпчак, Болгар, Кырым, Казан, нугай, сакъләб, хәзәзийан, хәзәр, үзбәк татары, Тур һәм төрки нәселе диләр. (Кайбер риваятьтә «сакъләб» дип әйтү – дөрес түгел, диләр).

Фарсы халкы да «татар» ди һәм күпчелек «үзбәк» диләр. Аеруча, Бохараи шәриф халкы – сартлар, таҗиклар, үзбәкләр – «татар» диләр. Әмма төрекмән халкы, хивалылар «татар» диләр һәм «Болгар халкы» диләр. Сарт халкы, Куканд һәм Ташкентлар «нугай», «татар» һәм «үзбәк» диләр. Шулай ук төрекләр (Госманлы халкы) «татар» диләр.

Әмма «татар» атамасы борынгы сүз, кушылган мәгънәсен тикшереп ачыклау бик мөшкел булып, ихтималга якын фаразлар булса да, сүзлек һәм тарих китапларында исем һәм гыйлем мәгънәсеннән башка аңлатмасы булмыйча, фәкать бер вилаять һәм бер кабиләгә исем булганын белдерүләреннән, махсус мәгънәне белдергән вилаять дәрәҗәсендә булып, борынгы заманда бер кеше исемен белдерсә дә, вакытлар узу белән күп балалары туып, төрле кабиләләрне һәм бер чиксез җәмәгатьне тәшкил итеп, дөньяга таралуларыннан, гүяки, татарлар ярты дөньяны һәм җир шарының яртысын биләп алып, аларны белмәгән кеше булмаса да, һаман хакыйкатьләрне бәян итү һәм барлыкка килгән урыннарын аңлату-белдерү зарури булуы бу заманда көн кебек ачык, һәр нәрсәне төшендерү таләп ителә.

Татарларның рухларын солтан Хуҗа Әхмәт Ясәви[44] хәзрәте

[44] *Хуҗа Әхмәд Ясәви* – Урта Азиядә яшәгән мәшһүр суфи шагыйрь (1166 елда вафат булган) Әхмәт Ясәви.

(аңа Аллаһы Тәгаләнең киң рәхмәтләре ирешсен) бәян иткән: «Көнбатышта – христиан, уртада – яһүд, көнчыгышта – татар».

Төркестанда иҗат ителгән «Бакырган китабы»:

Сөбхан Аллам үзедер
Ул Мостафа боерды.
Бабам Арслан тигерде,
Шәйхем Әхмәт Ясәви.

Мостафаның киемен
Киде, капты нигъмәтен,
Тотты Кәгъбә боҗрасын
Шәйхем Әхмәт Ясәви.

Бакса – Кәгъбә күрәлгән,
Басса – җирләр төрелгән,
Илаһи гыйлем бирелгән
Шәйхем Әхмәт Ясәви.

Асылы аның ханнан,
Белмәс аны күп надан.
Белер аны Хак Сөбхан,
Шәйхем Әхмәт Ясәви.

Исхак бабаның җирен,
Шәех Ибраһим колын,
Шәехләрнең олугы
Шәйхем Әхмәт Ясәви.

Яссы суының арасы,
Ятар гәүһәр парәсе.
Ишаннарның олысы
Шәйхем Әхмәт Ясәви.

Карчыганы кушлаган,
Шонкар, лачын учлаган,
Сансыз мөрид башлаган
Шәйхем Әхмәт Ясәви.

Шәригате тәртипле,
Тарикате береккән,
Хакыйкатьтә килешле
Шәйхем Әхмәт Ясәви.

Көн туганнан батарга,
Кяфер, яһүд, татарга,
Коллык кылып сатарга
Шәйхем Әхмәт Ясәви.

Унсигез мең галәмдә,
Аты мәшһүр телләрдә,
Үзе Дарес-сәламдә
Шәйхем Әхмәт Ясәви.

Баблар бабы – Хорасан,
Сансыз төмән – Һиндстан.
Бабалар башы – баба Арслан,
Шәйхем Әхмәт Ясәви.
Атам аты азасы,
Җофар булып тузасы,
Ике җиһан көзгесе
Шәйхем Әхмәт Ясәви.

Хәзрәт белән юлдашлы,
Ильяс белән иптәшле,
Хакъ каршында хөрмәтле
Шәйхем Әхмәт Ясәви.

Төркестанга барсаңчы,
Хезмәтендә булсаңчы,
Өлеш бирсә, алсаңчы,
Шәйхем Әхмәт Ясәви.

Баба Мачин – ул солтан,
Мөрид булды шөбһәсез,
Хәким хуҗа Сөләйман[45]
Шәйхем Әхмәт Йәсәви.

Әйтелгән татарларның җәмәгать һәм җөмһүриятләре Кытайның төньяк тарафында булган борынгы Татарстан җирендә барлыкка килеп һәм аннан чыгып, Амур елгасының Татар диңгезенә койган җир «Татарский пролив» – «Татар бугазы»ннан үтеп, көнчыгыш җирендә Монгол, Чин-Мачин һәм Кашгар, Зәмин, Тибет, Төмән, Һиндстан һәм Һиндкытай тарафларына татарлар китеп, бер төркем татарлар Туран, Төрек, Уган, Әфганстан һәм Бәлүҗистан тарафларына кадәр барып, Иран мәмләкәтендә Көрдстан җире һәм Госманлы дәүләтендә булган җирләрдә: Мисыр, Йәмән һәм Рум иле тарафларында, Болгарстан һәм сакъләб, лях, поляк һәм чех, немец, венгр (Венгрия) тарафларында татар бар. Һәм Алмания (Алан, Иланд), һәм Русь, Бәләнҗәр, Белоруссиядә, яэҗүҗ-мәэҗүҗ диварына хәтле таралып, бер өлеше борынгы материктан яңа кыйтгага – мәшһүр Американың Төньяк Америкадагы инглизләр мәмләкәтенең кардәше арасында таралулары уйланыла. Аерым алганда, Япониядә шафигый мәзһәбендә яшиләр, диләр. Татар диңгезеннән кичеп, утраудан-утрауга күчеп ирешкәннәр.

Татарлар күп төркем, нәселләрдә булып, хәзерге заманда баштагы татарлыкны белү бик читен булса да, иске тарих китапларындагы хәбәрләр һәм «татар» сүзе сүзлек китапларында әйтелгәнлектән, татарларның бик иске авыл һәм борынгы сүзләреннән беленә ки, татарлар бу заманда төрле телләргә һәм

[45] *Сөләйман* – бу шигырьнең авторы, Урта Азиядә яшәгән мәшһүр суфи шагыйрь (1186 елда вафат булган) Сөләйман Бакыргани. Аның әсәрләре татарларда дәреслек буларак кулланылган.

төрле киемнәргә ия, төрле мәскәнә, бик төрле кыяфәт һәм төсбит барлыкка китереп, төрле-төрле мәмләкәтләргә сәфәрчелек, күршелек итеп һәм бик сәяхәт итеп, чит халыклардан төс-кыяфәтне алганнар. Тышкы караш буенча, бу заманда булган татарларны борынгы хан заманында булган татарларга бик читят халәттә һәм кыяфәттә күренәчәкләре көн кебек ачык булганлыктан, гүяки, татарлар бу заманда татарлыктан чыккан кебек.

Әмма Казан һәм Болгар татарларының табигатьләрендә ваемсызлык урнашкан, «Тәзкирәтел-хөкем табакател-өмәм» китабында әйтелгән кебек. Татарлар бик төрле исемдә: монгол татарлары диләр һәм кимәк татарлары ...[46] диләр һәм ... татарлары һәм ... татарлары, кыргыз татарлары. Хәзәр (хәзәз, хакан, һәзар, Чине фәгъфур) дә Шәрыкнеке булганлыктан, шул мәгънәне белдерә.

Һәм тагын татарларның табигатьләре чит халыклардан гаҗәп төс-кыяфәтне алырга бик кызыга ки, борынгы заманда алар күчеп йөрүче халык. Бу замандагы кыргызларның үзләре дога кылганда үзгәргән, алыштырылган нәрсәләре һәм авазларны бозулары кебек. Бу заман күпчелек сүзләре русча, бигрәк тә, наданлыкта калган гади халыкларында. Әмма югары сыйныф вәкилләреннән бер өлеше Урта Азия һәм госманлы теле белән сөйләшүчеләре бар.

Хан заманында – Болгар һәм Казан хөкүмәте заманында – татарлар һәрбер төре белән Рум җирендәге һәм Кырым, Кавказ халкы кебек сөйләшкәннәр. Чөнки Болгар халкы барысы төрле көрдләр һәм төркиләр ки, кием-салымда һәм сөйләмдә, йортҗир әйберләрендә асыл төркилекләре күренә.

Хәзерге вакытта Казан татарларының иске һәм борынгы телләрендә чуваш, чирмеш, мукшы, ар халкы сөйләшәләр. Борын заманда, хан заманында һәркайсы чуваш киеме һәм теле кебек булганнар.

Хәзерге Казан җирендә мөселман татарларының авыл исемнәре чуваш теленчә: Орымширмә, Караширмә, Икширмә,

[46] Кулъязманың бу җөмләсе кәгазь читендә язылганлыктан, бик таушалган, сүзләре беленми.

Мулчирмә – болар барчасы Мишә суы буенда. Әмма Тау ягында чуваш авылларының исемнәре бу заман Казан татарларының телендә ки, мәсәлән, Шигали, Кызылъяр, Төшкилде, Туктамыш, Айдар, Куак авылы, Җөлки. Казан җирендә авыллар: Мәмәш, Мөндеш – чирмеш теле кебек. Мәчкәрә һәм Яңгул – ар теле, тагын Пыжмара һәм Шода. Тау ягында чуваш авыллары: Әҗбәбә – Хаҗи баба, Зәршәр – Хәзәр шәһәре, Алибучы – Гали башы һәм башкалары шулай ук Казан татары теле белән. Чуваш һәм башка болгар халкының телләре катышып беткән ки, борын заманда бер тел һәм бер сөйләм булган.

Каранширмә дигән сүз, «кара» сүзе мәгълүм – төркичә һәм татарча, әмма «ширмә» дигән сүз «чирмә» дигән сүз ки, татарча «җырма» һәм «җырмак» диләр, төрекчә «җырмак» һәм «йырмаг» диләр. «Орым» дигән сүз «озын» дигән сүз, саф хәзәр (һәм чуваш) теле. «Икшермә» – «Ике җырма», «Мулчирмә» – зур һәм мул чокыр, җырма.

Аз гына башкалык белән сүз башка тел кебек күренә һәм белeнә. Әмма гыйлемле кеше тизлек белән аңлый. Тау ягында күпчелек чуваш, мишәр, мукшы халкы булып, алар борынгы заманнан калган төрки тел белән сөйләшсәләр дә, вакытлар үтү белән сүзләрендә бик төрлелек бар. Әмма дөнья күргән кеше тиз аңлый, мәсәлән, Тау ягындагы татарларның надан адәмнәре «шәһәр» дигән сүзне «шәр» дип сөйләшәләр, «карыз» (бурыч) дигән сүзне «карыч» дип әйтәләр, «бәхет» дигән сүзне «бәкыт» дип әйтәләр, «талига (бәхет) йолдызы» дигән сүзне «тәлдәй» дип әйтәләр. «Яхшы» дигән сүзне «җакшы» һәм «якшы» дип әйтәләр. Әгәр дә асыл төрки китапларын күрмичә торып, наданлыкта калсалар, йөз елда тәмам телләре башкага әверелеп, татарлыктан чыгып, башка кавем булып беленерләр иде, бу заманда чуваш халкы хакыйкый төркиләрдән була торып та, башка кавем һәм башка халык булып күренгәне кебек. Чынлыкта, алар хан заманында мөселман булганнар. Әмма аларның телләре буенча тәмам хакыйкый төркиләр. Чирек телләре русча ки, дүрт йөз елдан бирле бу як мөселманлыкны ташлаганнар, Русия басып алу белән. Юкса, алар (ягъни, чу-

вашлар) тугыз йөз елга якын мөселман булып торганнар.

Чуваш авылларының янында ташландык иске, борынгы мөселман чуваш зиратларында күренгән ташларның датасы белдерә. Җөмләдән чуваш авылы Шигалида[47] мөселманнар бар ки – унике йорт. Зиратларында булган бер ташта Коръәннән изге аятьләр язылган, сугышта шәһит булган чуваш ки. Астагы юлларында «тарихе һиҗрәт йөз кырыкда рабигыль-әүвәлдә Әсәд кяфер кулындин шәһид булды, һичбер кеше кайсы җирдә үләчәген белми»[48] дип язылган, госманлыча һәм пашаларча язулы. Икенче ташта «һичбер кеше кайсы җирдә үләчәген белми» дип язылып, һиҗри «тугыз йөздә Әсәди угылы Тенеш кяфер кулыннан шәһид булды». Бу язу белдерә ки, әлеге Шигали авылы мең ел мөселман булып, аннары наданлыкта калганын белдерә һәм ислам динен ташлаганлыкларын аңлата.

Бу зиратка өч авыл җирләгән: Тегеш, Кызылъяр[49], Шигали. Һәм башка авылларда тагын да моның мисалы күп. Һәм моңа охшаш чуваш авыллары мөселман зиратларын ташлап, христианлыкны кабул иткәннән соң башка зират булдырсалар да, һаман үз хәлендә зиратлары мәгълүм һәм ташлары күп, һәммәсе күпчелеге һиҗри тугыз йөз (милади XVI гасыр).

Бу зиратка өч авыл халкын җирләгәннәр һәм хәтта өчәр көнлек җиргә, кавем-кабиләсе булса, китереп җирләгәннәр. Ислам гадәтләре буенча, «Шәрхе әрбәгыйн» китабында язылган кебек ки, [*бу урында мәрхүмне җирләү һәм каберенә билге өчен таш кую турында пәйгамбәрнең гарәп телендәге хәдисе язылган*].

---

[47] *Шигали* – хәзерге Чувашстан Республикасының Урмар районындагы Иске Шигали авылы.

[48] *һичбер кеше кайсы җирдә үләчәген белми* – Коръәннең «Локман» сүрәсендәге 34 нче аятьнең мәгънәсе.

[49] *Тегеш, Кызылъяр* – хәзерге Чувашстан Республикасының Урмар районындагы чуваш авыллары. Риваятьләр буенча, Шигали, Кызылъяр һәм Тегеш авыллары Болгардан килгән кешеләр тарафыннан нигезләнгән. Чуваш галимнәре язганга караганда, Кызылъяр авылын татарлар нигезләгән һәм ярты халкы мөселман (татар), яртысы мәҗүси (чуваш) булган.

Хан заманында чувашлар барчасы хак мөселман һәм хәзәр (хәзәзийан) халкы һәм төрки нәселе, бәлки хакыйкый төрки булуларын ташлаган һәм ташланган зиратларында булган кабер ташлары белдерә ки, ул бичаралар борынгы заманда мең елга якын мөселман булып торганнар.

Кабер өстенә таш кую – пәйгамбәр сөннәте һәм кавемнәселләрне бер зиратка җирләү дә – пәйгамбәребез сөннәте. Борын заманда чувашларда һәммәсе бу фигыльләре булган. Зиратлар һәм фигыльләре, тел һәм сөйләмнәре белдерә, апачык мәгънә – чувашларның ташлаган зиратларында булган ташларның күбесендә рус белән сугышу вакытында бәрелештә шәһит булган чувашлар ки, алар борынгы хан заманында мөселман булганнар.

Һәм тагын хәзер дә ашаганда һәм чимек теләүләрендә кирәк бай, һәм кирәк фәкыйрь – бөтен чуваш халкы «бисмилләһи» һәм «исме Аллаһи», «исмилләһ» белән ризык авыз итәләр һәм һәрбер эшкә керешкәндә дә. Һәм тагын кыз никах итеп алганда мәһәр билгелиләр. Һәм тагын җомга көнне «азна көн» дип (ягъни, «азинә» – төрки теле), бәйрәм дип шатланалар. Ләкин поплар бик тыялар.

Һәм изге Болгарда ташларның күбесе чуваш теле белән язылып калганыннан бәлки Болгарның төп халкы чуваш булса кирәк дип аңлашыла. Һәм чувашларның бик зур һәм галим, зур укымышлы адәмнәре булган: Әҗбаба дигән чуваш авылында булганы Хаҗи баба һәм ике Әренкә, Шулкан, Акъегет авылы, Бакырчы күле, Җуансы, Ырмар[50] җирләгән зиратта булган таш

[50] Автор бу җөмләләрне буталчыграк язган. Чөнки монда күрсәтелгән атамаларның барысы да чуваш авыллары түгел. Әҗбаба һәм Ырмар (Урмар) – Чувашстанның Урмар районындагы чуваш авыллары. Ә Әренкә, Шулкан дигәннәрен ачыклый алмадык. Әренкә дигәндә, бәлки, хәзерге Яльчик районындагы Аранчы авылы күздә тотылгандыр. Бакырчы һәм Акъегет – хәзерге Яшел Үзән районындагы татар авыллары. Чувашстандагы Иске Урмар авылы да элек Акъегет исеме белән йөртелгән. Җуансы дигәндә, бәлки, Яшел Үзән районындагы Юынчы (Сөнчәләй) авылы күздә тотылгандыр. Һәрхәлдә, бу атамаларның дөрес вариантлары шул төбәктә яшәүчеләргә мәгълүмдер. Иске Урмар (Акъегет) авылы зиратында 1736 (һиҗри 1149)

һижри тугыз йөзенче ел (милади 1494 ел), Мөхәммәд Чәләби[51] ки – госманлы телендә унике фәнне үзләштереп, тәкъва, суфи Алла бәндәсе дигән сүз. Чөнки асыл гарәпчәдә «җәләб» һәм «чәләб» диләр, Аллаһы Тәгаләнең исеме (әмма «Аллаһы» – гарәп теленчә), Чәләби сүзе сөрьяни теленнән, Ходай һәм Тәңре мәгънәсендә.

Китапларда язылган, бер заман Мәскәүнең урыс халкы Казанны басып алу нияте белән чыккан ки, һижри тугыз йөзенче елдан[52] бераз әүвәлрәк, гаскәрен йөз утыз мең кадәрледән ким кылмаган. Әлеге гаскәрнең йөреше бу юлы Хәзәр шәһәре, хәзәр (хакан) халкы – чувашларга туры килеп, алар белән алтмыш-җитмеш ел микъдары сугышканлыкларын белдергән ташлар бар. Чуваш халкы өсләрендә җитмеш ел буе рус гаскәре басып яткан. Чувашлар рус белән сугышып, руслар җиңеп, чувашның күп кешеләре шәһит булганлыкларын әйтеп үтелгән ташландык зиратлары белдерә.

Әмма рус гаскәре басып ятканда чувашларны тоташ христианлаштырырга вакытлары булмыйча калып, чувашлар исламнан аерылып һәм мәҗүсилектә калганнар. Мөселман булган заманнарында да мәҗүсилек галәмәтләре бар иде. Чөнки барлык татарлар да, көрдләр дә һәм төркиләр дә – Болгар ягында яшәгән халык, гъад кавеме булганлыкларыннан, гъад кавемнәре утка табынучы булганлыктан һәм кирәмәт[53] тоту һәм уен-җыеннарны кабул итүдән пәйда булып җиһанга калыккан.

Олы галимнәр тыйсалар да, барысы да тыелмыйча, кайбер урыннарда килеп чыгу шиге бар ки һәм чыга да. Мәсәлән, гореф-гадәттә мөселман татарның гъад һәм Әфридун хөкүмәте заманыннан калган фигыльләре – кирәмәт тоту бар. Кайбер

---

елгы һ.б. мөселман кабер ташлары бар икән.

[51] *Мөхәммәд Чәләби* – Каюм Насыйри язганнарга караганда, мондый исемле изге кеше үзе Әҗбаба авылыныкы булып, Бакырчы зиратында җирләргә дип васыять әйткән һәм аның XVI гасырда куелган кабер ташы хәзергәчә сакланган.

[52] Һижри 900 нче ел милади буенча 1495 елга туры килә.

[53] *кирәмәт* – Идел буе халыкларындагы мәҗүсиләрдә келәү (табыну) һәм корбан китерү урыны (гадәттә, изге агачлык).

кешеләрнең келәтләрендә капчык һәм янчык белән акчалары күп, яз көне нәүрүз әйтеп йөрү кебек һәм тагын Олы көндә (Пасха бәйрәмендә) уттан сикерешеп чыгу кебек Әфридун гамәле. Чимек көне бәйрәм ясап, чимек үләне җыюлары, борын заманда кыз һәм хатыннар ахшамнан соң җыелышып, урманга барып чимек үләне җыеп кайтып, ул үләннәр белән госел коенулар кебек. Адәмне сәламәт кыла дип, Олы көндә чәч тарамаслар иде. «Олы тәре козылган» көн дип, ел да бер бәйрәм ясап, сиксән камәт вә сиксән илек белән җаннар кабердән чыкканын карау кебек. Һәм карга боткасы бәйрәме ясап, бер егет атка менеп, өй саен берәр йомырка җыеп, күп булгач җыелышып ашаулары кебек, сабан туйлары кебек. Тау ягында сабан туй өй саен сыра эчеп йөреп, арттан кызыл йомыркалар өләшү кебек. Болар барчасы – Тау ягының һәм башка татарларның гъад кавеменнән һәм Кабил[54] балаларыннан калган нәрсәләрдер. Аеруча, Әфридуннан калганнары бар бер өлеше.

Руслар Казанны алгач мөселманнарны бик тарлык кылган ки, хәзерге мөселманнар тау-чокыр арасында качып калып, бүген килеп чыгып, күп булганнар.

Хәзер мөселманнар күп булганнар. Уйга китерик, әгәр татарларны ислам диненнән тыйсалар, Алла сакласын, берүк сакласын, һич диндә бик чыдамлы булмасалар, әлбәттә, аларның кайберсе чуваш кебек кирәмәт һәм башка нәрсәләрне иҗат итәрләр. Бара-бара, һәммәсе мәҗүси кебек булырлар, ничек ки Мәскәү чувашлар өсләрендә ятып, ислам гамәлләрен үтәргә рөхсәт бирмичә һәм чукындырмыйча, мәҗүси кылганнар. Аларның мәҗүси булганлыкларына якынча дүрт йөз ел бардыр. Алай да, чувашларның кайбер авылларында мөселманнары бар ки, әйтәләр: «Безнең чуваш һәм чирмеш һәм башка борынгы халыклар хан заманында барчасы мөселман булганнар», – дип. Чувашларның мөэминнәре, ягъни чукындырмыйча һәм мәҗүси булмыйча калганнарының исемнәре – Әлмәмәт, Бикми, Шили, Заид һәм башка, кыз-хатыннары –

[54] *Кабил* – Адәм пәйгамбәрнең улы.

Шәрбостан, Гөлбостан вә Сафиябану. Болар ислам динен тота алмаганлыктан, күбесе христианлашалар. Һәм руслар аларны бик тикшерә. Алар җавап бирәләр: «Адәм пәйгамбәр дине һәм Турхан динендә» – дип. Юкса аларны бер калыптан сугып, христиан кылалар. Алар иске бабаларын бик сагыналар.

Чувашлар дүрт йөз елдан бирле ислам динен тотарга мөмкин булмаганлыктан, күпчелеге мәҗүсилектә күрелеп, урыс халкы әйтә: «Чуваш халкы аерым кавем һәм кыяфәте башка, гаҗәеп гореф-гадәтле һәм ят сыйфатлы, Казан татарларыннан башка кавем, борын заманнан ук мәҗүси һәм икенче халык» дип, «язычный вера»да булганнар дип әйтәләр. Хәзер чувашлар татар булып һәм мөселман булып бетәләр дип, бик тикшерәләр.

Руслар белмиләр – чуваш халкы хан заманында татарлар кебек мөселман булганнарын, руслар: «Хәзер генә фәлән татар авылы чуваштан татар булган», – дип әйтәләр. Тагын да соңрак әйтерләр – «Барча татар чувашдан», – дип.

Инде без – мөселман татарлар әйтәбез: чувашлар бөтенесе татардан дип һәм бөтенесе төрки (хәзәр, хәзәз, фәгъфуре Чин, вә хакан) халкы, Болгарның төп халкы! Электән мөселман булганнар, мең ел мөселман булып торганнарын искә алынган ташлар әйтә. Һәм тагын да фигыльләре һәм киемнәре әйтә. Күптән түгел аларны рус көчләп христианлаштырмакчы булып, мәҗүси ясап киткәннәр. Хәзер русның исенә төшкән христиан кылу нияте, чувашларның исенә төшкән ислам нияте.

Чувашлар әйтәләр: «Безнең бабайлар барчасы хан булганнар, – дип, – һәм мөселман булганнар», – дип. Кайда калды болгар белән чуваш арасы? Чувашлар зиратларын күреп бик елаучылары бар.

Кайбер түбән кеше аларны чын христиан дип белә. Аларда христианлык та, мөселманлык та һәм яһүдлек тә юк. Мәҗүсилектән башка мәгънәләре юк. Гъад заманындагы халәтләренә кире кайтып, мәҗүси булып калганнар.

Ләкин алар исламга бик сәләтле. Хан заманында чуваш һәм

чирмешләр, мукшылар һәм удмуртлар – һәркайсы мөселман булганнар. Аларның мәҗүсилекләре дүрт йөз ел вакытында. Юкса, Болгар халкы төрле төрки һәм көрдләр булган ки, югарыда сүзләрнең рәвешенчә һәм мәгънә ягыннан аңлаттык – алар саф мөселман булып, биләр (һәм бикләр) белән вакытлар кичергәннәр. Иске замандагы кешеләрнең исемнәре татарча: Тәтеш баба, Чуаш бабай, Кармыш бабай, Мукшы бабай, Мамадыш бабай, Лаеш бабай, Чирмеш бабай, Малмыж бабай, Бутяк бабай, Ар бабай. Тау ягында авыл исемнәре: Мамадыш, Кармыш, Күгеш, Багыш, Даныш, Борнаш, Үтәмеш. Казан җирендә: Юртыш, Әрнәш, Кош, Лаш, Мөндеш, Мәмәш, Чирмеш Иле. Мишә елгасы буенда: Караширмә, Орымширмә, Икшермә, Бүлчирмә, Кайынсар. Тау ягында: Шуширмә, Чирмешән, Кошман, Сатмыш, Карамисар. Чуваш авыллары: Җәмәш, Тугаш, Куак авылы һәм башкалар – барчасы төрки теле, борынгы хан заманындагы сүзләр, барчасы кеше исемнәре. Хәзер авыл һәм кавем исеме булып калганнар. Әүвәл татарның күпчелек сүзләренең ахырында «ш» авазын кулланганнар ки, төркиләрне шулай белгәннәр. Чуваш, чирмеш һәм мукшы – чын төркиләр.

Казан татарларының да телләрендә аерым-аерым берәр тел белән сөйләшәләр, авыл белән авылның арасында сөйләм телендә шактый аерма булган кебек. Әмма төрле көрд һәм төрки кавемнәреннән торган Болгар халкы бер-берсенең телләрен бик дус күрәләр. Аерымлыкның табигый дәрәҗәсе булса да, асыл бер аерым кавемнең телләрен үзләре бик яхшы дус күреп, «менә бу безнең тел» дип әйтәләр.

Телдә чувашлар, чирмешләр, мукшылар, мишәрләр, төмәннәр һәм башка Болгар халкы арасындагы аерма аларның бер-берсенә ят кавем икәнлеген исбат һәм дәлил кылмаганлыктан, табигый һәм асыл нәрсә белән очраклы һәм алынма әйбернең билгеләре аерылып тора һәм үзенчәлеге ачыктан-ачык. Әйтик, рус телендә шушы халыклар бөтенесе сөйләшсәләр дә, ләкин һәммәсендә очраклы һәм алынма рәвештә. Шулкадәр бар ки, кайбер алынма тел дә табигый һәм тамак төбе белән сөйләшә торган тел кебек була – күбрәк

сөйләшүдән һәм күбрәк кулланудан һәм хәтта бер халыкның бер теле вакытлар узу белән бөтенләй үзгәрәчәге көн кебек ачык. Татар теле бу заманда бер тел һәм бер кавемнең эчендә ничәмә төрле авазлар һәм үзгәреп, киңәеп, сөйләмдәге авазларда ничаклы тармаклар пәйда булган ки – гыйбрәт иясе хәйран калырлык. Мәсәлән, бер тел ки: «бу йиргә кәл», төрек дияр – «бурадә гәл», татар әйтер – «бу җиргә кил», чуваш әйтер – «кунда кил». Һәммәсе болар бер кавем. Безнең гыйлемебездә һәм аңыбызда адәмнең теле һәм сөйләме, тел тәэсире һавадан һәм климаттан. Аннан хасил булган нигъмәтләрдән табигатькә бер төрле рәвештәгесе барлыкка килгәнлеге аңлашыла ки, экватор тарафларында көн һәм төн һәр заманнарда бертигез булган кебек. Әмма экватордан ераклашкан саен һәрбер минутта үзгәреш һәм башкалык бар. Төн һәм көн бик озын, хәтта 2 төннән артык көн булыр кебек, табигатьләрендә шулай ук артык кимчелек булып, телләрендә дә шулай ук. Суык һаваның телгә тәэсире ачык әйтелә торган сүзләрне бозып сөйләштергән кебек. Әмма татарлык, төреклек һәм руслык, французлык һәм башка милләткә нисбәтлелек асыл нәсәбнең тармагын асылдан башка бер халәте белән чыгуын аңлата. Һәм хәзрәти Адәм пәйгамбәрнең нәселен фәләнчә тармакта исемен дә, барлыкка килгән урынын да бер хас исем белән белдерү – һичбер дингә бәйләнешен аңлатмый. Гыйлем ияләренә һәм тел белгечләренә көн кебек ачык мәгънә ки, ул башлангычта ук төгәл санала.

Кайбер түбән һәм надан кешеләр әлеге исем белән, үзләрен белдекле күрсәтеп, шулай ук мактанып һәм тәкәбберләнеп, татарлар арасында «Мин – татар!» дип әйтә ки, максаты – мөселманлык. Әй-һай! «Татар» дигән сүз мөселманлык яки христианлык, яһүдлек яисә мәҗүсилекне түгел, ә бер аерым халыкны белдерә. Әмма мөселманлык йөрәк белән раслап һәм телдән икърар итеп, мөселман гамәлен ачык үтәсә һәм иман иңдереп нурландырса, тәгаен ул затны «мөселман» дибез. Кирәксә француз халкыннан булсын, кирәксә гарәп милләтеннән булсын, кирәк рус таифәсеннән булсын һәм

кирәксә чуваш булсын – безнең пәйгамбәребез Мөхәммәт мостафа һәммә җиһан әһеленә гомуми пәйгамбәр ки, «Син булмасаң, бу дөньяны барлыкка китермәс идем»[55].

Әмма Болгар халкы арасында төрле халыклар җирләшкән: гарәп, фарсы, төрек, көрд һәм Рум, Кытай, Урта Азия халкы һәм сакъләб халкы. Ляхстан халкы лях-поляк, Чехстан халкы чех, немец һәм венгр халкы. Шулай ук төрекмән, чыгытай, олунгалы, Кашгар, Зәмин халкы да бар һәм Һиндстан халкы да бар. Рум иле һәм Бәгъдад халкы да бар – боларның барчасын бәян кылабыз һәм аңлатабыз.

Әүвәл белергә кирәк ки, асыл адәм Һиндстанда[56] булса да, Нух пәйгамбәрдән соң өч урыннан чыкканнар һәрбер җиргә һәм һәрбер төрле сәбәп белән, Ходай Тәгалә үзе белә.

Гарәп, рум, фарсы һәм тагын Үзәк Азиядә булганнар Самга нисбәтле. Нух пәйгамбәр үзе исән чагында балаларына җир йөзенең кешеләр яшәргә яраклы дүрттән бер (коры җир) өлешен бүлеп биргән ки: Шам шәһәрен һәм гарәп ярымутравын, Гыйракны, Фарсыны һәм Хорасанны. Үзәк Азияне Самга бирде, чөнки ул балаларыннан иң хөрмәтлесе, өстенрәге һәм турылыклысы иде. Сам балалары Үзәк Азиядән чыкканнар.

Һәм Чин-Мачинны, Төркестанны Яфәскә бирде, шулай ук төркиләр (хакан) һәм яәҗүҗ-мәәҗүҗ Яфәскә нисбәтле ки, көнчыгыш илләрдә күпчелек ватаннары булып, Шәрыктан чыкканнар. Әмма көнбатыш илләрен, Зәнзибарны һәм Хәбәшне, Һиндстанны бирде кара тәнлеләргә, һиндкә, зәнзибарга, хәбәшкә, Судан да – Хам нәселеннән. Хам балалары Африкадан һәм Һиндстаннан чыккан.

Әмма югарыда әйтелгән Болгар мәмләкәтләренә гарәп кавемнәре хәзрәти Гомәр заманында дәгъвәт өчен килеп һәм сугышып, һәм яшәп калган гарәпләр татарлар эчендә урнаш-

---

[55] Ялган хәдис.

[56] *асыл Адәм Һиндстанда* – Адәм пәйгамбәрнең Һиндстан җиренә иңгәнлеге күздә тотылган.

кан. Курмыш өязендә Мәдинә[57] авылы диләр – алар төрек кавемнәре белән гарәпләр.

Бер заман – габбасилар хәлифәлеге заманында хәлифәләр биш мәртәбә чыгып, Болгарда ислам динен яңартканнар һәм яулап алганнар. Бәгъдад халкы һәм төрек халкы күбесе татарлар эчендә җирләшкән – аларны «мишәр» диләр. «Һәмшир» дигән сүз асылда «һәмшәһир» – Бәгъдадның фарсыча, төркичә һәм гарәпчә сөйләме. «Һәмшәһир» сүзе фарсы сүзеннән алынган ки, «бер шәһәрдәш» дигәнне белдерә, русча «земляк» диләр. Төрекләр бер-берсенә «һәмшир» һәм «әмшир» диләр, «әмшири» диләр, сүзне кыскартып сөйлиләр.

Фарсы халкы Әфридун хөкүмәте заманында килеп, татарлар эчендә урнашып, татар халкының исемнәре (күбесенчә кызларында) фарсыча булуы калган: Шәрбану, Шәрбостан, Гөлбизәр, Гөлҗай, Гөлҗан кебек исемнәр. Әфридун халкының килүенә өч мең елга якын булганлыктан, аларга ышанырга бик мөшкел, алай да чуваш халкына тәэсирләре бар. Авыл исемнәре күбесенчә фарсы сүзеннән булганлыктан, хакан (һәзар, хәзәр) халкы чуваш булганлыктан.

Көрдләр – башкортлар. Хак төркиләр чуваш, чирмеш, мукшылар һәм башкалар.

Кытай халкы Болгарга күбрәк Чыңгыз хан һәм Аксак Тимер белән килгәннәр. Кытай, монгол халкы Болгарда күп. Мәсәлән, әүвәлге исемнәр Чутай һәм Йангул, кеше исемнәре: Атнагул, Кодигул, Муллагол, Айдагул һәм Җомагул кебек. Һәм «алпавыт» («албагут») – «пәһлеван» мәгънәсендә ки, монгол сүзе һәм теленнән. Болар барчасы монгол теле ки, тел белгечләренә мәгълүм.

Һәм Урта Азия сүзләре дә күп, мәсәлән, «диһкан» дигән сүз, «ыспай» дигән сүз – болар фарсыча. «Рыскал» – «русхал», «хәл ирешмәк» дигән сүз. «Ыспай» дигән сүз – «сипаһи» дигән сүз ки, сугышчы һәм сугыш халкы яхшы чапаннар киеп йөргәч «матур, ыспай кеше» дип әйткәннәр.

---

[57] *Мәдинә* – хәзерге Түбән Новгород өлкәсенең Пильна районындагы Мәдәнә авылы күздә тотылган.

Һиндстан халкы, Кашгар, Зәмин һәм Урта Азия халкы Аксак Тимер белән килеп калып, татарлар эчендә урнашкан ки, төмән халкы (гаскәриләр) һәм гади халык. Болгарга тагын да Искәндәр Руми белән сакъләбләр, лях, поляк һәм чех, венгрлар һәм болгарлар килеп калып, татарлар эчендә урнашып калганнар.

Бу бәяннан зарур булганы шул ки – Болгарда яшәгән халыкларның асыл нәсәбе бик күп тармаклы булып, Нух уллары булган Сам, Хам, Яфәс – барчасының балалары Болгар шәһәрендә булганлыгы ышанычлы дәрәҗәдәге бер мәгънә. Юкса, төп Болгар халкы төрле төркиләр һәм көрдләр булып, чуваш, чирмеш, мукшы, мордва, удмурт һәм татарлар – Сам белән Яфәскә нисбәтлеләр, «Тәнбиһел-гафилин»[58] китабында язылган кебек ки: [*гарәп телендәге өземтәнең кыскача мәгънәсе: «йөз илле кавем яәҗүҗ-мәәҗүҗләр тәмугда янар. Илле төрле халык: румнар, хәзәрләр, сәкъләбләр ... Һиндстан, хәбәш, мәгърибләр, көнчыгышта алты халык: төрки, хакан, гуз, тогр, кимәк, йемәкләр җәһәннәмнән имин булыр»*].

Татарларның сабак чираты (кизүе)

Әүвәл – әлиф-ба.

Икенче – әлиф-ба иҗеге.

Иҗек дигән сүз «һиҗәк» дигән сүз, гарәпчә. Сүзләрне үлчәм (такт) белән кисәкләп, иҗекләп, сүз тамырына хәрәкә һәм сөкүн кушып, татар сүзе белән иҗеклиләр. «Иҗек» – татарча. Мәсәлән, «мин» – «мим» аста, сыйга (төрләнеш) сәкен – «мин» дип иҗеклиләр ки, татарча.

Өченче – әбҗәд[59] укырлар.

Дүртенче – әбҗәд иҗеге.

Бишенче – әлиф-баны сүрә кылып укырлар, ягъни тәртипләп һәм тезеп.

Алтынчы – әбҗәдне сүрә кылып укырлар.

---

[58] *«Тәнбиһел-гафилин»* – X гасыр галиме Әбүлләйс әс-Сәмәркандинең диниәхлакый әсәре.

[59] *Әбҗәд* – саннарны әлифба хәрефләре ярдәмендә белдерү ысулы.

Җиденче дәрәҗә – «Иман шарты»[60] дигән китапны укырлар, иҗек һәм сүрәсен.

Сигезенче дәрәҗә – Һәфтиякне, иҗекне һәм сүрәсен укырлар. «Бәдәвам», «Тәкый гаҗәп», «Башлагали»[61], «Мәрьям ана» китаплары белән.

Тугызынчы дәрәҗә – Коръәнне сүрә кылып укырлар. Иҗекләү гөнаһ диләр. «Йосыф» китабы, «Бакырган» китабы, «Сөбател-гаҗизин»[62] китабы һәм башка төрки китапларны укырлар.

Кайбер кеше укуны шунда төгәлләр.

Унынчы дәрәҗә – «Йәк хикәйәт» (фарсы китабы), «Хәмде би хәдд», «Шөрутес-саләт» һәм «Тәгълимес-саләт»[63] китапларын укырлар.

Унберенче дәрәҗә – «Бостан», «Гөлстан»[64], «Дөррел-мәҗалис», «Морадел-гарифин», «Сагълүк» һәм «Мөхтәсар»[65] китапларын укырлар.

Кайбер кешенең укуын төгәлләү дәрәҗәсе шушы – мәдрәсәдән чыгарлар.

Әгәр дә күп укыячак булса, боларның барысын да укырлар:

Әүвәл – сарыф, сарыфтан «Шәрхе Габдулла» китабы.

---

[60] *«Иман шарты»* – гарәп әлифбасын һәм ислам дине нигезләрен өйрәтү дәреслеге.

[61] *Һәфтияк* – Коръәннең җидедән бер өлешеннән торган китап; *«Тәкый гаҗәп»* – Сөләйман Бакырганиның «Ахыр заман» әсәре; *«Башлагали»* – «Кисекбаш» дастаны, *«Мәрьям ана»* – С.Бакыргани әсәре.

[62] *«Йосыф»* китабы – XIII гасыр болгар-татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре; «Бакырган» китабы – төрки-татар суфичылык шигърияте тупланган җыентык; *«Сөбател-гаҗизин»* – XVII гасыр төрки шагыйре Аллаһыяр Суфиның шигъри-әхлакый әсәре.

[63] *«Хәмде би хәдд»* – мәшһүр әдип Фәридетдин Гаттарның «Пәнднамә» исемле, фарсы телендәге шигъри нәсыйхәтләр китабы; *«Шөрутес-саләт», «Тәгълимес-саләт»* – намаз шартларын һәм кагыйдәләрен өйрәтү буенча Дагстан галимнәре язган гарәп телендәге әсәрләр.

[64] *«Бостан», «Гөлстан»* – XIII гасыр шагыйре Сәгъдинең фарсы телендәге мәшһүр поэмалары. «Бостан» исемлесе кулъязмада «Гөлбостан» дип язылган, ул татар кулъязмаларында шундый исем белән дә йөртелгән.

[65] *«Сагълүк»* – XVI гасыр галиме Әбелләйс әз-Зилинең «Һәдиятес-сагълүк, шәрхи Төхфәтел-мөлүк» исемле, шәригать нигезләренә багышланган, гарәп телендәге китабы.

Икенче – «Кавагыйд» (озынын һәм кыскасын), «Тәркиб» һәм «Әнмүзәҗ»[66].

Кайбер кеше шунда тәмамлап, мәдрәсәдән чыгар.

Өченче – «Кяфия», «Шәрхе мулла»[67] укып, мәдрәсәдән чыгарлар кайберәүләр.

Дүртенче – мантыйк фәненнән «Исагуҗи», «Мулла Садыйк», «Шәмсия», «Гакаид» һәм «Сөллям»[68] укып, кайберәүләр мәдрәсәдән чыгарлар. Шәригать мәсьәләләре китапларыннан фикъһ, «Һидая» һәм «Шәрхел-викая» китапларын укырлар.

Бишенче – «Тәһзиб», «Хикмәтел-гайн», «Мулла Җәлал», «Тәүзыйх», «Тәлхыйс», «Мотаувәл» һәм «Тәҗрид»[69]. Укуны тәмамлау дәрәҗәсе. Бу дәрәҗә Болгар җирендә сирәк.

---

[66] *«Кавагыйд», «Тәркиб»* – гарәп теле грамматикасы нигезләре; *«Әнмүзәҗ»* – Мәхмүт бине Гомәр әз-Зәмәхшәринең (1075–1144) «Китабел-әнмүзәҗ» исемле, гарәп теле грамматикасы.

[67] *«Кяфия»* – Ибне әл-Хаҗибнең (1249 елда вафат булган) гарәп телендәге әсәре; *«Шәрхе мулла»* – гарәп теленең морфологиясе буенча фарсы телендә язылган трактат.

[68] *«Исагуҗи»* – XIII гасыр галиме Әсиретдин бине Гомәр әл-Әбһәри тарафыннан грек телендәге әсәрне эшкәртеп, гарәп телендә язылган «Китабел-Исагуҗи» исемле, мантыйк буенча хезмәт; *«Мулла Садыйк»* – «Исагуҗи» китабына аңлатмалар рәвешендә, гарәп телендә язылган хезмәт; *«Шәмсия»* – XIII гасыр галиме Нәҗметдин Гали бине Гомәр әл-Казвининең мантыйк буенча гарәп телендә язган «Әр-рисаләтеш-шәмсия фил-кавагыйдел-мантыйкыя» исемле хезмәте; *«Гакаид»* – Нәҗмеддин Әбү Хафса Гомәр Нәсәфинең (1068–1142) кәлям гыйлеменә багышланган гарәп телендәге әсәре; *«Сөллям»* – Габдешшөкүр әл-Бихари (1707 елда вафат булган) тарафыннан мантыйк буенча гарәп телендә язылган «Әс-сөллямел-голүм» трактаты.

[69] *«Тәһзиб»* – Тәфтазанинең «Тәһзибел-мантыйк» әсәре; *«Мулла Җәлал»* – Җәлалетдин Дәвванинең (1426–1501) «Гакаидел-гыйздия» исемле хезмәтен шәрехләп, гарәп телендә язылган китап; *«Тәүзыйх»* – «Тәүзыйхел-ысул» исемле, фикъһ буенча гарәп телендә язылган әсәр.

# [I вариант]

Миһербанлы һәм рәхимле Алла исеме белән.

Ике дөньяның хуҗасы Аллаһы Тәгаләгә шөкерләр булсын. Һәм тәкъва бәндәләргә хәерле ахырлар сорыйбыз. Сәетебез Мөхәммәткә һәм барлык нәсәбенә, барлык сәхабәләренә, барча пәйгамбәрләргә дога һәм сәламнәр булсын.

Шуннан соң, иманда мәзһәбем сөнни булган имам Әбелмансур Матуриди хәзрәтләренчә инанып һәм гамәлдә имам әгъзам Әбү Хәнифә хәзрәтләре сүзенчә һәм шәкертләре – имам Мөхәммәт һәм имам Әбү Йосыф, имам Хәсән бине Зияд һәм имам Зөфәр әйткәнчә заһири гамәлдә гамәл итеп, һәм суфичылык силсиләсеннән Әбүбәкер әс-сиддыйктан (Аллаһы Тәгалә аннан риза булсын) башланган Габделхаликъ әл-Гыйҗдувани силсиләсе һәм Нәкышбәндия тарикате серле булган ысулда бизәп һәм зиннәтләп, Аллаһ дип, мин Минһаҗетдин бине Сәйфулла бине Мөхәммәдшәриф бине Гаделшаһ бине Габдрахман әл-Мамадыши әл-Җәбәли Тау ягында – Гөбенә елгасы буенда булып, мин Минһаҗетдин, заһир һәм батыйн гыйлемнәргә рөхсәтнамәсе булган, югары камиллеккә ирешкән ишан хәзрәт Галимөхәммәт Сәйфулла улыннан һәм кияве Шәмсетдин Рәхмәтулла улыннан белем алып, Бәчек авылында имам булып, берникадәр вакыт балалар укытып, бу китапчыкны яздым.

Үзебез һәр фәннән дәрес тыңлап һәм дәрескә күңел салып укыганлыгыбыз сабакташлар арасында көн кебек ачык билгеле.

Ләкин, фәкыйрьлегебез сәбәпле, мәдрәсәдә күп заман тора алмыйча, бер фәннең ишарәсеннән бер гыйбарәне чишәр өчен хисләнеп-үкенеп, нәфсебез җиһад дәрәҗәсендә өзгәләнде. Вакытлар белән расланган ки, хакны сөйләгән адәмне капкаларыннан сөрәләр.

Бу китапка «Татар тарихыннан сайланма» дип исем бирдем ки, татарлар әхвален һәм тармакларын тасвирлап, тел һәм тарих, иске сүз һәм иске авылларның сүзләреннән фәһемләп, тикшерәм. Яхшы һәм сәламәт вакытыбызда халык белән

сөйләшеп йөрелгән сүзләрем, сүзебезне һәр дус-иш бик тә аңлап, канәгать булалар иде.

**Татарларның дәрес нәүбәте (чираты, кизүе) бу рәвешчә**

Әүвәл – әлиф-ба сабагы, аннан соң – иҗек сабагы, аннары – сүрә.

«Иҗек» дигән сүз гарәпчә, асылда «һиҗәк» – сүзләрне кисәкләп, иҗекләп уку дигәнне белдерә. Сүз тамырының хәрәкә, сөкүн һәм авазларны дөресләп сүзне әйтү. «Һиҗәк» һәм «иҗек» сүз тамырын чыгара.

Бу иҗек гарәптә тел, аваз һәм үлчәм дәрәҗәсендә.

Иҗек гамәле төрки булганлыктан, аны татарлар уйлап чыгарганнар. «Сүрә» дигәннәре сүзләрне төрләндереп, тәртипләп һәм тезеп уку.

Аннан соң – әбҗәд укырлар. Әбҗәдне һәм сүрәсен.

Һәм тагын «Иман шарты» укырлар, иҗекне һәм сүрәсен.

Һәм тагын Һәфтиякне, иҗекне һәм сүрәсен. Һәм төрки китаплары: «Бәдәвам», «Тәкый гаҗәп», «Башлагали», «Мәрьям ана» китапларын укырлар.

Һәм тагын Коръәнне сүрә кылып укырлар. «Йосыф», «Бакырган», «Сөбател-гаҗизин» һәм башка төрки китапларын тапканча укырлар.


Коръәннән соң укырлар гарәпчә һәм фарсыча китапларны: «Йәк хикәйәт», «Хәмде би хәдд», «Морадел-гарифин», «Дөррелмәҗалис», «Бостан», «Гөлстан», «Мәҗмәгыль-ләтаиф»[70], «Дәкаикыль-әхбар», «Тәгълимес-саләт», «Шөрутес-саләт» һәм башка гарәп-фарсы китапларын.

Әгәр дә күп укыячак булмаса, «Мөхтәсар» һәм «Сагълүк» укып, мәдрәсәдән чыгарлар.

Әгәр дә күп укыячак булсалар, боларны һәммәсен укып, сарыф укырлар, сарыф буенча «Шәрхе Габдулла», «Кавагыйд», «Тәркиб», «Әнмүзәҗ», «Кяфия», «Шәрхе мулла». Кайберәүләр монда туктап калырлар.

---

[70] *«Мәҗмәгыль-ләтаиф»* – хәдисләр җыентыгы.



بسم الله الرحمن الرحيم
الحمد لله رب العالمين والعاقبة للمتقين والصلوة والسلام على سيدنا محمد وآله وصحبه اجمعين
اما بعد اهل السنة والجماعة مذهبنده امام ماتریدیه حضرتلاری باش اولوب
اعتقاده مذهبم اهل السنة والجماعة ماتریدی حضرتلارینه اعتقاد ایدرک وعملده امام اعظم ابو حنیفه
حضرتلاری قولیغه وشاگردلاری امام محمد وامام ابو یوسف وامام حسن بن زیاد وامام زفر قولینه
ظاهر عملی ایدرک وسلسلهٔ صوفیه دن ابوبکر الصدیق رضی الله تعالی عنه دن ظهور ایدن سلسلهٔ عبد الخالق
غجدوانی وطریقهٔ نقشبندیه فقیر اولان طریقده تخلیه تحلیه ایدرک الله دیب

*I вариант текстының башы,*
*26б кәгазь*

Һәм тагын укырлар «Исагуҗи», «Мулла Садыйк», «Шәмсия», «Гакаид», «Сөллямел-голум», «Тәһзиб», «Хикмәтел-гайн», «Мулла Җәлал», «Тәҗрид», «Тәүзыйх», «Тәлхыйс» һәм «Мотаувәл». Белем алуның ахыргы дәрәҗәсе шушы.

### Болгар һәм Казанда булган төрле татарлар хакан таифәсеннән булып, барчасы төрле төркиләр һәм пәйгамбәр заманында ислам дине белән хөрмәтләнгәнлекләрен белдергән, дәлилләгән хәзәр җирендәге болгарларның зират ташлары. Болгар (хакан, татар) һәм төркиләрдән булган татарларның кабер ташлары язуларындагы хакыйкать турында китап

### Болгар җирендәге хәзәр авыллары янындагы ташландык зиратларның кабер ташлары дәлиле белән ныгытылган һәм Болгарның төркиләрдән булган хакан һәм татарларның Бәгъдад һәм госманлы язулары төрләрендәге (һәммәсе дә 900 һәм 800 һиҗри[71] еллардагы) ташъязмалары турында хакыйкать

Куснар янында Мартын[72] чувашы авылы Зиршир зиратында язылган мөселман ташы бар. Бик начар язулы: «Меңдә йөздә» дигән, башкасы беленми.

Нирсир (Җеншир, Йаншир, Шинзир диләр), Мартийан диләр. Җен шәһәре, Зиншәһәр, Шинзәр, Йершәр, Ир шәһәре. Суы – Шуршу, Шуршәр, Акшәһәр. Акчура – Акшура хан.

Сур суы, Шур суы – Ак су. Акчура – Акшура. Чура, Шура – икесе бер мәгънәдә, «ак» мәгънәсендә чуваш һәм төрки телендә.

Ягъни Мартын авылы янында мөселманнар каберләре күп.

---

[71] *900, 800 һиҗри еллар* – милади белән 1400, 1500 нче елларга туры килә.

[72] *Куснар* – хәзерге Чувашстан Республикасының Козловка районындагы авыл (рәсми исеме – Байгулово); *Мартын* – шул ук райондагы Мартыново (Йершер) авылы, XVIII гасырда Преображенское (хәзерге Аттиково) авылы крестьяннары нигезләгән.

Бер ташда язылган «меңдә йөз» дип. Ике юллы.

Шул зират янында бер шәһәр бар – исеме Акшәһәр булса кирәк. Чөнки авылы Шуршәр зираты. Елгасын Шуршу дип әйтәләр. Чувашча Аксу һәм Акшәһәр. Һәзәр шәһәре (хәзәр шәһәре), хакан, һәзар шәһәре.

Һәзәр шәһәре, шәһәр һәм халкы.

Яки Зәршәр – Зәршәһәр, әүвәл заманда җимерелгән хәзәр шәһәре.

Яки Зуршәр – Зур шәһәр.

Билыйби авылында кала бар, Борындык басуында. Каласының исеме Бузай яки Акби яки Белыйби каласы. Борындык, Шуширмә, Карашәм, Наратлы, Әҗәле, Танай, Мамадыш, Ышналыбашы өчен унлык салымын җыючы булган.

Кири авылында кала – Кошман (һәм Бәһрә) каласы. Хуҗаш, Ачасыр, Исхак авылы (Исаково), Данайча (Таныча), Каинка (Каенлык) авылларының унлык салымын җыючы булган.

Өткәкдә[73] кала, бәлки кечкенә ныгытмадыр. [*Гарәп телендәге өземтәнең мәгънәсе: «Хәзәр иленең һәм Җәбәлелфәтехнең җире киң, анда хисапсыз төрле төрки халыклар яши һәм патшалыклары да төркинеке, Искәндәр төзегән диварга чиктәш»*].

Тарих китапларында әйтелгән Хәзәр иленең күпчелеге Казан губернасында Чабаксар каласының идарәсендә булган Богородский волостендәге Зәршәр авылының басуындагы шәһәр – Зәршәр. Ягъни, Хәзәр шәһәре дигән сүз булыр ки, һәзар (хакан) падишаһының каласы.

Чуваш, мишәр һәм төрек телләрендә «х» белән «һ» арасында аерма юк, әйтелеше бер, төшереп калдырып сөйлиләр.

Зәршәр – һәзар (һәм хәзәр) шәһәре.

Турхан – субашы булып, Төрләмәс авылы булган хәзер.

---

[73] Өтәк атамасының иске телдәге яңгырашы, ихтимал, шулай – Өткәк рәвешендә булгандыр.

***

«Албагут» – «пәһлеван» мәгънәсендә («Кыйсасел-әнбия» китабында, 63 бит)[74].

Чувашча «алпаут», татарча «алпавыт». «Алып үгезне ат» яки «алыб бу ат» – монгол сүзе («мангул» дип әйтелә).

«Чәрик» – гаскәр мәгънәсендә монгол телендә. Чувашча «чер» диләр. Татарча «чирү» диләр.

Чувашча «йарвых чиру» диләр, иске тел – «сыру» (сирү). «Сиры» – «сөрьяни» дигән сүз, язу.

***

«Татар» дигәнебез сүз татарча «татар», әмма гарәпчә «тәтәр» диләр бу заманда. Иске китапларда гарәпчә «татар»ны «болгар халкы» һәм «хәзәрийан», кайбер риваятьтә «сәкъләб» дип әйтүче бар. Фарсы халкы һәм үзбәк «болгар-татар» дип әйтәләр, янә сарт (Бохара шәриф халкы) «үзбәк», «нугай» һәм «татар» дип әйтәләр. Төркмән-Хива халкы «нугай», «татар» һәм «болгар» халкы дип әйтәләр. Сарт (Коканд халкы һәм Ташкент халкы) шулай ук «нугай», «татар» һәм «Казан татары» диләр.

«Татар» сүзе бик борынгы сүз, бирелгән мәгънәсен белү мөшкел булып, берничә ихтималга якын фаразлар булса да, сүзлек һәм тарих китапларында исем һәм гыйлем мәгънәсеннән башка аңлатмасы булмыйча, бер вилаятькә исем булганын белдерүләреннән махсус мәгънәгә ия вилаять дәрәҗәсендә, борынгы заманда бер кеше исеме һәм бер кабиләнең исеме булып, вакытлар узу белән күп балалары туып, төрле кабиләләрне һәм бер чиксез зур җәмәгатьне тәшкил итеп, дөньяның төрле якларына таралганлыкларыннан, гүяки, татарлар ярты дөньяны һәм җир йөзенең яртысын биләп алганлыклары мәгълүм булып, борынгы Татарстаннан чыгып, монгол һәм Урта Азия халкы, Кашгар, Коканд-Хакан, Тибет, Төмән, Һиндстан, Чин-

[74] Бу мәгълүмат 1859 елда басылган китапка туры килә: Кыйсасы Рабгузи. – Казан: ун-т табыгханәсе, 1859. – Б. 63.

Мачин[75], Әфганстан, Уган, Катаган, Билуҗистан, Төркестан, Туран, Көрдстан, Госманстан, Болгарстан татары һәм Кавказдан яэҗүҗ-мәэҗүҗ диварына кадәр буларак, берникадәресе Төньяк Американың ерактагы инглизләр мәмләкәтенең кардәше тарафларына таралулары мәгълүм. Сибирия тарафларының Ерак Көнчыгышы булган Беринг бугазыннан чыгып, Төньяк Американың кушылган булуы фаразлануыннан Америкада халыкның күбесе һәм бу бер борынгыдан адәм балалары чыкканлыгы ышанычлы дәрәҗәдәге бер мәгънә[76].

Җир түгәрәк шәкелдә ки, географлар, борынгы грек һәм мөселман философларының бер өлеше аңлаталар – ислам дәлилләре кебек. Менә татарлар әйтелгәнчә җәмәгать булып һәм дөньяга таралуларыннан күп бүлемнәр һәм нәселләр барчасы тармаклары булып, башлангыч татарлыкны белү бик катлаулы булса да, иске тарих китапларында булган хәбәрләр һәм «татар» сүзенең асылы сүзлек китапларыннан алып, Казан татарларының бик иске авылларының исемнәреннән һәм кайбер борынгы сүзләрдән татарлыкны белүебездән соң, татарларның артканын, нәселләрен һәм татарлыкны бәян итү мөмкин. Белгечләр өчен ышанычлы һәм башлангыч булган мәгънә ки, барлыкка килүе көн кебек ачык.

---

[75] Кулъязмада төп текстның шушы юллары арасында автор тарафыннан дүрт юллы шигъри парча карандаш белән язып өстәлгән:

Баба Мачин – ул солтан,
Мөрид булды шөбһәсез.
Мөрид булды бик күп меңнәр –
Остазы шәйх Әхмәд Йәсәви.

Бу дүртьюллык Сөләйман Бакыргани шигыреннән.

[76] Авторның Беринг бугазы аша Төньяк Америка кыйтгасына борынгы төркиләрнең таралган булулары турындагы сүзләре игътибарга лаек. Аның бу фикере, күрәсең, рус матбугатыннан (ихтимал, «Гатцук газетасы»ннан) алынгандыр. XIX гасырда яшәгән Америка галиме Отто Геригнның, төрки телләр белән индеецларның телләре арасында шактый уртаклыклар табып, соңгылары борынгы дәверләрдә Азиядән күченгәннәр дигән фикергә килгән булуын сүз уңаеннан искәртик. Бу хакта галим Әбрар Кәримуллин язган иде (*Каримуллин А. Прототюрки и индейцы Америки: по следам одной гипотезы. – М.: ИНСАН, РФК, 1995. – 80 с*).

Менә татарлар төрле телләр һәм төрлечә киемнәр һәм төрле мәсканә, бик күп төрле кыяфәт һәм төс-бит барлыкка китереп, төрле мәмләкәтләргә сәфәрчелек, күршелек һәм бик сәяхәт итеп, чит-ятлардан тел һәм кием һәм төс-кыяфәтне үзгәртергә татарларның табигатьләре бик кызыга ки, тышкы күренеш буенча бу заманда булган татарлар борынгы заман татарларына бик чит халәттә һәм рәвештә булуы аңлашыла.

Әлеге җәмәгать һәм татарның бер төркем үзгәрмәгән таифәләренең кием, тел, гадәтләреннән һәм мәсканәләреннән фаразлап, татарлар борынгы заманнан бирле телләрен һәм төс-битләрен үзгәртүчән булганлыклары үзләренең үзгәрүе һәм алмашуында. Мәсәлән, Болгар пәйгамбәр заманыннан соң һәм элегрәк бер белгән алмашу һәм үзгәрү, бер заман Искәндәр Руми (бөтен дөньяга мәшһүр, белмәгән кеше булмас) румилар һәм башка халыклар белән килеп, Болгар вилаятьләрен Ибраһим пәйгамбәр динендә кылып китмән.

Һәм аннан соң Кытайдан Чыңгыз хан басып алган һәм соңрак гарәпләр, тагын Бәгъдад, Гыйрак төрекләре басып киткәннәр.

Һәм шуннан соң Аксак Тимер яулап алып, бөтен Болгарны юк итеп, халкын һәлак итеп киткән.

Бәс Болгар вә Казан вилаятьләрендә төрле нәсел һәм тел булырга тиеш булса да, төрле нәсел татарлар эчендә урнашып һәм катышып, вилаятьләре хәзер беткәнлеге гадәт һәм тышкы күренешләреннән беленә.

Һәм тагын Казанны Мәскәү басып алган һиҗри белән 961 елда. Русиядән качып һәм посып калган татарлар акрын-акрын Казан халкына кушылып һәм кыргыз халкына катнашып, Урта Азия халкы саф мөселман булганга күзләренә бик яхшы күренеп, Ташкент, Коканд, Сәмәрканд, Бохараи шәрифтә төрле гыйлемнәр һәм белем бирү куәтле заманда һәм Хива, Үргәнеч мәдрәсәләреннән гыйлем алып, төрле-төрле фәннәргә булдыклы һәм остаз буларак Казан вилаятьләренә кайтып, гыйлем тараткannar һәм укытканнар.

Безнең Тау ягы өчен Каргалыда Вәлид ишан[77] хәзрәтләреннән һәм башка хәзрәтләр мөселманлыкны күп таратканнар. Әүлиялар рөхсәте һәм рухани иҗазәте белән. Юкса, Тау ягы тәмам чуваш халкы кебек каралып калган булган.

Тау ягының татар һәм мөселманнарының каралыклары бу заманда бик ачык күз алдында – мал гыйбадәтләрендә бик ялкауланып, дүрт йөз ел наданлыкта калган чуваш халкы кебек. Чуваш кебек малга бик мәхәббәт белән зәкят һәм гошер бирүне үтәмиләр. Хәтта күбесе зәкят бирү һәм гошер бирүне хәрам дип беләләр, кайберсе алай-болай хәйлә кылалар, сәдака бирүне «акча беткәч зарар була» дип, бирмиләр. Мөселманлык бик зәгыйфь.

Казан җирендә, Уфа һәм башка яклардагы яхшы мөселман татарлар мал гыйбадәтләрен бирүдә һәм башка мөселманча гамәлләрдә тырышлар, җиңел һәм ихлас белән итә-итә килгәннәр. Бу үзгәреш бу заманда күп.

Әйтелгән Казан татарлары Урта Азиягә аралашу, сәүдә һәм мөгамәлә кылу белән бергә Урта Азия халкының телләре белән сөйләшеп, хәзерге заманда Казанда һәм тирә-ягында булган татарларның күбесе Урта Азия һәм госманлы телләре белән сөйләшәләр[78]. Һәм Казан җирендә бигрәк тә Урта Азия теле белән сөйләшәләр мулла, галимнәр, хаҗбабалары, диндар адәмнәре һәм башка укыган кешеләре. Әмма гади халкы күбесенчә рус теле белән сөйләшеп, остарып, үз бабаларыннан калган тел кебек, чит тел икәнен белмичә, ихлас белән сөйләшүче адәмнәр күп.

Казан татарларының иске сүзләре һәм авыл исемнәре, иске кием, савыт-саба исемнәре башкорт, кыргыз, чуваш, чирмеш,

---

[77] *Вәлид ишан* – үз чорында «Каргалы Вәлид ишан» дип танылган, 1802 елда вафат булган Вәлид бине Мөхәммәтәмин Җәбәли әл-Кайбычи. Тумышы белән Кайбыч авылыннан булып, Дагстанда һәм Бохарада белем алганнан соң Оренбург янындагы Татар Каргалысы авылында имам һәм ишан булган. Бу шәхес Ш.Мәрҗани һәм Р.Фәхретдин хезмәтләрендә югары бәяләнгән.

[78] Кулъязмадагы юллар арасына язылган бер өстәмә өлешенең тиешле урынын тәгаенләп булмады. Анда болай диелгән: «булганлыкларыннан һәм үз нәселләреннән булган чуваш таифәсе аерылып калып, бер халыкка әверелгән, Аллаһы Тәгаләгә сыгынабыз».

мукшы, удмурт телләре белән гүяки бер үк тел дәрәҗәсендә. Гыйбрәт иясенә мәгълүм – иске заманда Казан татарлары белән чувашларның телләре бер булган. Мәсәлән, иске киемнәр исеме: *такыя, калпак, бөркәнчек, каш, бучиңчә, чүбә, ак чүбә, бәбеч, чирбик*[79]*, нагышлы чүбә, җилән, чапан.* Казан татарлары бу киемнәрне барысын да кигәннәр. Хәзердә мөселман татарларның карчыклары һәм картлары әйтә һәм шулай ук наданлыкта калган татарлар токымы булган чирмеш, чуваш, мукшы, удмурт (вотяк) һәм мордва – бер халыкларның киемнәрен кияләр. Әмма хәзер Казан мөселман татарлары кимиләр.

Шулай ук Казан җирендә авыл исемнәре чувашча: Караширмә, Икшермә, Орымширмә, Булчирмә – Мишә елгасы буенда; Әтнә, Кавал, Каенсар; Җырыкчирмә дигән удмурт авылы, Таузар Иле – Шушма[80] елгасы буенда. Чирмешләр булган Чирмешән елгасы буенда. Һәм башка авыл исемнәрендә борынгы исемнәр күп – хәзер Казанның мөселман татарлары мәгънәсен белмиләр – һәркайсы кеше исеме.

Борынгы тел: *мәскәнәләр, кош, салаш, йаулаша, канат алды, актана асты, анбар, сарай, өй, бура, чалак, китәк, сарача, кәҗәнкә, әҗәтканә, әбрәсханә, әбрәкәй, мәмәшҗул*[81].

Тау ягында хурлап әйткән «гыҗҗот, алпан-тилпән, ыжгыт, алангыр» кебек, «котсыз, котың чыккан икән, котсыз җиз» кебек, «җүләр, сумбый, Кырым чирүе» кебек сүзләр күп. *Ничә чакрым майыттамал, кисрән, тенкәм корыды, талигым җук, ыспай (салмак кеше), хан заманында, мургыр кебек, «әҗәт (бу-*

---

[79] *такыя* – бу сүз түбәтәй, калфак, кырпу бүрек мәгънәләрендә йөргән, чувашларда «тухья» – кызлар бүреге; *калпак* – бәйләгән башлык; *бөркәнчек* – йөзне яшерү өчен кием өстеннән бөркәнеп йөргән ябынча; *чүбә* – җөббә(?); *бәбеч* – читек; *чирбик* – кунычлы күн аяк киеме.

[80] *Шушма* – хәзерге Татарстанның төньягындагы Шушма елгасы күздә тотылган.

[81] Монда китерелгән сүзләрдән *салаш* – шалаш; *канат алды* – өйнең алгы (урам) ягы; *актана асты* – каралты астына яннан казылган ярым баз; *чалак* – чарлак(?), чолан(?); *сарача* – чарача, мунча алды; *кәҗәнкә* – чолан, веранда; *әҗәтканә, әбрәсханә, әбрәкәй* – бәдрәф. *Өй, бура* һ.б. сүзләр хәзерге телдә дә бар, ә калганнарының мәгънәләре ачыкланмады.

*рыч) бирдем, карычга (карызга – бурычка) алдым», сөмсез* һәм шуларга охшаш андый гыйбарәләр күп. Мәсәлән, «чүбә» дигән сүз «сүбә» булса кирәк, «нагыш» дигән сүз «нәкышь» дигән булса кирәк. «Бәбеч» дигән сүз «папуч», госманлыча сүз. «Чирбик» дигән сүз «чадук», госманлыча сүз. «Җыныган» дигән сүз «чи илән» дигән сүз – саф татарча. «Әҗәтканә» дигән сүз «хаҗәтханә» мәгънәсендә.

Татар, чуваш телендә фарсыча сүзләр дә бар. «Гыҗ» дигән сүз – «Гуҗ» булса кирәк.

«Алгаз» дигән сүз – гарәпчә «әлгаз» (серләр). «Алпан» дигән сүз – «алыплар» дигән сүз. «Ыжгыт» дигән сүз – «әз гъад» (гъад кавеменнән) дигән сүз.

«Алангыр» дигән сүз, «алан» – мәмләкәт, халкы да алан. Санкт-Петербург каласының тирәләре Алан дигән җир булса кирәк, «Алман, Алакан, Алмания» дип әйтәләр, Балтыйк диңгезен «Аламан диңгезе» дип. Петербург каласының тирәсендә[82].

«Гыр» дигән сүз татар сүзе. «Хыр» дигән сүз, ягъни батыр булып, үзен куркыныч коручы дигән сүз – татарның «мургыр» дигән сүзеннән беленә. «Мур» – халыкның исеме, «гыр» – «кырмак» мәгънәсендә. Болгарга чувашча «мурхыр» дип әйтәләр. «Мыргыр», «Муркыргыр» дип әйтәләр. Амур дигәннән, Амур суы буеннан килгән халык, болгар һәм татар.

Болгарның тирә-ягында булган халыклар чуваш, чирмеш, мукшы, татарлар һәм башка, мишәр һәм төмән, башка халыклар һәммәсе бер нәсел – асыл төркилеккә бәйле һәм татар исеменә кайталар. Әмма татарлык-төркилек, руслык, французлык һәм башка милләткә нисбәтлелек төп нәсәпнең төрен билдереп, һичбер дингә бәйләнеше булмаганлыгы гыйлемияләренә, телләрне белүчеләргә билгеле.

Кайбер түбән кешеләр әлеге исем белән үзләрен белдекле итеп, мактанып һәм тәкәбберлек итеп, «мин – татар» диләр.

[82] Кәгазь читендә автор мондый искәрмә язган: «Петербург янында булган диңгез Аламан диңгезе («Гаҗаибел-мәхлукат» китабы) һәм халкы «алан» (виланд) халкы, Алмания диләр».

Әй-һай! Татарлык сүзеннән мөселманлык күзалланмый. Мөселманлык йөрәк белән расланып һәм телдән икърар ителеп, ислам гамәлләре үтәлсә, һәркайсы халык алдында булып һәм кәсеп итеп хасил кылса, һичшиксез ул затны «мөселман» дибез. Кирәксә рус булсын, кирәк француз булсын, кирәксә гарәп булсын, кирәксә татар булсын һәм кирәксә чуваш булсын, шулкадәр бар ки – Русия халкын «татарин» дип әйтсәләр, мөселманлыкны күздә тотып әйтәләр. Үз мәмләкәтләренә нисбәтле булган Казан мөселманы һәм Болгар халыкларыннан мөселман кыяфәтендә бер кеше күрсәләр – «татарин» дип аерып әйтүләреннән акылы кыска адәмнәр белмичә һәм аныкламыйча «татар» сүзенә тәгаен «мөселман» мәгънәсен бирделәр. Бу ялгыштыру һәм буташтыру[83].

Төп максат – татар асылы һәм татар барча тармаклары белән ислам динен кайсы заманнан бирле тота? Татар халкы элекке заманда кайсы җирдә булган? Һәм Казан татарларының барча тармаклары булган халыкларны хәзер әйтәбез, иншалла.

Татарлар борын заманда Кытайның төньяк һәм көнчыгыш тарафларында бер абруйлы мәмләкәт, халкы да татар булган. Мәшһүр Амур елгасының көнчыгыш диңгезе һәм Татар бугазына койган җирләрдә мәшһүр карта, атлас һәм җир кисәкләре турында язганда Амур елгасы тарафларын һәм Камчат халкын биләгән итеп күрсәтәләр. 1876 елның «Гатцук» газетасының[84] 23 нче номерында да шулай дип язылган.

Күчеп йөргәннәр, һун һәм авар, монгол. Татар һәм төрки халкы чыкканнар Азиянең эченнән – күбрәк Себер ягыннан, Себер Азиясеннән. Аннан соң Урта Азиягә килгәннәр, Бактри-

[83] Бу кәгазь читендә язылган ике өстәмәнең төгәл урыннарын тәгаенләп булмады. Аларда болай язылган: 1) «Һәм хәзрәти Адәм галәйһиссәламнең баласын бер тәгаен исем белән һәм атама белән килеп чыккан заманын һәм төгәл урынын,...» (кәгазьнең чите таушалган булуы сәбәпле, бу урындагы берничә сүз җуелган); 2) «Һәм хәзрәти Адәм дәрьяны фәләнчә исемдә һәм урында булып».

[84] *«Гатцук газетасы»* – танылган археолог, публицист һәм язучы Алексей Алексеевич Гатцук (1832–1890) мөхәррирлегендә һәм наширлегендә 1875–1890 елларда Мәскәүдә чыккан атналык, бизәлешле басма. «Крестный календарь»

яга[85]. Аннан фарсы Азиясенә, аннан Европага чыкканнар миладие сигезенче гасыр эчендә, Европага чыккан рус сахрасыннан миладие сигезенче гасыр эчендә.

Ибраһим Хаккый «Мәгърифәтнамә» китабында яәҗүҗ-мәәҗүҗ бәянында «Алар борынгы Татарстанның аргы ягында» дигән.

Җир йөзенең тышкы күренешен тасвирлап, Себер тарафларының көньяк-көнчыгышы булган һәм ерак Сибирия булган Амур елгасының төньяк тарафына язган «Татарстан» дип.

Тарих китапларында һәм заман ахырын бәян кылган китапларда татарларны «Искәндәрнең кече дивары һәм яәҗүҗ-мәәҗүҗләр җире башланган урында» дип язуларыннан әлеге татарлар җәмәгате борынгы заманда көнчыгышта булып, бу Казан, Болгар вилаятьләренә вакытлар узу һәм Нух пәйгамбәр заманыннан соң таралып, Болгар һәм Казанда булганнары да төрле тел һәм сүзләр белән сөйләшәләр[86].

Алат юлы татары, Гәлеч юлы татары, Арча юлы татары, Җөри юлы татары һәм Нугай юлы татары араларында аерымлык бик күп телләрендә.

Алай да күп фән, китап һәм тәҗрибә иясе садә, саф татарны бик җиңел белә, аларның бөтенесе белән тиз заман сөйләшергә була[87].

Татар асылы пәйгамбәр телендә дә булып, әйткән: «татар – Сәгъд һәм татарда булыр» дип. «Сәгъд» – Табарри китабының бәянына күрә, Сәмәрканд.

---

(православие диненең чиркәү календаре) кушымтасы буларак чыга башлаган әлеге басма 1875 елның 43 нче санынннан «Газета А.Гатцука» исеме астында нәшер ителгән һәм үз чорында шактый популярлыкка ирешкән.

[85] *Бактрия* – хәзерге Таҗикстан, Үзбәкстан һәм Әфганстанның чиктәш өлешендәге борынгы (безнең эрага кадәр 2500 елдан алып безнең эраның 900 нче еллары) тарихи өлкә.

[86] Кулъязмада текстның бу урынында мондый җөмлә өстәлгән: «адәмнәр бер токым Адәм пәйгамбәр балалары булып Һиндстанда булсалар, төрле-төрле исемдә булып, төрле урыннан барлыкка килгәннәр».

[87] Бу җөмләнең ахырында язылган «үзем күзәттем» дигән сүзләре авторның үзе тарафыннан сызылган.

«Татар» – бер бик хуш исле хушбуй җөмләсеннән, камфара кебек, татар – ганбәр кебек мәшһүр хушбуй. (Бу сүз «Алты бармак» китабында телгә алынган).

Сәгъд һәм татар – көнчыгышта булганлыгы тасвирланганлыктан, татарлар кабиләсе көнчыгыштан чыгып, дөньяга таралган. Хәтта Япония һәм Төньяк Америка тарафларында булуы уйланып, Япониядә татарлар ислам динендә һәм шафигый мәзһәбендә булуын сөйләүчеләр күп. Дәүләт хезмәтендә булган шәкерт һәм галим кешеләр әйтәләр.

«Тәнбиһел-гафилин» китабында Әбүлләйс әс-Сәмәрканди язган – пәйгамбәребез (аңа Аллаһы Тәгаләнең салаватлары һәм якыннарына сәламнәре булсын) боерган: [*гарәп телендәге өземтәнең кыскача мәгънәсе: «йөз илле кавем яәҗүҗ-мәәҗүҗләр тәмугда янар. Илле төрле халык: румнар, хәзәрләр, сәкъләбләр ... Һиндстан, хәбәш, мәгърибләр, көнчыгышта алты халык: төрки, хакан, гуз, тогр, кимәк, йемәкләр җәһәннәмнән имин булыр»*].

Бу сүзнең бәяны, иншалла, бу рәвешле – төркиләр күп кабиләләргә бүленгән булсалар да, хакыйкатьләре мәшһүр. «Хакан» дигәннәре – Коканд халкы (мәшһүр һәм билгеле сүз). «Гуз һәм тогр» дигәннәре – кыргыз халкы булса кирәк. Һәм башка өч кабилә татар ырулары булып, чуваш, чирмеш һәм мукшы кебек, боларның күбесе әлеге төрки булганлыгыннан төрки һәм татар бер тармак һәм бер нәсел булганы көн кебек ачык. Бу хәдистә «сакъләб»не Румга бәйләвеннән «сәкъләб» халкы румлылардан башка бер халык булса да, «Укъянус» китабында (6 бит) «әс-сәкъләб», «сәгъләб» үлчәмендә, румлыларның бер тармагы булганлыгы ачык аңлатылган ки, бер ир-ат исеме һәм бер төр халык. «Төрки» һәм «гарәби» кебек нисбәттә «сәкъләби» диләр. Күплек санда «сәкалибә» була, моның мәшһүре «сәкалибә», ноктасыз «сад» хәрефе белән, «рус» дип тәрҗемә ителгән мәгънәләр ки, «сакъләб» дип атау гадәткә кергән. «Укъянус» (8 бит): «Әс-сакъләб» – «сад» хәрефеннән соң «а» белән, бер халык атамасы, илләре Болгар мәмләкәте белән Константинополь арасында, Хәзәр иле белән бер тигезлектә.

География китапларында «сакалибә» – лях, чех, немец, венгр иле белән тәңгәл. Хәзерге Валахия һәм Молдавия дә ул өлкә эчендә. Һәм кайбер география китапларында «болгар» халкы дип аңлатылган һәм көнбатыш Грециядә дип тасвирланган. «Рәддел-мөхтар» китабында[88] «Болгардагы кебек вакыт юк» дигән һәм «Болгар иле – төньякта, бик салкын җирдә, аны сакалибә халкы нигезләгән» дигән.

Югарыда әйтелгәнгә күрә, сакъләб күп санлы булып, татарлар ыруыннан бер кеше исеме булып, борынгы заманда хөкүмәт иясе булганлыгыннан Болгарны төзегән булса – нәрсәсе гаҗәп?

Ләкин без – татарлар кабиләсе, бик хуш беләбез ки, Болгар шәрифне татарлар бина иткәнен.

Борынгы заманда Болгарның хөкүмәте Кавказ тарафларыннан алып, Русиянең Нижний каласына кадәр булып, бәлки Русия һәм Мәскәү бер заман татарларның идарәсе астында булганлыгы Русия халкының тарих китапларында язылган. «Нисабел-интисар» китабында язылган: [*гарәп телендәге өземтәнең тәрҗемәсе: «Хәзәр иленең җире Җәбәлел-фәтех икълимендә. Ул җир киң, анда хисапсыз төрле төрки халыклар яши һәм патшалыклары да төркинеке, Искәндәр төзегән диварга чиктәш. Аллаһы Тәгалә Коръәннең «әл-Кәһф» сүрәсендә хәбәр иткәнчә, дивар яәҗүҗ-мәәҗүҗдән саклау өчен төзелгән. Иң имин кабиләләр: хәрхәр, кимак, җәәҗән, әктәш, әтрәкс, болгар һәм башкалар. Сәедбаттал Газый «Төхфәтел-ләбаб» китабында болай дигән – Болгарда гъад кавеменең кешесен күрдем, ул 27 зирагтан озынрак. Шул кеше атны кечкенә сабыйны алган кебек кенә култыгы астына кыстыра. Болгарның Башкорт дигән җирендә хәзер дә гъад халкы калдыклары бар. Болгар җирендә мөселман төркиләр яши, алар габбаси хәлифәләреннән әл-Мәэмүн һәм әл-Васикъ Билләһи заманында ислам динен кабул*

[88] *«Рәддел-мохтар»* – ислам диненең мәшһүр галимнәреннән Ибне Габидин (1784–1836) тарафыннан язылган «Рәддел-мохтар галәд-Дөррелмохтар, шәрхи Тәнвирел-әбсар» исемле күптомлы хезмәт. Бу әсәр – хәнәфи мәзһәбенең фикъһ буенча иң ышанычлы хезмәте.

*иткәннәр һәм әл-Каим Би-әмриллаһ вакытында яңарткannar 30 мең йорт төрки кабиләләр (бер гаиләдән кардәше, агасы, балалары – барлыгы 100-дән 1000-гә хәтле). Солтан Сәбектәгин вакытында ислам динен кабул иткәннәренең хисабы юк (бик күп). Төркиләрдән ислам динен кабул итмәгән имансыз-кяферләрен үтергән. Кайбер хәкимнәр «Җәбәлел-фәтех»нең зурлыгы 12 мең фәрсәх дигәннәр. Аның шәһәрләреннән Сәмәндәр каласы руслар тарафыннан җимерелгән. Һәм андагы Болгар шәһәре һәм җире «Җәбәлел-фәтех» мәмләкәтеннән ике тапкыр киңрәк. Кыш вакытында болгарларда һәм русларда көннәр өч мәртәбә кыскарак була. Имам әл-Хәүкәли Болгардагы кыска төннәрнең намаз вакытына тәэсире турында искәрткән»*].

География белгечләре һәм тарихчылар Болгар халкына «хәзәзийан» дип әйткәннәр. Хәзәзийан халкы хакында Табарри китабында язган: мөэминнәрнең әмире хәзрәти Гомәр хәлифә заманында хәзрәти Могавиия[89] Сүриядә хаким булып, Габдрахман сәхабәне берникадәр гарәп гаскәре белән Кавказ тарафына җибәргән. Алар җиңеп, зур диварларны (яэҗүҗ-мәэҗүҗ чиген) кичеп, Дәрбәндләрдән чыгып, хәзәзийан халкы белән сугышка хәзрәти Могавиядән рөхсәт һәм фатиха алып, хәзәзийан халкы белән ничә мәртәбә сугышып һәм җиңеп, Турхан падишаһның башына җиткән (әлеге Турхан хәзазийан халкының олы башлыгы һәм падишаһлары иде. Мәҗүси иде, дуңгыз һәм эт ашар иде, аракы һәм буза эчәр иде). Хәзрәти Могавия әмере белән Габдрахман сәхабә Турханны җиңеп, халкын һәм кавемен мөселман һәм Мөхәммәт пәйгамбәр өммәте кылган.

Турхан ни урында булганын без хәзер белдек – Казан губернасындагы Чабаксар дигән кала идарәсендә булган Тау ягының чуваш халкының Төрләмәс дигән авылы (каласының) басуында Турханның урыны бар, чувашлар «Турхан пасуы» дип әйтәләр. Анда сугыш булган дип әйтәләр[90].

---

[89] *Могавия* – 661–680 елларда өмәвиләр хәлифе булган Габдрахман Могавия ибне Әбү Суфиян әл-Өмәви әл-Кораеши.

[90] Кулъязмада текстның бу өлешенең сул як читендә карандаш белән болай дип язылган: «Салам-торхан дигән сүз».

Бу сүздән беленде, мәгълүм булды – борынгы заманда чувашлар мөселман булганнар да, заманнар узу белән янә мәҗүсилеккә кайтып, аерым бер халык рәвешендә күренәләр. Юкса, Казан татарларының бик иске телләреннән һәм Тау ягы татарларының сөйләменнән һәм сүзләреннән күренгәнчә, бу заманда булган чувашларның теле, гүя, бер тел дәрәҗәсендә.

Казан татарларының сөйләме, теле Урта Азия һәм госманлы теленә якынайган. Алар качып һәм посып мөселман булып калганлыкларыннан, чуваш халкы мәҗүс булып калып, берникадәр рус теленә авышкан. Бу заман татарларның гади халкының яртылаш телләре русча, русның ярты теле татарча булган кебек. «Айда базар» дип әйтә руслар, русча кирәк «пойдём рынок». Мәсәлән, татар белән мишәр – бер төрле, һәм мишәр белән төмән – бер төрле, төмән белән типтәр – бер төрле, типтәр белән башкорт – бер төрле, башкорт белән кыргыз – бер төрле, кыргыз белән чуваш – бер төрле, чуваш белән чирмеш – бер төрле, чирмеш белән мукшы – бер төрле, мордва белән удмурт – бер төрле. Болар һәммәсе төрле төркиләр һәм көрдләр һәм гъад кавемнәре булганлыклары аңлашыла, татарлар арасында иске сүз бар – «алыплар заманы» һәм «хан заманы». Кайбер чыгып торган җирләрне әйтәләр: «алып чабата каккан җир» дип һәм җирләрдән бик зур хайван сөяге дә булмас, шулкадәр зур бот сөякләре чыга. Алыпны татарча «гыж» дип әйтәләр һәм «алпантилпән» дип әйтәләр. Болгар вилаятьләрендә хәзрәти Адәм заманында ук кешеләр барлыгы беленә. Болгар – бик иске шәһәр.

Күгешнең Биктимер улы Камалетдин әйткән: «Бер адәм сөяге күрдек, җелек юлыннан чыгып киттек» дип. Әлмән кырында Ышналы чокырында табылган бер сөяк – сыйракның яртысы, югары башы булырга кирәк. Үлчәү хисабы ярты пот. Буе – өч карыш. Бөтен булса, җиде карыш була. Әмма тез утырган җиренең аркылысы – алты вершок ярым. Әмма бу кеше исән чак егерме аршиндыр[91].

[91] *Пот* – авырлык үлчәү берәмлеге, 16,3 кг чамасы; *карыш* – озынлык үлчәү берәмлеге, якынча чирек аршинга тиң; *вершок* – озынлык үлчәү берәмлеге, якынча 4,4 см; аршун – аршын, озынлык үлчәү бермәлеге, 71 см-га тиң.

Алыплар заманы Нух пәйгамбәрдән әүвәл булган. Алып Гуҗ бине Ганык бинте Адәм пәйгамбәр[92]. Ганык – Адәмнең кызы. Ганык улыннан озын иде – «биек тау кебек» иде. Әмма Гуҗның буй озынлыгы өч мең өч йөз аршин иде. Ул терсәк (зираг[93]) бу заман терсәгеннән бер учка артык иде. Гуҗның гомере өч мең алты йөз ел иде. Муса пәйгамбәр кулыннан һәлак булды. Потка табынучы мәҗүси, кяфер иде.

Алар җөмләсеннән гъад кавеме – гъад Гаус бине Әрәм бине Сам нәселе, йөз егерме аршин буйлары. (Бу бәян «Алты бармак» китабында).

***

Болгар шәһәре исламга Ибраһим пәйгамбәр килгән заманы, Нух пәйгамбәрдән соң, әүвәл мәртәбә Салих пәйгамбәр дәгъвәте белән мөэмин булганнар.

Һәм тагын Искәндәр Руми заманында Ибраһим пәйгамбәр динендә булдылар. Һәм тагын Мөхәммәт пәйгамбәр дәгъвәте белән мөэмин һәм мөселман булганлыклары «Алты бармак» китабындагы шушы хикәяттән мәгълүм була.

«Риваять ителгән ки, хәзрәти рәсүлулла (аңа Аллаһы Тәгаләнең салаватлары һәм нәселенә сәламнәре булсын) боерды ки – Җәбраил фәрештә мине яэҗүҗ-мәэҗүҗгә илтте. Аларны иманга һәм Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылырга дәгъвәт иттем, кабул итмәделәр һәм исламга килмәделәр – бөтенесе җәһәннәм әһеле. Аннан мине ике шәһәргә илттеләр: берсе көнчыгышта һәм берсе көнбатышта, һәрберсенең ике мең капкасы бар иде. Бер капкадан икенче капкага бер фәрсәх иде. Ул көнчыгышта булган шәһәрнең халкы гъад кавеменең мөэминнәреннән иде, ягъни нәселләреннән иде. Салих пәйгамбәргә иман китергәннәр иде. «Сөрьяни телендә Бәркайна диләр һәм гыйбрани телендә Җабәлкаһ диләр –

[92] «Кыйсасы Рабгузи» китабында (Казан, 1859, 54–56 битләр) алып «Гуҗ ибне Ганык хикәяте» бар. Мөхәммәд Чокрыкчызадәнең «Алты бармак» (Казан, 1865, 92–94 битләр) китабында да гъад кавеме турында язылган.

[93] *зираг* – терсәк буе озынлык үлчәве (58 см).

аларны дингә дәгъвәт иттем, гыйбадәтне өйрәттем – кабул иттеләр».

Гөман бар ки, Болгар вилаяте зур диваргача (яэҗүҗ-мәэҗүҗ чигенә) башлангычы булганлыктан, яэҗүҗ-мәэҗүҗгә сәяхәте һәм зикереннән, шаять, бу тарафлардыр. «Җабәлкаһ»ны «Тибъян нафигъ» тәрҗемәсендә охшаш галәм белән матди галәм белән рухани галәм арасында бер нурани галәм дисә дә, без әйтәбез: «хәзер аныклавыбыз буенча, Җабәлкаһ берничә» дибез.

Һәм тагын «Тәварихы дәваир»[94] китабында өч сәхабә Болгарга килеп гыйбадәт һәм дин өйрәтеп киткәннәр тугызынчы һиҗри (милади 633) елда.

Һәм тагын хәзрәти Гомәр заманында (Могавия яшәгән заманда), Габдрахман сәхабәнең Турхан халкы хәзәзийан белән сугышып, Болгар тарафында исламны көчәйтеп киткәнлеге Табарри китабында язылган. Русиягә, Бәләнҗәр һәм Аланга хәтле.

Аннан соң габбаси хәлифәләрдән Мәэмүн хәлифә заманында Болгар халкы басып алынган.

Һәм тагын Васикъ Билләһи заманында яуланган һәм Каим Билләһи заманында утыз мең сыркәү яулап алынган. Сыркәү – төрек теленчә ир кардәшләрдән һәм барча карендәшләреннән йөздән меңгәчә.

Тагын да Болгар халкы иман китергәннәр солтан Мәхмүд Сәбектәгин заманында хисапсыз.

Әмма әлеге Болгар каласы бик олы кала булган. Шәһәр үзе йөз чакрымга якын булган, унике пулат булган, чиксез күп мәдрәсәләр булган. Суфый галимнәр булган. Хөкүмәте Кавказ тарафларыннан Мәскәүгәчә. Һәм Мәскәү дә бер заманны аның идарәсе астында булганлыгы русларның тарих китапларында язылган. Болгар җирендә төрле халык һәм төрле телләр үзгәреп һәм алмашып килгән.

[94] «Тәварихы дәваир» исемле китапка нисбәт ителгән бу вакыйга Таҗетдин Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» исемле әсәрендә язылган.

Бу урынга «Болгар бәете» язылачак[95].

***

Болгар халкы күбәеп җиткәч, камиллек билгесе бетеп, Батый хан чыгып Кытайдан күп гаскәр белән (Чыңгыз диләр) Болгарны алып, әйберләргә тамга салдыру гадәт итеп киткән. Аннан соң сигезенче йөз (милади XIV гасыр) фетнәсе булган Чыңгыз нәселеннән Аксак Тимер Болгарны, үзбәк шәһәрләре никадәре булган – һәммәсен җимергән, бөтенләй булмагандай юкка чыгарган. Нурсыз-имансыз Тимер русны җиңәлмәгәч, кайтып, качып киткән.

Аксак Тимер мактаулы кеше түгел, кызылбашлар белән, хөруфи[96] дигән кешеләр белән сәяхәт иткән һәм мөэминнәрнең канын һәм яшен түгеп, хозур һәм ләззәт тапкан адәм. Юкса, шуның чаклы яхшы мөселман шәһәрен җимереп бетермәс иде.

Шул заманда Болгар татарлары бик аз гына калып, качып-посып йөреп, Казан елгасы буена кала салып, йөз елдан артык анда торып, ул җирне яратмыйча, Казан елгасы Иделгә койган җиргә Казан каласын төзеп күчкәннәр. Һаман да Казанда ханнан калган манара[97] бар.

Аннан соң Мәскәүнең рус халкы бик куәтләнеп, йөз илле мең кеше белән патша Иван Васильевич җиде ел сугышып, һиҗри 961 нче елда, тычкан елында, чаян ае (октябрь) 2 нче

---

[95] Кулъязмада шушы искәрмә генә бар, бәетнең тексты теркәлмәгән. Кызганыч ки, китап авторының Болгарга багышланган нинди бәетне күздә тотканлыгы билгесез. Татар халкының Болгар шәһәре турындагы бәетләре күптөрле (*мәсәлән: Татар халык иҗаты. Бәетләр / төз. Ф.Әхмәтова, И.Надиров, К.Җамалетдинова. – Казан: Татар. китап нәшр., 1983. – Б. 24; «Гәүһәр Болгарга килдем...»: тарихи бәетләр..., 2013. – Б. 49–66*).

[96] *кызылбашлар* – Иранда XVI–XVIII гасырларда хакимлек иткән сәфәвиләр династиясенең төп көчен тәшкил иткән Кече Азияле төрекләр. Башларына кигән кызыл тасмалы бүрекләренә бәйле рәвештә «кызылбашлар» дип йөртелгәннәр. *Хөруфи* – шигый мәзһәбендәге суфиларның XIV гасырда Иранда оешкан дини-фәлсәфи агымы.

[97] Сөембикә манарасы күздә тотылган.

көнендә[98] («Чыңгыз хан китабы»нда язылган) күп адәмнәр һәлак булып, татарларның күп нәсел-ырулары беткән. Ул заман Казанда мөселман гаскәре утыз мең иде.

«Казан бәете», иске бәет:

Фар-фурлар бөтенләй уйнамас булды,
Каһвәханәләрдә каһвәләр кайнамас булды.

Казан шәһәре дә бер мәшһүр бөек шәһәр булып, башка калалар шикелле, мөселманнар күп булган.

Хәзерге заман Казан ягында наданлыкта һәм зәгыйфьлектә калган кешеләр күп. Мәзһәб нәрсә икәнен белмәгән үлем хәлендәге бәндә кебек, «Лә иләһә иллә Аллаһу Мөхәммәт рәсүл»не (Бер Алладан башка кодрәт иясе юк, Мөхәммәт – аның илчесе) белерләр, башка әгъзалар гамәленнән һәм башка фәннәрдән һич хәбәрләре юк.

***

Үзебезнең иске хикәятебезгә килик. Безнең Тау ягы халкы күп нәрсәне беләләр, бик иске нәрсәләрен, хәлләрен һәм хикәятләрен беләләр.

Алыплар иске заманда күп булган. Бер заман алып дигән озын халык сука сукалаган кешеләрне җир өстендә сука сукалап йөргән чагында, «Бу чебен ни эшләп җир ертып йөри?» – дип алып, кесәсенә тыгып кайткан. Әйтәләр – имәннәрне әрем дип утап ташлаганнар, дип. Бу сүзләрдән беленә – алып бу җирдә элгәредән булган икән дип. Кечкенә халыклар соңыннан ерак җирдән җыелып чыккач, аларга карап торасы бик гаҗәп булган.

Бу дөньяның әүвәлен белгән кеше юк. Түнтәрнең ишан хәзрәттән ишеткән идек – бу дөньяда адәм исемендә күп адәм булып үткән, бу дөнья ничә миллион еллар дәвер иткән дип ис-

[98] Һиҗри 961 елның 2 нче гакърәб (чаян ае) милади белән 1554 елның 23 октябренә туры килә. Дөресе – 1552 елга туры килә торган һиҗри 959 ел булырга тиеш.

батланган, әмма барлыкка килгән заманы һәм тарихы юк[99].

Шуңа күрә, хәзрәти Адәмнән пәйгамбәребез (аңа Аллаһы Тәгаләнең салаватлары һәм сәламнәре булсын) килгәнче тарихта булган төп Адәм пәйгамбәр нәселе шулай ук адәмнәр ул заманда Азиядә булып, җир йөзенә тарала килгәннәр. Европага, Африкага, Америкага һәм көньяк Һиндстан булган Австралиягә һаман адәмнәрнең таралуы һәм фигыле шундый.

География галимнәре сүзенчә, дөнья туп кебек йомры һәм аны биш кыйтгага (материкка) бүләләр: Азия, Африка, Америка, Европа һәм көньяк Һиндстан – Австралия һәм башка утраулар күп.

Бу заманда дөньяның мәшһүр һәм танылган кыйтгасы – Европа. Мәдәният, башка һөнәр һәм гыйлемнәр күп. Халкының яртысына якыны мөселманнар. Төрки һәм татарлардан Андалузия тарафларында берникадәр гарәпләр дә бар. Һәм башка халыктан мөселманнар күп.

Европадагы адәмнәрнең төрләре: әүвәл – төрки һәм татар нәселе, икенче – славян нәселе. Ул бу нәселләргә тармаклана: рус, поляк, серб, богем. Өченче нәсел немец нәселе, тармаклана: датчин, швед, голланд, инглиз, француз. Дүртенче – латин нәселеннән чыга испанияле, португаллылар, итальяннар. Бишенче – венгр нәселе. Алтынчы – грек һәм крит нәселе. Җиденче – мавр нәселе, Испания мәмләкәтләрендә, Ак (Урта) диңгез утрауларында торалар. Сигезенче нәсел – чегәннәр һәм яһүдләр мәмләкәте.

## [III вариант]

### Болгарлар һәм хаканлылар тарихы

### Болгар һәм хакан татарларының пәйгамбәр заманында ислам дине

[99] Кульъязмада текстның бу урыныннан Ибраһим Хаккыйның «Мәгърифәтнамә» китабыннан күчерелеп, һинд браһманының сүзләре рәвешендә кояш әйләнешенең 80 мең еллык хәрәкәтенә бәйле табигать үзгәрешләре турында язылган.

белән хөрмәтләнгәнлекләрен белдергән
дәлилле борынгы ташлар
китабы

Болгар һәм Казанда хакан татарларының
пәйгамбәр заманында ислам дине белән
хөрмәтләнгәнлекләрен белдергән дәлилле
борынгы Болгар җирендәге борынгы ташлар
китабы


Болгар һәм Казанда булган татарлар күп төрле һәм бөтенесе
дә төрки һәм хакан булып, барчасы пәйгамбәр заманында
ислам дине белән хөрмәтләнгәнлекләрен
белдергән дәлилле Хәзәр җирендәге зират ташлары
(хәзәр һәм болгар сүзләре белән язылган) хакыйкатьтә хакан
һәм татар китабы

**Болгар һәм татар тарихы**

Болгар һәм Казан якларында яшәгән төрле төркиләр җөмләсеннән саналган халыкларның исемнәре – борынгы хан заманында һәм хөкүмәтендә булып, алар: чирмеш, чуваш, мукшы, удмурт һәм татар – барчасы Болгар иле халкы.

Һәм тагын башкорт, мишәр, төмән, кыргыз һәм Төркестан да бер заман Болгар хөкүмәтендә булып, Болгар, янә Төркестан, Хәзәр, Хәзәз, фәгъфуре Чин исемендә булып, барлык халкы берләшеп, Болгар җире һәм мәмләкәте бер киң мәмләкәт булып, Дәрбәнд һәм Дәмур исемле Кавказ тарафыннан Боз диңгезенә һәм Сибирия тарафларына кадәр – җөмләсенә Хәзәр вилаяте диләр. Эчендә төрле төркиләр һәм Яфәс ырулары белән тулы.

Болгарның борынгы заманда баш шәһәрләре исемнәре Сарай (Дарел-мөлкет-татар), Сәмәндәр, Хәзәр, Казан һәм башка исемнәрдәге күп шәһәрләре булып, хәзерге заманда бихисап кала һәм шәһәр урыннары Болгар җирендә бар. Ләкин исемнәрен күп кешеләр белмәгәнлектән, исемнәрен язмадык. Шулкадәрле ки – Болгарның баш шәһәре Сәмәндәрнең тәхете



تواریخ بلغاریه وتاتاریه

بلغار وقزان اطرافنده ساکن اولان اتراک المختلفه لر جمله سندن معدود اولان طائفه لارینک

اسم لاری قدیم خان زمانلرنده وحکوماتلرنده اولوب طایفه لاری نینک نوع وجنسی

*III вариант текстының башы,*
*22б кәгазь*

егерме ел сәнгать ителеп, алтын һәм көмеш, җәүһәрләр белән гаҗәп рәвештә бизәлгән иде, хәзер рус кулында дип әйтәләр һәм китапларда күренә.

Болгар исемле борынгы шәһәр Салих пәйгамбәр өммәте булып, аннан соң хәзрәти рәсүлгә (Мөхәммәт пәйгамбәргә) иман китереп, бер заман Искәндәр Руми идарәсе астында булып, ничә еллар мөэмин булып вакытлар үткәргәннәр.

Болгар һәм Казан халкы төркиләрдән булып, хәзәр һәм хәзәзийан халкы диләр. Барчасы төрки һәм татарлар. Болгарга буйсынган төркиләр – чуваш, чирмеш, мукшы, удмурт халкы хан заманында Мөхәммәт пәйгамбәр заманыннан бирле мөэмин, Мөхәммәт өммәте булып, заманнар үтү белән аерымланганлыкларын белдерә торган язулы кабер ташлары әйтә. Болгарда һәм Болгарның ерак тарафларында һәр халыкның зиратларында күренгән ташларда Болгарның соң мәртәбә ислам белән куәт табулары солтан Мәхмүт Сәбектәгин заманында булып, алты-җиде мәртәбә ислам яңартылган: әүвәл – Салих пәйгамбәр заманында һәм тагын – Искәндәр Руми заманында. Бигрәк тә, Болгар вилаяте Габдрахман сәхабә хәзрәтләре кулыннан күбесе мөселман булганнар. Ул заманда Болгар халкының хан исемендә булган кешесен хакан-һәзар дигәннәр, татарларның ...[100] падишаһы.

Әмма татарларның чуваш ыруы русның Казанны яулавы заманыннан илле-алтмыш ел алдан наданлыкта калып, мәҗүси һәм төркиләрнең борынгыда булган әшәке гадәтләрен китереп чыгарган. Мәҗүси булып калуларына хәзер дүрт йөз ел ки.

Рус йөз утыз мең гаскәр белән чуваш халкы өстендә басып яткан. Аларны ислам гамәлләрен кылудан тыеп торып һәм чукындырырга вакыт булмыйча, мәҗүси кылып китеп, хәзерге заманда аларны христианлаштыру ниятендә бик ныгытып тикшерәләр. Чувашларның борынгы хан заманында мөселман булганлыкларына дәлил үз токымнарыннан һәм авыл саен...[101]

---

[100] Кулъязманың кәгазь чите таушалып ертылган булуы сәбәпле, бу урындагы бер сүз укылмый. Аның ахыргы хәрефе «с» яки «ш» генә күренә.

[101] Кулъязмада кәгазьнең чите ертылган булуы сәбәпле, бер сүз танылмый.

булган мөэминнәренең исемнәре – Габдеш, Заид һәм Шәфи кебек, кызларында Гөлбостан, [Шәрбо]стан кебек исемнәр.

Шулай ук удмурт халкы, чирмеш халкы һәм мукшылар кыз биргәндә мәһәр билгелиләр һәм ризыкны ашый башлаганда «бисмилла» диләр.

Һәм дә авылларының янында булган ташландык зур зиратларында язулы ташларында һиҗри белән тугыз йөзенче еллар (милади XVI гасыр). Һәм тагын ташларында Коръән аятьләре һәм пәйгамбәр хәдисләре язылып, күбесе рус белән сугышып, бәрелеш вакытында шәһид булган хан һәм би чувашлар. Чуваш халкы саф төрки (хәзәр һәм хәзәзийан, фәгъфур халкы) һәм Шәркый. Кайбер ташларында «хаҗи Чәләби» дип язылган һәм кайсысында «би» дип язылган, һәм кайсында «әфәнде» дип язылган һәм кайсында «хуҗа» дип язылган. Күбесенчә һиҗри белән «тугыз [йөз] ел» язылган. Кайберләрендә бар һиҗри тарихы язылган ташларда ...[102] «... йөз кырык», кайберсендә «сигез йөз» һиҗри (милади XV гасыр) дата язылганнары да бар.

Гомумән, җомга көнне хөрмәтләп, бәйрәмчә шатланалар.

Һәм борынгы заманда булган Болгар шәһәренең зиратында да ташларда чуваш теле белән язылган ташлар күп дип сөйлиләр.

Безнең Бәчек бинең ташында язылган Коръән аяте: «Җирдә булган һәр нәрсә һәлак булачак, фәкать олуглык һәм хөрмәт иясе булган Раббыңның заты мәңгелек. Тарих тугыз йөз җидедә вакыт Шәгъбан бине Әсәд бине Әмурхан бине Әбамган бине Шыгал хан бине Төнихуҗа Бәчүкә угылы кяфер кулындин шәһид булды».

Хәзер 1295 һиҗри (1878 милади) ел Казан губернасы Зөя өязендәге Бүә суының буенда булган Бәчек авылының зиратында булган каберстанда бер олы ташның сурәте.

Бу ташта җирләнгән кеше Шәгъбан бине Әсәд бине Әмурхан бине Әбамган бине Шыгал хан бине Төнихуҗа улы Бәчүкә улы тарих тугыз йөз җидедә вакыт кяфер кулыннан шәһид булган.

[102] Кульязмада кәгазьнең чите ертылган булуы сәбәпле, берничә сүз танылмый.

[*кабер ташының алгы ягының рәсемендәге язуы*]:

1) мөбарәк һәм бөек Алла әйтте

2) җирдә булган һәр нәрсә һәлак булачак, фәкать олуглык һәм хөрмәт иясе булган

3) Раббыңның заты мәңгелек[103]

4) тарих тугыз йөз җидедә вакытка

5) Шәгъбан бине Әсәд бине Әмур хан бине Әбамган бине

6) Шыгал хан бине Төнихуҗа угылы Бәчүкә

7) кяфер кулыннан шәһид булды

[*кабер ташы рәсеменең арткы ягындагы язуы*]

1) бу ташны ясады ...

2) ...ис кылды

[*Уң ягында:*] пәйгамбәребез (аңа Алланың сәламнәре булсын) әйтте: бу дөнья – ахирәтнең иген кыры.

[*Сул ягында:*] пәйгамбәребез (аңа Алланың сәламнәре булсын) әйтте: бу дөнья бер сәгатьлек, аны гыйбадәт белән үткәр.

Бу таш белдерә – Бәчек авылы җите йөз елдан бирле авыл салынып, шушы урында көн итеп, тагын күп заманнарда мөселман булып торганлыкларын.

Бәчек авылы Болгар җимерелгәннән әүвәл булып, ханның бер күркәм бие булганлыгыннан «Бичегем» дип әйтүеннән Бәчек ..[104] ...лар ... булган ... күп ... калып, чуваш булганнар, ... авылны өчкә ... Бичек би, Күз би, Мулла бабай, Дүскә(?) бабай «Иске йорт»та утырганнар, имәнлек чатында. Ягъни, тау башында – имәнлек урманында.

Әлмән, Кармыш, Бәчек – һәр өчесе ханның биләреннән саналган. Хәзерге вакытта аерылып, өч авыл булып, ни өчен ... [105]

[103] Коръәннең «Рахман» сүрәсендәге 26–27 нче аятьләрдән алынган текстның мәгънәсе. Гарәп теленнән тәрҗемә ителгән өлеше төп текстагы юлларга тәңгәл килеп бетми.

[104] Кульязма кәгазенең түбәнге юлы таушалган, аерым сүз өлешләре генә күренә. Аннан соң текст кәгазьнең читенә язылып дәвам иткән. Ул читләре дә таушалган, язулары җуелган. Танылган аерым сүзләрне һәм сүз өлешләрен күрсәттек.

[105] Кульязма җыентыкта текстның шуннан соңгы дәвамы юк.

# КУЛЪЯЗМАНЫҢ ТАСВИРЛАМАСЫ

Кулъязма Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә «2113т» шифры белән саклана. Китапханәгә археограф галимә Зәйнәп Максудова тарафыннан 1962 елда тапшырылган.

Күләме 22х36 сантиметр зурлыгындагы, Россиядә эшләнгән 38 кәгазьдән тора. Үзенең пагинациясе дә, кустодлары да булмаган. З.Максудова тарафыннан гади карандаш белән (берничә урында кызыл карандашлы һәм шәмәхә кара белән) бит саен куелган пагинациясе бар. Ул 1а–17а кәгазьләрдә 1–33 битләр рәвешендә дөрес куелган, ләкин 17б кәгазьдә ялгышлык белән 33 дип тагын кабатлап номерланган. Шулай дәвам итеп, 36 саны да ике мәртәбә (19а һәм 19б кәгазьләрдә) билгеләнгән. 20а кәгазьдән 37 саны куелып, иң ахыргысы (38б кәгазь) – 72 нче бит дип номерланган. Берничә мәртәбә сызып-бозып үзгәртүләр нәтиҗәсендә, З.Максудова теркәгән пагинациянең иң ахыргы бите (38б кәгазьдә) «72» кебек күренсә дә, ул «76» итеп төзәтелгән булган.

Кулъязманың сакланышы уртача. Кайбер кәгазьләре (бигрәк тә 23 нче кәгазь) таушалган һәм күпчелек кәгазьләрнең читләре тетелгән. Тышлыгы юк, элек ак җеп белән тегелгән кәгазьләренең бер өлеше таркалган һәм урыннары буталган. 12–19 һәм 27–36 нчы кәгазьләре аерым дәфтәрләр рәвешендә тегелгән хәлдә саклаган.

Җыентыктагы текст Минһаҗетдин мулла Сәйфулла улы тарафыннан гарәп язуының «татар тәгъликы» дип йөртелгән төрендә, ашыгыч өслүбтә, көрән төстәге кара белән язылган. Төзәтеп, сызып һәм өстәп язылган урыннары шактый. Урыны-

урыны белән өстәлгән аерым сүзләр, хәтта җөмләләр дә бар. Аларның күбесе башта язылган юл араларына вак кына итеп теркәлгән. Юллар арасында мәйдан җитмәгәнлектән, кәгазь читендәге буш урыннарга чыгып, еш кына вертикаль рәвештә югары тарафка яисә түбәнгә таба дәвам иткән. Өстәмәләр ваграк итеп көрән кара белән һәм гади карандаш белән язылган. Аерым битләрдә кайбер сүзләрнең һәм гыйбарәләрнең асларына гади карандаш белән авторның үзе һәм З.Максудова тарафыннан сызылган, кайбер сүзләрнең өстендә җөмлә яки фикер башлары махсус тамгалар белән билгеләнгән. 6а, 6б, 13а, 29а, 30б, 32а–33б, 35а, 35б кәгазьләрдәге кайбер сүзләр астына З.Максудова тарафыннан кызыл карандаш һәм шәмәхә кара белән сызылган.

Хезмәтнең авторы ашыгыч язган булуы сәбәпле, кайбер сүзләрдә хаталары бар. Мәсәлән, «итмәк» сүзе «итекмәк», «кесәсенә» сүзе «ксиләсенә» һ.б. Кулъязма текстында аерым сүзләрнең кушымчалары, калын яки нечкә яңгырашлы буларак, сүз тамырына ярашмавы очрый. Мәсәлән, *иделәчак, йазмадук, йәһүдлык.*

Кулъязмадагы төп текстларның теркәлгән вакыты – 1878 ел: 10а кәгазьдә – 1878 елның 5 сентябре, 25а һәм 26а кәгазьләрдә 1878 дип, елы гына күрсәтелгән. Кайбер өстәмә язмалар соңрак та теркәлгән, мәсәлән, 1б кәгазьдә «1886» датасы бар.

34б кәгазьдә карандаш белән «отсюда» (бу урыннан) дип билгеләп, 35а кәгазьдә «до сюда» (монда хәтле) дигән искәрмә күренә. Ул якынча XX гасыр башына кадәрге вакытта теркәлгән. Аның кем тарафыннан билгеләнгән булуы мәгълүм түгел. Анда Болгарда ислам дине кабул ителүе, Болгарның җимерелүе, Казан шәһәренең нигезләнүе һ.б. кыскача бәян ителгән.

Җыентыкта автор хезмәтенең каралама вариантлары үзара буталганлыктан, текстта кабатланган урыннары бар. Кереш мәкаләбездә бу мәсьәләгә махсус аңлатма язылды һәм җыентык тексты берничә өлештән (варианттан) торган булуының ачыклануы әйтелде.

Кулъязма җыентыкның гомуми пагинациясе, текст вариант-

ларының эчтәлегенә һәм мәгънәсенә күрә, ачыклавыбыз буенча, түбәндәгечә тәртиптә булырга тиешле.

| *тиеш* | *үзендә куелган* | *искәрмә* |
|---|---|---|
| 1 | 24 | |
| 2 | 25 | |
| 3 | 11 | |
| 4 | 26 | хезмәтнең I варианты башы; текстның бу варианты яңача (тиеш) дип билгеләнгән 13 номерга кадәр дәвам итә |
| 5 | 27 | үзендә куелган пагинация буенча 27–36 нчы кәгазьләр бергә тегелгән |
| 6 | 28 | |
| 7 | 29 | |
| 8 | 30 | |
| 9 | 31 | |
| 10 | 32 | |
| 11 | 33 | |
| 12 | 34 | |
| 13 | 35 | I вариантның ахыры |
| 14 | 36 | |
| 15 | 37 | |
| 16 | 21 | |
| 17 | 38 | хезмәтнең II варианты башы; текстның бу варианты яңача (тиеш) дип билгеләнгән 35 номерга кадәр дәвам итә |
| 18 | 1 | үз пагинациясендә кәгазьнең икенче ягы белән әйләнгән хәлдә номерланган; дөреслектә 1б тарафы 1а булырга тиеш |
| 19 | 2 | |
| 20 | 3 | |
| 21 | 4 | үзендә куелган пагинация буенча 4–5 нче кәгазьләр куш бит рәвешендә |
| 22 | 5 | |
| 23 | 6 | |
| 24 | 7 | |

| | | |
|---|---|---|
| 25 | 8 | |
| 26 | 9 | |
| 27 | 10 | |
| 28 | 12 | үзендә куелган пагинация буенча 12–19 нчы кәгазьләр бергә тегелгән |
| 29 | 13 | |
| 30 | 14 | |
| 31 | 15 | |
| 32 | 16 | |
| 33 | 17 | |
| 34 | 18 | |
| 35 | 19 | II вариантның ахыры |
| 36 | 20 | |
| 37 | 22 | үзендә куелган пагинация буенча 22 һәм 23 нче кәгазьләр кыскача аерым бер башламлы һәм аны шартлы рәвештә III вариант дияргә мөмкин |
| 38 | 23 | |

Вариант текстлары арасындагы кәгазьләрдә нәрсәләр теркәлгән булуы һәм, гомумән, җыентыкның үзендәге пагинациясе буенча тасвиры түбәндәгечә.

1а кәгазендә Гали ишан Сәйфулла улы Түнтәригә бирелгән иҗазәтнамә текстының күчермәсе[1]. Иҗазәтнамә гарәп телендә язылган. Анда ишанның исеме Гали бине Сәйфулла әл-Болгари әт-Түнтәри дип теркәлгән. Битнең түбәнге өлешендә карандаш белән өстәп язылган аңлатмалар бар. Кәгазьнең түбәнге өлешендә гади карандаш белән «Мулла Мөхәммәтфатих ...» дигән исем теркәлгән.

Шул биттәге текстның уртасыннан югарырак өлешендә З.Максудова тарафыннан карандаш белән «язылган» дип

[1] Бу иҗазәтнамәнең тексты гарәп хәрефләре белән басылган: Бустанов А. Библиотека Зайнап Максудовой = Зәйнәп Максудова китапханәсе. – М, 2019. – С. 177–180. Әлеге китапта кульъязманың бите «1б кәгазе» дип ялгыш күрсәтелгән, иҗазәтнамәнең хәзерге татар язуына күчермәсе һәм тәрҗемәсе бирелмәгән.

искәртелгән. (Кулъязманың шактый битләрендә кабатланган, вертикаль яисә диагональ рәвештәге, «язылган» һәм «язылды» дигән мондый искәрмәләр турындагы мәгълүмат тасвирлама ахырында бергә җыеп күрсәтелде). Алар текстның З.Максудова тарафыннан күчереп язылганын белдерә.

1б кәгазьнең өске өлешендә «Мәнакыйбе хәзрәти ишан Түнтәри. Әз тәхрирате галлямәтез-заман дамелла Фәхретдин Норлатый әл-Җәбәли»[2] дип язылган. Ягъни, бу биттә Фәхретдин Норлатыйның Гали ишан Түнтәригә багышланган мәдхия тексты урын алырга тиеш булган[3]. Шунлыктан, кәгазь бите буш калдырылып, күпмедер вакыттан соң анда кулъязма иясе Нух пәйгамбәр шәҗәрәсен язып куйган. Ягъни, Нухның 5 улының исемнәре, шулардан беренчесе Яфәснең 13 улы (Төрек, Хәзәр, Чин, Хәзәз, Рус, Сакъләб һ.б.) теркәлгән. Төрекнең ике улы: Алынча хан һәм Фәвек, Алынча ханның шулай ук ике улы – Магул һәм Татар исемнәре язылган. Кайбер исемнәргә карата өстәмә аңлатмалар да бирелгән. Шул ук кәгазь битендә рус язылышындагы саннар белән «1886» дигән дата теркәлгән. Бу, күрәсең, әлеге шәҗәрәне теркәгән елны белдерәдер.

2а кәгазьдә «Шәҗәрәтү тарикати хәзрәти Нәкышбәндийә куддисә Аллаһу Тәгалә әсрарүһүм» (Нәкышбәндия тарикатенең Мөхәммәт пәйгамбәрдән алып Гали ишан Түнтәригә кадәрге силсиләсе) тексты фарсы телендә язылган[4].

Җыентыкның 2б кәгазенең өске өлеше таушалганга күрә, анда язылган юллар танылып бетми. Гали ишанга бәйле таныл-

---

[2] Бу гыйбарә гарәп хәрефләре белән басылган: Бустанов А. Библиотека Зайнап Максудовой..., 2019. – С. 177. Анда кулъязманың бите «1а» дип ялгыш күрсәтелгән.

[3] Фәхретдин Мостафа улы Норлатый (1806–1891) – хәзерге Буа районындагы Норлат авылында имам һәм мөдәррис булган, укымышлы, мәшһүр зат, ишан. Гомеренең соңгы 40 елында сукыр хәлендә мөдәррис вазифасында мәшгуль булган сирәк шәхесләрнең берсе. Аның Гали ишанга багышлап мәдхия язганлыгы турында башка чыганаклардан билгеле түгел.

[4] Силсиләнең башындагы һәм ахырындагы кайбер юллары гарәп хәрефләре белән басылган: Бустанов А. Библиотека Зайнап Максудовой..., 2019. – С. 179.

ган хәтлесе мондый: «[Мә]зкүр хәзрәти ишан күб адәмләрнең калеб... һидайәт йулына салуб китмешдүр». Шул ук 2б һәм 3а кәгазьләрдә пәйгамбәрләр тарихына, дөньядагы кешелек тарихына ничә ел булуына бәйле каршылыклы фикерләр турындагы язмалар теркәлгән. Коръәннән һәм хәдисләрдән, Мөхетдин Гарәбидән, Табарридан «Алты бармак» китабыннан дәлилләр китерелгән.

3а–5а кәгазьләрдә «Алты бармак» китабыннан кешелек яратылышына бәйле, җан һәм тән турындагы, пәйгамбәрләр тарихын тасвирлаган һ.б. өземтәләр күчерелгән.

5б кәгазьдә «Алты бармак» китабындагы пәйгамбәрләр тарихы дәвам ителеп, Нух пәйгамбәрнең балалары хикәяләнгән, төрекмәннәр һәм төрекләр Яфәс токымы булуы турында һ.б. язылган. Гарәп тарихчысы Табарри китабындагы һәм Рабгузиның «Кыйсасел-әнбия» әсәрендәге мәгълүматлар теркәлгән.

Шул ук битнең уртасыннан башланып, 6а кәгазьдә дәвам иткән текстта «Миръател-кяинат» рисаләсеннән Нух пәйгамбәрнең нәсел дәвамчылары, Яфәснең угыллары турында бәйан ителгән. Яфәснең бер улы Гуз (Угыз) Болгар вилайәтенә килеп биналар төзүе, аның бертуган кардәшләре Рус, Сакъләб һ.б. турында язылган. 6б кәгазьдә дә шул ук китапның төркиләр турындагы 6 нчы фасылыннан күчермә урын алган. 7а кәгазьдә дә әлеге китаптан төркиләргә багышланган өлеше дәвам иткән, Чин һәм Дәрбәнд вилаятьләре тасвирланган.

7б кәгазьдә «Миръател-кяинат» китабының Яфәс улы Рус өммәте, сакалибә һәм татар өммәтләре турындагы фасыл-бүлекләр күчерелгән. Анда мондый юллар бар: «Җәмигъ тәваифе магул вә әксәр татар Мәвараэннәһердә улуб, вилайәтләре Фирганә, Шаш, Кашан, Кяшгар вә дийаре Чинә дәк бәгъзе мәмләкәтләрдүр. Әксәр мәмалике исламийәйе, хосусан, Бәгъдады хәраб идән Чыңыз хан вә аның угылы Һуләгу вә анларның җөмлә гаскәрләре таифәи магулдан иделәр. Анлар вә халән дийаре шәрыкдә «үзбәк» дидүкләре татарлар вә

чыгытай татарлары. Вә дийаре Көфә сәмтендә улан вилайәт Дәште Кыпчак татарлары вә нугай татарлары вә «кичә баш» вә «ак баш» вә «ак кайынлы» вә «кара кайынлы» таифәләре сәдде йәэҗүҗдән тышра калан кабаиле әтракь нәселендәндер занн улынур» («Миръател-кяинат»).

Бу биттә шулай ук «Укъянус» китабыннан да мәгълүмат теркәлгән. Мәсәлән, бер өлеше: «Мөтәрҗим дийәр ки, көтебе тәварихда бу рәсмә мәрсүмдер ки: «Нәүбәте солтанәте Төркестан Төрк бине Яфәс ханәданыдан Алынҗа хана интикаль идүб, мәзбурның Мәгул вә Татар нам ике угылы улмагыйлә, җөмлә мәмләкәте бәйнләрендә тәкъсим иде. Мәгул вә Татар уймаклары анлардан мәншүр улды. («Укъйанус»).

Икенче китаптан мондый сүзләр күчерелгән: «Сарай – шималь тарафында мәгъруф шәһәрдер ки, дарел-мөлке татардур («Тибъян нафигъ, тәрҗемәи Борһане катыйг»).

Кульязманың 8а–8б кәгазьләрендә «Укъянус», «Тибъян нафигъ», «Нисабел-интисар», «Шәрхе Мөхәммәдия» китапларындагы төркиләр, «сакъләб» мәсьәләсе, Болгар, Төркестан, Дәште Кыпчак турында һ.б. тасвирланган төрки һәм гарәп телләрендәге өземтәләр күчерелгән.

9а кәгазьдә Ибраһим Хаккыйның «Мәгърифәтнамә» хезмәтеннән, Табарри китабыннан татарчага тәрҗемә ителгән өзекләр урын алган. Мәсәлән, яэҗүҗ-мәэҗүҗдән саклану дивары борынгы Татарстанның (кульязмада: «Татарстане кадим») төньягында булуы, Хәзәр, Дәрбәнд шәһәрләре, Азәрбәйҗанда ислам динен тарату, Сакъләб елгасы, Турхан исемле кешегә каршы сугышка бару турында бәян ителгән.

9б кәгазьдә «Тибъян нафигъ» һәм «Укъянус» китапларыннан Рус вилаяте, Болгар шәһәре һәм иле, Әтил елгасы, Хәзәр, Төркестан, Сакъләб, Алан, Дәште Кыпчак вилаятьләре турында кыскача мәгълүматлар күчерелгән.

Бу кәгазьнең түбәнге өлешендә «әгузе...» һәм «бисмилла...» белән башлап, авторның үз әсәренең башыннан өч юл ярым язылып, сызылган.

10а кәгазьдә Табарри китабыннан дин сугышлары, Турхан-

га каршы яу өлешләре, Мәһди чыгачак заман турында төркичә һәм гарәпчә күчермәләр бар.

Кульязма җыентыкка текстларның теркәлгән вакыты – һиҗри 1294 һәм милади 1878 елның сентябре датасы күрсәтелгән: «әл-йаумә һиҗрәти нәбийина саллаллаһу Тәгалә галәйһи вәссәлләм мең дә ике йөз дә туксан дүрт сәнәдүр, ...әл-йаумә румийә мең дә сикез йөз дә йитмеш сикезенче, сентябрь 5».

Битнең түбәнге өлешендә һәм читендә мондый рәвештәге шигъри юллар язылган:

«Бере-беренә керүб
Кяфер вә ислам әһеле,
Алты елдур ки атарлар
Бере-беренә сәһам.

Ике-өч кәррә идүб
Һиҗрәт румия шаһа,
Улды тәкъдир хәмд илә
Безә Бурса мәкам.

Шөйлә ки Бурсайы хуш
Күрмәдә мәҗалем вардур.
Кидәрәк хасил улур
Чикмә әләм җөмлә мәрам».

Әлеге шигырь бу кульязма җыентык язылган елларда барган рус-төрек сугышының кайтавазы икәнлеге аңлашыла.

Җыентыкның 10б кәгазендә «Нәтаиҗел-фөнүн» китабыннан фани дөньяның күпме яшәячәге мәсьәләсенә бәйле, пәйгамбәрләрнең гомер озынлыклары һ.б. мәгълүматлар теркәлгән. «Әхмәдия» китабына да ишарә бар.

11а кәгазьдә Болгар һәм Казан ханлыклары турында авторның үз фикерләре язылган. Әсәренең төп текстындагы фикерләреннән мондые кабатланган: «Болгар вә Казан вә Кырым вилайәтләренең, вә Дәште Кыпчак да исемләре кадим заманда – Нухдан соң Яфәс угылы Төрек Бабилдан күчеб, шималь тарафына килүб, угылы Алынҗа хандан ике угыл тугуб, бере –

Татар вә бере – Мәгул. Мөрүре заман берлә анларга җөмләтән «Җабәлкаһ» дийәрләр. Бәкъиә кауме Салих галәйһиссәлам нәселендәндер, кәсрәтдә тукуз йәэҗүҗ вә мәэҗүҗ кадәрледүр, мөрүре заман берлә «Дәште кыпчак» дийәрләр».

Шунда ук Нух пәйгамбәрдән дәвам иткән шәҗәрәнең берничә төп буыны, Яфәснең 13 улының исемнәре теркәлгән. Болгар-Казан вилаяте һәм анда яшәгән халыклар (барлыгы – 14) исемлеге һәм берничәсенең хаким-хөкемдарлары аталган: Җабәлкаһ («падишаһ вә гъад кауме»), 2) Хәзәзийан («хакан, хәзәр(?)», 3) Болгар (хан, кан), 4) Казан (хан, биләр), 5) татар, 6) мишәр, 7) төмән, 8) башкорд, 9) кыргыз, 10) чуаш, 11) чирмеш, 12) мукшы, 13) мурдуба, 14) ар (вотяк).

11б кәгазьдә яэҗүҗ-мәэҗүҗдән саклану өчен Искәндәр Зөлкарнәйн төзеткән ике дивар турында китаплардан түбәндәгечә өземтәләр күчерелгән: «Сәдд ике кыйсемдер. «Сәддел-әүвәл әл-Искәндәри» диб әйтүләдер Кафказ (вә Кабкас вә Каукасел-бәрз тагъ (вә даг) – тауларындин башлаб, Дәрбәнд вә «Җәбәлел-кабук» вә «Дәмүр капу» вә «Каф тагы» дийәрләр, вә «Бабел-әбваб» дийәрләр. Мәзкүр Капкас арзындан башлаб, та Сибирийә тарафында улан хакыйкый сәддкәчә бер тарафы Урал вә шәрык, вә бер тарафы Бәләнхәр вә Рус вилайәтләрене вә Болгар вә Казан вилайәтләрене ихата кыйлуб, Боз диңгезенә кадәр барчасына «Мөкаддимәи йәэҗүҗ вә мәэҗүҗ» дийәрләр. Әксәре әүляде Яфәсдүр. Вә «Сәддес-сани әл-әкбәр әл-Искәндәри» дийәрләр – Хытайның шималендә вә Татарстане кадимнең шималендә бер мәмләкәтдер. Сибирийәнең әкъсасе улан йирләрдә булса кирәк («Мәгърифәтнамә» бәйаны).

«Мәшрикъ тарафында Хыта[й] вә Чин вә Дәште Кыпчак киселдүге йирдә йәэҗүҗ вә мәэҗүждүр» («Шәрхе Мөхәммәдийә»дә мәзкүрдүр)».

Шул ук кәгазьдә пәйгамбәрләрнең гомерләре һ.б. риваятьләр нигезендә дөньяның яшәеш вакытын исәпләү язмалары теркәлгән.

Бу биттә рус графикасында «указни мулла Мингазутдин» дигән язма да бар.

12а–12б кәгазьләрдә «Нисабел-интисар», «Алты бармак» китапларындагы Болгар каласы һәм халкы турындагы язмалар күчерелгән. Авторның Болгар вилаятенең төрки кавемнәре, чуваш, чирмеш һ.б. турындагы фикерләре урын алган, этнографик үзенчәлекләре һәм уртаклыклары, телләре һ.б. бәян ителгән.

13а кәгазьдә Искәндәр Руминың Болгар каласын төзетүе һ.б. турында «Тибъян нафигъ» тәрҗемәсе һәм «Нисабел-интисар» китабындагы мәгълүматларга нигезләнгән язмалар урын алган (татар һәм гарәп телләрендә).

Кулъязманың 13б–14а кәгазьләрендә Болгар һәм Казан вилаятьләренең барлык халыклары әүвәл Салих пәйгамбәр заманында мөэмин булганлыгы, аннан соң Искәндәр Руми заманында иман китерүләре һәм һиҗри 9 елда Мәдинә шәһәреннән өч сәхабә килеп, Болгар халкын мөселманлыкка дәгъвәт иткәнлеге турында язмалар теркәлгән. Әүвәлге сугышлар, Чыңгыз ханның Болгарны яулавы, Аксак Тимернең Болгар илен җимерүе-туздыруы, качып-посып калган мөселманнарның Казан шәһәрен салулары, аннан яңа урынга күчүләре кыскача әйтелгән. Һиҗри 961 елда русларның Казанны яулап алулары язылган. Шул вакыйгага бәйле борынгы бәетнең берничә юлы теркәлгән. Элекке сугышлар булып үткән урыннар белән әүвәлге кайбер калалар турында мәгълүмат бирелгән. «Татар» сүзенең мәгънәсе язылган. «Алты бармак» китабыннан мондый юллар да күчерелгән: «Әмма «тата[р]» ләфзы рәсүлуллаһ лисане мөбарәкләр дахил улуб бойурмышдур ки, ганбәр вә татар Һинддә. Сәгъд вә татарда улур димешдүр ки, «татар» – бер хушбуйдур, асыл Хытайдан килүр. Сәгъд – Сәмәрканд шәһәре».

14б кәгазьдә Сөләйман Бакырганиның «Шәйхем Әхмәд Ясәви» шигъри тексты теркәлгән. Бу шигырь «Бакырган китабы» исеме белән мәшһүр суфичылык шигърияте җыентыгында бар. Шигырь тексты читендә калган буш урынга гади карандаш белән рус телендә «Мулла Мингазутдин Сейфуллин» дип язылган.

Шул ук биттә «Борынгы Татарстан»ның («Татарстане кадим») иң әүвәлге географик урыны һәм андагы халыкның

кайсы якларга һәм кыйтгаларга таралганлыгы турындагы мәгълүмат теркәлгән.

Җыентыкның 15а–19а кәгазьләрендә татарлар һәм Идел буендагы башка халыкларның борынгы чордагы уртак тарихы турында автор тексты бирелгән.

19а кәгазьдә «Тибъян нафигъ» һәм «Тәнбиһел-гафилин» китапларыннан төрки-татарлар (угыз, төрк һ.б.) тарихына караган кыскача күчермәләр бар.

19б–20а кәгазьләрдә «Тарихе Ибне Хәлликан» китабыннан телләр һәм язулар турында мәгълүмат күчерелгән. Сөрьяни һәм гарәби әлифба хәрефләре язылган. Татарларның сабак-дәрес уку тәртибе (әлифбадан башлап, гыйльми китапларга кадәр саналган). Татарларның һәм Болгарның ислам динен кабул итү вакытлары турындагы кыскача язма урын алган.

19б кәгазьдә зур хәрефләр белән «Рысбуга, Богырыслан, Рысбуганың Җәлалетдин хәзрәт, Фәхретдин мәзин» дигән аерым атама-исемнәр теркәлгән.

20а кәгазьнең түбәнге өлешендә Муса пәйгамбәрдән әүвәлрәк булган кавемнәр турындагы язма бирелгән. Шул биттә болгар-татарларның мөэмин-мөселман булу тарихы кыскача бу рәвешле теркәлгән: «Татарлар Салих пәйгамбәр заманындин бирле мөэмин булуб, Җабәлкаһ нам гөзар идеб, рәсүлулла кәндүсенә иман килтүреб, Болгар нам кальга йасуб, соңра өч сәхабә дәгъвәте берлә иман килтү[ре]б вә соңра тәҗдид вә әзйад иткәнләр. Габдрахман сәхабә вә Мәсләмә Хәзазийанны вә дәхи биш холәфаи габбасийәдән Мәэмүн, Васыйк Билләһи».

20б кәгазьдә «Тәүрат Шәриф каблә Муса галәйһиссәлам үзә ун сухәф вә ун кәлимат вирелмешдер. Хакъ Сөбханәһә вә Тәгалә бойурды ки» дип башланып, ун таләп-кагыйдә язылган. Шул ук мәгълүмат 21б кәгазьдә дә кабатланган, андагы исеме «Әлвахе гашәрә, Муса галәйһиссәлам үзә бирелмешдер».

Бу биттә гади карандаш белән рус графикасында «Мулла Мингазутдин» дип язылган.

21а кәгазьдә Африка кыйтгасындагы ил-дәүләтләр (Тунис, Мисыр һ.б.) турында кыскача географик, дини, тарихи, стати-

стик мәгълүмат язылган. Бу текстның башы 37б кәгазьдә.

22а кәгазьдә Минһаҗетдин Сәйфулла улы язган тарихи хезмәтенең исеме – «Тәварихел-Болгарийә вәл-хаканийә» һәм ярым аннотацияле киңрәк рәвештәге исем вариантлары теркәлгән.

Кәгазьнең язудан буш урынына көрән төстәге кара белән, рус хәрефләрендә «Мингазутдин Сейфуллину, мулла» дип теркәлгән.

Җыентыкның 22б–23а кәгазьләрендә «Тәварихы Болгарийә вә татарийә» дип исемләнеп, авторның тарихи хезмәте тексты язылган.

23б кәгазьдә Зөя өязенең Бәчек авылы зиратындагы борынгы ташъязма истәлекнең алгы һәм арткы, ян-якларының рәсеме ясалган. Алгы ягында 7 юлга бүленгән тексты һәм арткы ягындагы язуының күренгән хәтле өлеше, ике янындагы язмалары сурәтләнгән. Алгы тарафындагы төп мәгълүматы – елы һәм кеше исеме ялгыш укылган. Язудан тыш өлеше (читләре) гади карандаш белән буялган. Бу ташка карата өстәмә аңлатма теркәлгән һәм Бәчек авылының нигезләнү тарихы кыскача бәян ителгән.

Бу биттә гади карандаш белән вертикаль рәвештә:

Ата ялган хатынсың,
Ахры, миңа калырсың,

– дигән юллар теркәлгән.

Кулъязма җыентыкның бу кәгазенең читләре шактый тузган, язуларының бер өлеше таушалып һәм тетелеп юкка чыккан.

24а кәгазьдә «Көнһел-әхбар» китабыннан Әтил елгасы һәм шәһәре, Болгар, Биләр, Хәзәр, Сарай, Саксин, Үкәк һ.б. шәһәрләр, Яфәс нәселе һәм төркиләр турында мәгълүмат, шигъри парча күчерелгән, Ибне Әсир мәгълүматлары телгә алынган.

Кулъязманың 24б кәгазендә «Миръател-кяинат» китабыннан фарсыларның һ.б. кавемнәрнең утка табынучы мәҗүсигә (зәрдәшт) әверелүе турындагы язма теркәлгән. Шул ук китаптан борынгы пәйгамбәрләрдән дәвам итеп килгән рум, юнан,

гаҗәм һ.б. кавемнәрнең шәҗәрәсенең схематик язмасы урын алган.

25а кәгаздә «Миръател-кяинат» китабындагы мәгълүматлар нигезендә, Нух пәйгамбәрдән дәвам иткән шәҗәрә һәм аңа аңлатмалар, «сакъләб», Болгар һ.б. турында Минһаҗетдин мулланың үз искәрмәләре (мәсәлән, Хәзәр шәһәре турында һәм төрле төбәкләрдә яшәүче татарлар турында), текстка бәйләп 1295 нче һиҗри ел датасы да (милади 1878 ел) теркәлгән.

25б кәгазьдә гарәп географы Әбү Исхак әл-Истәхридән Әтил елгасы, Болгар, Суар шәһәрләре турындагы түбәндәге мәгълүмат язылган.

«Болгар, Суар (Сур суы буй таифәсе ...), Белеквар, Пиләр, Пиләрхар.

Мәрҗани китаб. Әбү Исхак әл-Истәхри.

Атилнең башы Хархиз җирендән чыкуб, Кимәкийә вә Гузийә арасында хәдде фасыйль булуб, мәгъриб тарафына борулуб, Болгарга килеб, Бортас вә билядел-Хәзәргә гауд идүб койадур[5].

Яфәс, угылы Кимәри, Болгар, Бортас, Ар таифәсе (кальгаләре Арчада), Мурдас, Мурдва, Мукчы, Иржә, Мичәр.

Суар вилайәте Сур суы буйында. Суар Суаш вә Субаш.

Химәншин татары (Уг суы буйында), Тирхан вилайәте (Уг тамагында Сарай булган).


Атил суы Ука суының буйында Алмалы Атагача Тутый тамагындин.

Болгар таифәсе Кимәри балалары. Кимәри, Болгар, Бортас, дәхи Суар (чуаш) вә дәхи Суас (татар). Монлар барчасы хәйрел-касрунда иман вә исламда улганлар.

Чирү вә Чир Гуз угылы (үзбәк лисаны). Чирмеш Гуз угылыны, йәгъни татарны «суас» диб әйтәләр. Ар таифәсе татарны «бигер» диб әйтә, чөнки Яфәс угылы Гуз угылы Пигур улдыгы җәһәтилә. Ар чирмеш[не] «пур» диб әйтә. Чирмеш

---

[5] Әтил (Атил, Итил), ягъни Идел елгасының хырхыз (кыргыз, бу очракта казакъ) вилаятеннән башлануы турындагы мәгълүмат ялгыш. Бу очракта Чулманга коя торган Агыйдел күздә тотылып, Идел елгасының агымы ялгыш күзалланган.


نوح عليه السلام

سام حام يافث

*Кулъязманың 25а кәгазе*

арны «увод» диб әйтә. Чирмеш чуашны «кыркмари» дийәрләр. Чуаш мукшы[ны] «ирҗе» диб әйтә. Әл-йаум Кимәри чирмеш болгар, ар, бортас (бордас), йәгъни мурдас, йәгъни мурдва, йәгъни мукшы – чуаш вә чирмеш нәүгысендән».

26а кәгаздә казакъча ел башы һәм елларның хайван исемнәре белән аталышы, һиҗри 1295, милади 1878 елдан алып 1300/1893 елга кадәр кайсы ел нинди хайван елына туры килүе теркәлгән.

26б кәгазьдә Минһаҗетдин Сәйфулла улының «Мөнтәхәбет-татар» рисаләсенең (кыскача вариантының) башы язылган.


27а кәгазьдә «Татарларның дәрес нәүбәте (чираты, кизүе) ошбу рәвешчә» дигән баш астында мәктәп-мәдрәсәләрдәге уку тәртибе тасвирланган. Кәгазьнең өстендә З.Максудова гади карандаш белән «II вариант» дип искәрткән.

Кулъязма җыентыкның 27б–28а кәгазьләрендә Җирнең түгәрәк шәкелдә булу мәсьәләсенә юнан һәм мөселман галимнәре карашлары, планеталар һәм күк җисемнәре гомуми рәвештә тасвирланган.

28а кәгазьнең яртысыннан алып Минһаҗетдин Сәйфулла улының үз әсәре исеменең аннотация рәвешендәге озын вариантлары теркәлгән.

28б кәгазьдә чуаш авыллары зиратларындагы мөселман ташлары һәм иске кала урыннары турында мәгълүмат язылган.

Җыентыкның 29а–30а кәгазьләрендә кайбер сүзләрнең («алпавыт», «чирү» һ.б.) этимологияләре, «Кыйсасел-әнбия» китабыннан пәйгамбәрләргә бәйле һ.б. язмалар, «Көнһел-әхбар» китабыннан Ибне Әсирнең хәзәрләр турындагы мәгълүматы, Әтил, Биләр, Болгар, Саксин шәһәрләре турындагы күчермәләр, Искәндәр Зөлкарнәйн хакында гарәп телендәге китаптан өземтә урын алган. Текстларга карата Минһаҗетдин Җәбәлинең кайбер искәрмәләре бар. Сәмуд һәм гъад кабиләләре, гаҗәмнәр, Нухтан дәвам иткән тармаклар турында «Кыйсасел-әнбийа»дан, Табарридан күчерелеп язылган. «Кыйсасел-әнбийа» дигән китап исеменең астына кызыл карандаш белән сызылган.



*Кулъязманың 29б кәгазе*

29б һәм 30а кәгазьләрдәге текстлар эре хәрефләр белән, кәгазьнең озынча буена теркәлгән.

30б–31а кәгазьләр Рабгузиның «Кыйсасел-әнбия» китабыннан күчермәләрне тәшкил итә.

31б–35а кәгазьләрдә авторның үз хезмәте тексты язылган. «Татар» атамасы һәм халкы турында этимологик, этнографик, лингвистик, дини мәгълүмат һ.б. теркәлгән. 34б кәгазьнең төп текстындагы юллар арасына автор тарафыннан карандаш белән Табарри китабы 3 нче җилденең 108 битеннән текст өземтәсе күчерелгән. Анда туфан суы күтәрелгәннән алып Ибраһим пәйгамбәргә хәтле узган вакыт арасында гъад кавеменең азганлыгы, Аллаһы Тәгаләнең аларга Һуд пәйгамбәрне җибәрүе һәм аннан соңгы вакыйгалар тасвирланган. 34б кәгазьнең уртасыннан түбәнрәк урындагы текст өлеше карандаш белән сызып, русча «отсюда» дип искәртелгән һәм 35а кәгазьнең түбәннән өченче юлында шулай ук карандаш белән «до сюда» диелгән.

34б кәгазьнең ахырында «Бу урынга «Болгар бәйете» йазылачакдыр» дип искәртелгән.

35а кәгазьнең түбәнге юлларында Ибраһим Хаккыйның «Мәгърифәтнамә» китабыннан күчермә башланып, 35б һәм 36а кәгазьләрдә дәвам иткән.

Кулъязма җыентыкта дөньяның төрле кыйтгаларындагы илдәүләтләр турында мәгълүмат бирелеп, Европаның XIX гасырдагы әһәмияте билгеләнгән.

Дөньядагы диннәр һәм материклар, Европадагы илдәүләтләр турында кыскача тарихи, сәяси, географик, дини һәм статистик мәгълүмат язылган (чыганагы күрсәтелмәгән).

36б кәгазьдә шундый ук рухта Русия мәмләкәте, Госманлы дәүләте, Иран, Әфганстан, Һиндстан, Япония һәм Азиянең башка илләре турында кыскача язмалар теркәлгән. Мәсәлән, Русия турындагы өлеше: «Русийә мәмләкәте гадәде нөфус Сибирийәдә, Каукас (йәгъни, Кафказда) вә Аурупада ныйсьфе русийә улуб, туксан миллион нөфусләр дийеленде. Хөкүмәт идән әгъзалар мирыски мәзһәбдә нәсарилардур. Ислам әһеле вә мәзһәбе хәнәфи татарлар чукдур вә һәм рәваизлар, шыйгалар вә

кызылбаш нәүгълар Кафказ җирендәдүр, чиркәсләр шафигый мәзһәбдәдүр вә Төркестане кадим, Хива вә Кукан вә Ташкәндләр мәзһәбе хәнәфидә, сарт халыкларыдур. Вә һәм төрле җәһүдләр бардур вә төрле динләр күбдүр. Кырык төрле телләр берлән сүләдеге халыклар бардур. Русийә бер олуг падишаһлыкдур. Нуруфийә[6] кенәзләре Русийәгә табигъдур».

37б кәгазьдән Африка турында языла башлаган, дәвамы 21а кәгазьдә.

Кулъязманың 38а кәгазендә ләүхелмәхфүз турындагы кыскача риваять һәм Муса пәйгамбәргә Аллаһы Тәгаләнең ун боерыгы теркәлгән. Кәгазьнең бушрак калган урыннарында русча «мулла Мингазутдин» дип язылган.

38б кәгазь – Минһаҗетдин Сәйфулла улы әсәренең тулырак вариантының башы. Әсәрнең исеме башта «Мөнтәхәб фи әхвалит-та[та]р вәл-болгар» дип язылган һәм сызып «Мөнтәхәб фи әхвали әкрадел-мөхтәлифә вә әтракел-мөхтәлифә фи ардил-Болгар вәт-татар» дип төзәтелгән.

Битнең ахырында «Мондан соң мәнакыйбе хәзрәти ишан язылыр» диелгән.

38б кәгазьнең тексты З.Максудова китапханәсенә багышланган китапта гарәп хәрефләре белән тулаем диярлек (башын кертмичә) күчереп бастырылган. Анда кулъязманың үзендәге пагинация буенча бите «72а» дип күрсәтелгән[7]. Текст эчендәге кайбер сүзләр бөтенләй язылмаган, ә кайберләренең хәрефләре төшеп калган яисә үзгәртелгән. Мәсәлән, *«идәк, фәнә, Түнәр»* – чынлыкта тиеш: *«идәрәк, фәнни, Түнтәр»*.

1б–11а, 12а–13а, 15б–17б, 18б–21а, 22а, 23а, 25а, 26а, 27б–30б, 38а, 38б кәгазьләрдә карандаш белән вертикаль рәвештә (аерым очракларда диагональ буенча) «язылган» дип, 22б–24б, 25б, 26б, 27а (ике урында), 27б кәгазьләрдә «язылды» дип искәртелгән. Алда әйткәнебезчә, болар – З.Максудова искәрмәләре.

---

[6] Кулъязмада бу сүзнең астына З.Максудова тарафыннан шәмәхә кара белән сызып, кәгазьнең читенә сорау билгесе куелган.

[7] Бустанов А. Библиотека Зайнап Максудовой..., 2019. – С. 179–180.

Бу кульъязманың кайбер мәгълүматлары басылды:

1. «Казан бәете» фрагменты (кульъязмада 14а, 35а кәгазьдә)

– Яхин А., Бакиров М. Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе: мәзәкләр, бәетләр. – Казан: ун-т нәшр., 1979. – Б. 125.

– «Гәүһәр Болгарга килдем...»: тарихи бәетләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2013. – Б. 96, 113.

2. Әсәр текстының кереш өлеше (кульъязмада 38б кәгазьдә), Гали ишан Түнтәри иҗазәтнамәсенең күчермәсе (кульъязмада 1а кәгазьдә) һәм Нәкышбәндиләр силсиләсе (кыскача, кульъязмада 2а кәгазьдә) – болар барысы да гарәп хәрефләрендә

Бустанов А. Библиотека Зайнап Максудовой = Зәйнәп Максудова китапханәсе. – М, 2019. – С. 177–180.

# СҮЗЛЕК

*анлар* – алар

*әз тәхрирате галлямәтез-заман* – заманның иң олуг галиме язганнардан
*әксәр* – күпчелек
*әкъса* – ерак
*әләм* – газап, җәфа
*әлвахе* гашәрә – ун язу
*әл-йаумә* – бүген, хәзер
*әүляд* – балалар

*бәгъзе* – кайбер
*бәйнләрендә тәкъсим* – араларында бүленгән
*бәкъиә* – калдык, калган
*безә* – безгә
*билядел-Хәзәр* – Хәзәр шәһәре

*вә* – һәм
*вирелмеш* – бирелгән

*гадәде нөфус* – халык саны
*газиз* – изге
*галәйһиссәлам* – пәйгамбәр мәгънәсендә
*гауд идүб* – борылып
*гөзар идеб* – үтеп
*гуаһ* – шаһит

*дахил* – эчке, эчендәге
*дәк* – хәтле
*дәхи* – тагын
*дидүкләре* – диелгән, дип аталган

*дийар* – илләр
*дийеленде* – әйтелде

*җәмигъ тәваифе магул* – барлык монгол халкы
*җөмләтән* – барысы бергә, һәммәсе, берьюлы

*занн улынур* – уйланыла, фаразлана
*земляк* – якташ
*зимләнкә* – җиргә казып эшләнгән торак; рус телендәге «землянка» сүзе

*игътираз кыйлган* – кире каккан
*идән* – иткән
*икълим* – борынгы географик бүленеш буенча җирнең экватордан төньяк котыпка кадәр булган җиде бүленешенең берсе
*имди* – инде
*интикаль идүб* – күчеп

*йасуб* – ясап

*кабаиле әтракь* – төрки кабиләләр
*каблә* – элек, әүвәл
*кадим* – борынгы, элекке
*калеб* – йөрәк, күңел
*кальга* – кала, ныгытма, крепость,
*кариб* – якын
*кәлимат* – сүзләр
*кәндүсе* – үзе
*кәрамәт* – могҗиза
*кәррә идүб* – кабатланып
*кәсрәт* – зурлык, өстенлек
*кемсәнә* – кеше
*кидәрәк* – китеп
*киселдүге йир* – киселгән җир
*көтебе тәварих* – тарих китаплары
*куддисә Аллаһу Тәгалә әсрарүһүм* – Аллаһы Тәгалә аларның серләрен пакь һәм мөбарәк кылсын
*күрмәдә* – күрүдә

*ләфыз* – сүз
*лисан* – тел

*мәгъриб* – көнбатыш
*мәгъруф* – мәшһүр
*мәҗалем вардур* – көчем бар
*мәзбур* – язылган, әйтелгән
*мәзкүр* – әйтелгән, телгә алынган, шушы, бу
*мәкам* – урын
*мәмалике исламийә* – мөселман илләре
*мәнакыйб* – мактаунамә, мәдхия
*мәншүр улды* – таралды
*мәрам* – теләк
*мәрсүм* – тасвирланган
*мирыски* – христиан динендәге мәхәллә халкы; рус телендәге «мирский» сүзе
*мөрүре заман* – заман үтү, вакыт узу
*мөтәрҗим* – тәрҗемәче
*мутаука* – болгаткыч; рус телендәге «мутовка» сүзеннән

*нам* – исем, исемле
*нәсари* – христиан
*нәүбәте солтанәт* – патшалык нәүбәте
*ныйсьфе* – яртысы

*ригая кыйлыб* – өстен күреп
*румийә* – милади ел исәбе

*сәдде йәәҗүҗдән тышра калан* – яэҗүҗ-мәэҗүҗ дивары тышында калган
*сәддел-әүвәл әл-Искәндәри* – Искәндәр төзегән беренче дивар
*сәддес-сани әл-әкбәр әл-Искәндәри* – Искәндәр төзегән икенче бөек дивар
*сәмт* – тараф, як
*сәнә* – ел
*сәһам* – ук
*сухәф* – сәхифәләр, битләр
*сүләдеге* – сөйләшүче

*та* – хәтле, кадәр
*табигъ* – буйсынучы
*таифә* – халык
*тәҗдид вә әзйад* – яңарту һәм арттыру
*тәэлиф ителгән* – язылган
*тугуб* – туып

*уймак* – ыру
*улмагыйлә* – булганлыктан
*улуб* – булып

*үзә* – өчен, белән

*фар-фүр* – музыка уен коралы

*халән* – хәзер
*хана* – ханга
*ханәдан* – династия
*хәдде фасыйль булуб* – тукталып
*хәйрел-касрун* – кыска һәм хәерле вакыт
*хәмд илә* – мактап
*хәраб идән* – җимергән, тар-мар иткән
*хилаф* – каршы
*холәфаи габбаси* – габбаси хәлифәләр
*хосусан* – аеруча, бигрәк тә

*һиҗрәти нәбийина саллаллаһу Тәгалә галәйһи вәссәлләм* – пәйгамбәребез (аңа Аллаһы Тәгаләнең салаватлары һәм сәламнәре булсын) һиҗрәте (күчүе)

*чук* – күп

*шаһа* – шаһка
*шималь* – төньяк
*шөйлә* – шундый
*шыйга* – шигый

*ыстатья* – статья, мәкалә

# РЕЗЮМЕ


Тридцать первая книга серии «Татарская археография» включает текст ранее неизвестного сочинения по истории татарского народа Мингазутдина Сайфуллина аль-Джабали. Рукопись, хранившаяся в личной библиотеке педагога, археографа Зайнап Максудовой (1897–1980), в 1962 году была передана ею в Научную библиотеку им. Н.И.Лобачевского Казанского государственного университета.

Рукописный сборник на 38 листах, основной текст которого был написан в 1878 году, сохранился в относительно удовлетворительном состоянии. Часть листов находится в разрозненном виде, порядок их перепутан. Авторская пагинация и кустоды отсутствуют, что усложняет восстановление первоначального авторского текста.

В результате тщательного изучения рукописи установлено, что большую часть текста составляют цитаты о древних тюрках и истории распространения ислама в Поволжье. Остальной текст – оригинальные авторские трактовки в трёх вариантах. В текстах имеются правки, добавления и примечания. Наличие окончательного варианта данного исторического сочинения не установлено.

Мингазутдин Сайфуллин (1838–1893), получивший образование в медресе известного религиозного деятеля Мухамметгали ишана Тюнтяри (1788–1874), служил имамом, обучал детей грамоте и основам религии в деревне Васюково Свияжского уезда (ныне Зеленодольский район Республики Татарстан).

Примечательно, что сельский мулла Мингазутдин, воспитанник медресе Заказанья, имел довольно широкое представление об истории народов Поволжья, владел методами научного исследования и использовал различные документальные источники, изучал эпиграфические памятники XVI–XVII вв., сравнительно исследовал языки, ономастику, этнографию, основывался на произведениях фольклора и т.п. (интересен факт: он ссылался на статью 1876 года «Газеты А.Гатцука», опубликованную в Москве).

В период, когда Мингазутдин Джабали занимался своими исследованиями, не было опубликованных работ по истории татарского народа, написанных татарскими авторами.

Автор представлял себе всю серьёзность своего сочинения, что доказывается названием, которое он намеревался дать сборнику. В сборнике сохранилось 9 вариантов названий.

В рукописи М.Сайфуллина-Джабали имеется историческая информация о древних тюрках и татарах, местах их расселения, хазарах и др. Особое внимание уделено принятию ислама в Волжской Булгарии. Автором описаны несколько вариантов проникновения мусульманства в Булгарию. По его мнению, всё население Булгарского государства и Казанского ханства исповедывало ислам. Автор кратко описал разрушение Древнего Булгара Тамерланом, основание Старой и Новой Казани, завоевание Казанского ханства. В тексте приведён фрагмент баита, посвящённого взятию Казани.

Автор описал древних тюрков, хазар, булгар и татар как единый народ, трансформировавшийся в различные исторические периоды. Под этнонимом «татары» он подразумевал всю тюркскую общность. Говоря о населении Булгарии, он называл такие народности, как татары, чуваши, черемисы, мордва и удмурты, не выделяя отдельно «булгар». Этноним «булгар» автор представлял как собирательное название.

В сочинении освещается история мусульманства у чувашского народа, затронута проблема христианизации чуваш.

Мингазутдин Джабали описал некоторые древности – остатки городов и укреплений, курганов, отдельные эпиграфические памятники. В рукописном сборнике приведён рисунок эпиграфического памятника первой половины XVI века с кладбища деревни Васюково, представляющего особую историческую ценность.

Автором кратко описан порядок обучения в татарских мектебе и медресе.

С точки зрения современной академической науки некоторые описания и выводы Мингазутдина Сайфуллина могут вызвать сомнение. Тем не менее они интересны как суждения мыслителя того времени, как своеобразный взгляд на некоторые исторические факты, в том числе об этнических изменениях, этнониме «татары» и др. В целом, взгляды М.Джабали схожи с представлениями его современников, таких как Ш.Марджани, Х.Фаизханов, Х.Амирханов и К.Насыри.

В предлагаемом сборнике опубликованы тексты всех трёх вариантов сочинения Мингазутдина Сайфуллина. Во вступительной статье дан аналитический обзор содержания рукописи, информация об авторе. В конце книги представлено подробное описание рукописи.

Издание снабжено фотографиями, факсимиле некоторых листов рукописи.

# «ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ» СЕРИЯСЕНДӘ ЧЫККАН КИТАПЛАР

(төзүчесе – археограф, текстолог Раиф Мәрданов; «Милли китап» нәшрияты)

**Мәүла Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты»; «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты».** – Казан, 2008. – 88 б. – (1 нче китап). Шул ук. Икенче басма. – Казан, 2011. – 88 б.

**Түләк китабы: дастан.** – Казан, 2008. – 76 б. – (2 нче китап).

**«Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар.** – Казан, 2009. – 92 б. – (3 нче китап).

**Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы: әсәрнең Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмалары.** – Казан, 2009. – 128 б. – (4 нче китап).

**Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары...** – Казан, 2010. – 92 б. – (5 нче китап).

**[Мөхәммәтәмин]. Кыйссаи Мансур.** – Казан, 2010. – 128 б. – (6 нчы китап).

**[Фәезханов Хөсәен]. Кыскача татар тарихы.** – Казан, 2011. – 68 б. – (7 нче китап).

**Сәяхәтнамәләр.** – Казан, 2011. – 84 б. – (8 нче китап).

**Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте.** – Казан, 2012. – 184 б. – (9 нчы китап).

**Кыз хикәяте.** – Казан, 2012. – 184 б. – (10 нчы китап).

**Сөрген хатлары.** – Казан, 2013. – 103 б. – (11 нче китап).

**«Гәүһәр Болгарга килдем...»: тарихи бәетләр.** – Казан, 2013. – 128 б. – (12 нче китап).

**«Без плиндә ятамыз читлектәге кош кебек...»: Беренче**

**бөтендөнья сугышы бәетләре.** – Казан, 2014. – 119 б. – (13 нче китап).

**Гали авылы тарихы.** – Казан, 2014. – 164 б. – (14 нче китап).

**Тинчурин К. Каракүз: музыкаль мелодрама; Нәни абый: комедия.** – Казан, 2015. – 192 б. – (15 нче китап).

**Тинчурин К. Чит илләрдә: хыялый комедия.** – Казан, 2015. – 108 б. – (16 нчы китап).

**[Мөхәммәтәмин]. Гыйлем Хакка илтер.** – Казан, 2016. – 124 б. – (17 нче китап).

**Сугыш һәм солдат бәетләре.** – Казан, 2016. – 264 б. – (18 нче китап).

**Дастане җайә (Мәликә китабы).** – Казан, 2017. – 148 б. – (19 нчы китап).

**Матрос Әхмәдулла дәфтәре: 1898–1906 еллар.** – Казан, 2017. – 140 б. – (20 нче китап).

**Алдым каләм, яздым сәлам...: хатлар.** – Казан, 2018. – 180 б. – (21 нче китап).

**Солдат Ярулла дәфтәре: бәетләр һәм мөнәҗәтләр. 1905–1906 еллар.** – Казан, 2018. – 92 б. – (22 нче китап).

**«Чыңгызнамә»: тарихи дастаннар**. – Казан, 2019. – 288 б. – (23 нче китап).

**Халык җырлары: XVII–XX гасырлар.** – Казан, 2019. – 146 б. – (24 нче китап).

**Бөек Ватан сугышы хатлары, солдат хатирәләре: Җиңүнең 75 еллыгына.** – Казан, 2020. – 276 б. – (25 нче китап).

**Бакый Урманче көндәлекләре: 1965–1976 еллар.** – Казан, 2020. – 218 б. – (26 нчы китап).

**Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар.** – Казан, 2021. – 252 б. – (27 нче китап).

**Шәҗәрәләр. –** Казан, 2021. – 196 б. – (28 нче китап).

**«Утызынчы елларда...»: халык тормышының фаҗигале сәхифәләре.** – Казан, 2022. – 180 б. – (29 нчы китап).

**Милли китапханәнең археографик экспедицияләре: 30 еллык тәҗрибә.** – Казан, 2022. – 250 б. – (30 нчы китап).

# ЭЧТӘЛЕК

«БОРЫНГЫ ТАРИХЛАРДАН ҖЫЕП ЯЗДЫМ...»............3
Тарихи җыентык кулъязмасы ..............................................4
Авторы ..........................................................................11
Хезмәтнең исеме..............................................................18
Автор кулланган чыганаклар..............................................22
Әсәрдә нәрсәләр тасвирланган...........................................26
Эчтәлегенә кайбер искәрмәләр...........................................40
Чувашлар тарихына бәйле мәсьәлә ....................................54
Тау ягындагы борынгы кала урыннары..............................60
Хезмәттә тасвирланган ташъязма истәлекләр ..................64
Китапның эчке төзелеше турында ....................................78

ТӘВАРИХЫ БОЛГАРИЙӘ ВӘ ТАТАРИЙӘ
(текст транслитерациясе)......................................................81
II вариант .......................................................................82
I вариант .......................................................................116
III вариант.......................................................................139

БОЛГАР ҺӘМ ТАТАР ТАРИХЫ
(хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе) ..............................145
II вариант .......................................................................146
I вариант .......................................................................179
III вариант.......................................................................200

КУЛЪЯЗМАНЫҢ ТАСВИРЛАМАСЫ ..............................206
СҮЗЛЕК.............................................................................225
РЕЗЮМЕ ...........................................................................229

«Татар археографиясе» сериясендә чыккан китаплар .......231

**Мингазутдин Джабали**

# БУЛГАРО-ТАТАРСКИЕ ИСТОРИИ

*(на татарском языке)*

Составитель: Раиф Марданов
Ответственный редактор: Ирек Хадиев
Оформление: Ирина Мещанинова

Басарга кул куелды 15.05.2023. Форматы 60x84 1/16.
Тиражы 100 данә. Заказ № 477.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе.
«Милли китап» нәшрияты.
420015, Казан шәһәре, Пушкин ур., 86.

Подписано к печати 15.05.2023. Формат 60x84 1/16.
Тираж 100 экз. Заказ № 477.
Национальная библиотека Республики Татарстан.
Издательство «Милли китап».
420015, г. Казань, ул. Пушкина, 86.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият бүлегендә басылды.

Отпечатано в редакционно-издательском отделе
Национальной библиотеки Республики Татарстан.

سال ... ده بر زاهد ...

... آلی ... ایدی

... اول زاهید ... بیلدی

... اوغلی ... اولدی

... آنکا ... عمر ... قیلدی

... آنکا دخی پیغمبر دیب بیلدی

... یوسف جمالی کورکلی ...

... کوردی اول زاهید اول قیو...

... اجازه دعا قیلدی اول ...

... آنینک ... بر ... ایدی

... اول زاهید حقی حضرتنه دعا قیلدی

... خالقدن ... عمر ...

اول زاهیدنک دعاسی ... قبول ...

اول زاهیدی ...

... الله ...

... اطاعت قیلدی ...

... بس ...